Татар әдәбияты

7

Татар әдәбияты
7

А. Абзгильдин. Тукай

Ф. М. МУСИН, И. Г. ГЫЙЛӘҖЕВ,
Р. С. ШӘВӘЛИЕВА

Татар әдәбияты

Рус телендә урта гомуми белем бирүче мәктәпнең
7 нче сыйныфы өчен дәреслек

(татар балалары өчен)

*Татарстан Республикасы
Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан
тәкъдим ителгән*

Тулыландырылган өченче басма

КАЗАН
«МӘГАРИФ» НӘШРИЯТЫ
2005

УДК 373.167.1:821.512.145*07
ББК 83.3(2Рос=Тат)я721
М78

Охраняется Законом РФ «Об авторском праве и смежных правах». Воспроизведение всей книги или ее части на любых видах носителей запрещается без письменного разрешения издательства.

Мусин Ф. М.

М78 Татар әдәбияты: Рус телендә урта гомуми белем бирүче мәкт. 7 нче с-фы өчен д-лек (татар балалары өчен) / Ф. М. Мусин, И. Г. Гыйләҗев, Р. С. Шәвәлиева.— Тулыл. 3 нче басма.— Казан: Мәгариф, 2005.— 175 б.: рәс. б-н.
ISBN 5-7761-1521-3

ISBN 5-7761-1521-3
© «Мәгариф» нәшрияты, 1999, үзгәрешләр б-н
© «Мәгариф» нәшрияты, 2005, үзгәрешләр б-н
© Бизәү. «Мәгариф» нәшрияты, 2005

Халык авыз иҗаты

Халыкның телдән сөйләнә торган поэтик әсәрләре **халык авыз иҗаты** яки **фольклор** дип атала. Фольклор — инглизчә «халык акылы» дигән сүз.

Халык авыз иҗаты әсәрләре язу сәнгате туганчы ук барлыкка килгәннәр. Борынгы чорда җыр, бию, уеннар, төрле йолалар үзара үрелгән хәлдә ыруг, кабилә иҗаты буларак яши. Заманнар үтү белән кешеләрнең аңы да үсә. Шуның белән бергә халык авыз иҗаты да үзгәреш кичерә, аның төрләре арта, әсәрләрдәге фикер тирәнәя. Алар мөстәкыйль сәнгать әсәре булып формалашалар. Халык авыз иҗаты әсәрләренә җырлар, такмак-такмазалар, әкиятләр, мәкальләр һәм әйтемнәр, табышмаклар, мәзәкләр, бәетләр һ. б. керә. Аларда халыкның уй-хыяллары, гаделлек өчен көрәше, якты киләчәккә омтылышы гәүдәләнә. Шунлыктан фольклор әсәрләре һәркемгә якын, һәркемне дулкынландыра, яхшылыкка, әдәпле һәм намуслы булырга өнди.

Халык авыз иҗаты әсәрләре — күмәк иҗат җимеше. Аларның авторы билгеле булмый. Кем дә булса берәү җыр, мәзәк яисә әкият чыгара икән, алар шунда ук телдән телгә күчеп йөри башлый. Әнә шулай үзенең яшәвен дәвам итә. Һәр башкаручы кеше мондый әсәрләрне үзенчә эшкәртә, эчтәлеген тулыландыра, сәнгатьчә матурлый-бизи.

Фольклор — халыкның рухи хәзинәсе, ерак заманнарда яшәгән кешенең эчке дөньясын чагылдыра торган тормышчан чыганак. Халык авыз иҗаты әсәрләрендә җанлы сөйләм теленең үзенчәлекләре, халыкның фикер байлыгы, сүз тапкырлыгы, күп төрле сурәтләү чаралары тупланган.

Әнә шуларны күздә тотып, Габдулла Тукай болай ди:

«Дөресен генә әйткәндә, халык зур ул, көчле ул, дәртле ул, моңлы ул, әдип ул, шагыйрь ул».

Халыкның сүнмәс таланты белән иҗат ителгән фольклор әсәрләрен без бүген дә яратып укыйбыз. Язучылар, шагыйрьләр,

композиторлар һәм рәссамнар өчен исә халык авыз иҗаты әсәрләре бетмәс-төкәнмәс илһам чишмәсе булып тора.

Ә хәзер табышмаклар турында сүз алып барыйк.

Бер предмет яки күренешне шуңа якын торган икенче предмет яки күренешнең сыйфатлары буенча табуны белдергән кыскача шигъри сөйләмгә **табышмак** диләр. Табышмаклар — метафорик сөйләм, ягъни яшерен чагыштыру формасында туа. Анда мәгънә турыдан-туры әйтелми:

Ялт-йолт итәр, ялмап йотар. *(Ут)*

Баш астында баллы кашык. *(Йокы)*

Табышмаклар — кыска, конкрет сурәтле, рифмага бай тезмә әсәрләр. Җавабы да кыска була:

Кара мыеклы җизнәм,
Сагынып-сагынып килгән. *(Яз)*

Күренеш һәм хәрәкәтне белдерә торган табышмаклар да байтак:

Ак сандыгым ачылды, эченнән ефәк чәчелде.

(Таң ату, кояш чыгу)

Табышмаклар акыл йөгереклеген, уй зирәклеген арттыралар, шуңа күрә дә күбесенчә зиһен сынашуга, хәтерне ныгытуга хезмәт итәләр. Әмма үзләре борынгы заманнарда ук иҗат ителгән әсәрләр, аларны йола гадәтен үтәгәндә әйтешкәннәр. Мәсәлән, көз көне эш беткәч, мордва халкы табышмак бәйрәме үткәрә торган булган. Заманалар узу белән табышмакларның эчтәлеге үзгәрә барган һәм формасы белән дә шомара, чарлана килгән:

Канаты бар — җаны юк,
Очу өчен тиңе юк. *(Самолет)*

Тимер тәкә тау яра. *(Машина белән чәч алу)*

Табышмаклар хезмәт кешесенең дөньяга карашын ачыклау ягыннан да зур әһәмияткә ияләр. Аларда әйтелгәнчә, борынгы дәверләрдә кешеләр табигатьне җанлы итеп күз алдына китергәннәр, төрле хорафатларга ышанганнар. Шушы мифологик күзаллауларның эзләре аерым табышмакларда да беркадәр сакланып калган. Ләкин безнең көннәргә килеп җиткән табышмакларның иң зур күпчелеге халыкның табигать дөньясын материалистик рухта аңлавы турында сөйли.

Борынгылык сакланган аерым табышмакларны хәзер дә күрергә була:

Дию пәрие күккә аша, ашы-суы җирдә кала.

(Төтен)

Монда мифларга табыну чоры чагылып китә. Дию — мифик образ. Табышмакларда тарихи хәлләр, тормышның төрле ягы, кешенең рухи байлыгы, һөнәр-кәсепләре, аның әйләнә-тирәсендәге табигать күренешләре образлы сурәтләнә; аларда кешеләрнең теге яки бу күренешне ничек бәяләве ачык чагылыш таба:

Ишек төбендә биле бәйләүле кол ятар. *(Себерке)*

Тормыш үзгәрешен, үсешен чагылдыруда табышмаклар — реалистик әсәрләр. Хәзерге вакытта очрый торган аң-белем табышмаклары шуны исбатлый:

Түр башында җылы гармун
Бөтен өйне җылыта. *(Батарея)*

Үзе сөйли, үзе күренми. *(Радио)*

Табышмак бик образлы, матур сурәт күренешләрен күз алдына бастыра:

Йөзлек астында йөз инә. *(Керфекләр)*

Чагыштырулар кулланып яки арттырып әйтү (гипербола) юлы белән дә табышмак әйтелә, бу очракта предмет һәм күренеш җанланып китә, бик тәэсирле килеп чыга:

Метри башлы, мең күзле. *(Уймак)*

Койрыгы без кебек, күзе тоз кебек. *(Тычкан)*

Табышмаклар, шигъри әсәрләр булып, бер, ике, өч, дүрт, алты-җиде юлдан төзелергә мөмкин; шигырь юллары рифмалы була:

Ялт-йолт ялтырый,
Калт-колт калтырый.

(Яшен яшьнәү, күк күкрәү)

Безнең халык табышмаклар әйтергә бик һәвәс, аларны һаман иҗат итеп тора, кешенең образлы фикер йөртүен, акыл тапкырлыгын күрсәтү ягыннан да бу төр әсәрләрнең әһәмияте зур.

Сораулар һәм биремнәр.

1. Табышмакларның җавапларын табыгыз.

Ак сыер торып китте,
Кара сыер ятып калды.

Бер атасы, бер анасы,
Ничә йөз мең баласы.

Өй эчендә базым бар,
Баз эчендә бозым бар.
Керер идем, сыя алмыйм,
Бозларында шуа алмыйм.

2. Ике төркемгә бүленеп, табышмаклар уйлагыз һәм аларның җавапларын табыгыз. Кем алга чыгар? Урыннар билгеләгез.
3. Өйдә әби-бабайлардан, әти-әниләрдән табышмаклар язып килегез. Сыйныфта «Табышмак кичәсе» уздырыгыз.



Габдулла Тукай

(1886—1913)

Габдулла Тукай үзе исән чакта ук татар милләте аны үзенең рухи юлбашчысы итте, шагыйрь халык тарафыннан иң югары һәм үзгәрмәс бәя алды. Бик сирәк талант ияләренә генә насыйп була торган мондый бәя шагыйрь язмышының милләт язмышыннан аерылгысыз булуы белән аңлатыла иде. Тукай татарның тарихи язмышын үз башыннан кичерде һәм иҗатын да шушы язмышка багышлады.

Үзенең балалык елларын Габдулла Тукай «Исемдә калганнар» дигән автобиографик очеркында ачык гәүдәләндерә. Ул 1886 елның 26 апрелендә хәзерге Татарстан Республикасының Арча районына кергән Кушлавыч авылында Мөхәммәтгариф гаиләсендә дөньяга килә. Габдулланың тууын ата-анасы бары изге ниятләр белән, ак бәхетләр теләп көтеп алса да, язмыш аңа карата кырыслык күрсәтә: алты айлык вакытында атасы, ә дүрт яше тулып килгәндә анасы үлә. Шул вакыттан шагыйрь бу дөньяда япа-ялгыз кала һәм кулдан кулга йөртелә башлый.

Башта ул Өчиле авылындагы бабасының ишле гаиләсенә барып эләгә. Анда бу артык тамактан тизрәк котылу ягын карыйлар һәм, тиз арада бер ямщикка утыртып, Казанга озаталар. Печән базарында ямщик сабыйны кая куярга белми аптырап йөргәндә, Яңа бистәдә яшәүче Мөхәммәтвәли исемле кеше очрап, аны үзенә асрау бала итеп ала. Әмма Яңа бистәдәге тормыш нәни Габдулла өчен бик кыска гомерле була. Бер-ике ел үтүгә үги әтисе белән әнисе, икесе берьюлы авырып китеп һәм баланың тагын берүзе калуыннан куркып, аны кабат Өчилегә озаталар. Бу авылда яңадан малайны тизрәк каядыр

җибәрү ягын карыйлар, һәм бераздан аны Сәгъди исемле кеше үзенә уллыкка Кырлайга алып китә. Хезмәтчел халкы, бәйрәмнәре һәм табигате белән якыннан танышу, гыйлемгә беренче адымнар ясалган Кырлай авылы аның дөньяга күзе ачыла башлаган җир буларак хәтерендә кала. Әмма биредә дә Габдуллага озак яшәргә туры килми, ике елдан язмыш аны тагын юлга озата. Бу юлы аны Уральск шәһәрендә яшәгән туганнары үзләренә соратып алалар. Башта җизнәсе өендәге хезмәтчеләр янында, аннары мәдрәсәдә ачлы-туклы яшәп гомер кичерсә дә, Уральск Тукайга олы белем һәм иҗат дөньясына юл ача: мәдрәсәдә һәм аның каршындагы рус классында укыганда ул халык иҗаты, татар, рус һәм дөнья әдәбияты белән ныклап кызыксына башлый. Бераздан яшь Тукай үзе дә олы шагыйрьлек юлына аяк баса. «Фикер» газетасын, «Әлгасрел җәдит» һәм «Уклар» журналларын чыгаруда актив катнашып, ул иҗат эшен редакторлык һәм журналистлык эше белән тыгыз бәйләп алып бара. Шундый күпкырлы эшчәнлеген ул 1907 елда Казанга күчкәч тагын да рухланыбрак дәвам итә. Матбугаттагы беренче шигъри чыгышыннан («Голүмең бакчасында», 1905) алып Казанның Клячкин больницасында үлем түшәгендә язылган соңгы шигырьләренә («Буш вакыт», «Мәктәп» һ. б.) кадәр ул үзенең бөтен иҗатын туган халкына хезмәт итүгә, аны милләт буларак саклауга һәм үстерүгә багышлады. Шуңа күрә ул үзе исән вакытта ук милләт шагыйре булып танылды, ә алга таба аның тарихтагы мондый кабатланмас роле торган саен тирәнрәк һәм тулырак ачыла барды.

Безнең көннәрдә, әдәбият-сәнгать, мәдәният үзенең милли асылына кайтканда, Тукай милләткә хезмәт итү үрнәге булып яңа бер көч белән кабат замандашларыбыз сафына баса, аларга юл күрсәтә, рух бирә кебек...

ИСЕМДӘ КАЛГАННАР

(Өзекләр)

I

Минем атам Мөхәммәтгариф Кушлавыч авылында Мөхәммәтгалим исемле мулланың улы булган, карт атасы тере вакытта ук авылыбыз Кушлавычка кайтып, мулла булмыштыр.

Минем туганыма биш ай заман үткәч, атам аз гына вакыт авырып үлгән.

Тол калган анам янында мин берничә вакыт торгач, анам, мине авылыбыздагы Шәрифә исемле бер фәкыйрь карчыкка вакытлыча асрарга биреп калдырып, үзе Сасна исемле авылның мулласына кияүгә чыккан. Мин бу карчык өендә кадерсез, артык бер бала булганлыктан, ул мине әлбәттә тәрбияләмәгән; тәрбияләү түгел, яшь балаларның иң мохтаҗ булдыклары ачык йөзне дә күрсәтмәгән.

Мин үзем ул карчыкта үткән заманның ничеклеген белмим. Ул вакыт мин ике-өч ярым яшендә генә булганмын дип уйлыйм.

Хәзер авылда минем балалык вакытымны күргән карчык вә хатыннар тәрбияче карчыгымның минем илә бик начар мөгамәләдә булганлыгын үземә хикәят итәләр.

Җөмләдән берсе.

Мин кыш көннәрендә төнлә яланаяк, күлмәкчән көенчә тышка чыгам икән дә бераздан, өйгә кермәкче булып, ишеккә киләм икән. Кыш көне авыл ызбаларының ишекләрен ачмак балага түгел, шактый үсмер кешеләргә дә мәшәкать вә көч булганлыктан, табигый, мин ишекне ача алмый вә ишек төбендә аякларым бозга ябышып катканчы көтеп торам икән.

Карчык исә үзенең «Кадалмас әле, килмешәк!» дигән «шәфкатьле» фикере илә мине үзе теләгән вакытта орыша-орыша кертә икән.

Мин бу карчыкта торган вакытта анам да теге муллага үзләшеп җиткән булырга кирәк: ул бервакыт мине үз янына Саснага алдырырга атлар җибәрткән.

Мине бу атлар, әлбәттә, Саснага алып киткәннәр.

Хәер, алып киткәннәр генә түгел, шул атка утырып киткән минутларда миндә, бала булсам да, хәзердә дә атта утырып Саснага барганымны, үземне бер киң вә рәхәт галәмдә хис иткәнемне, юлда барганда күз алдымда әллә нинди нурлар уйнаганын онытмаган шикелле булам.

Саснага барып җиткәнмен. Ничек, ни рәвеш бардым, мине кемнәр каршылады — анысын белмим; ләкин үги этиемнең мине сөюе, миңа чәй янында кәрәзле балны ак күмәчкә ягып бирүе, минем шунда куанганнарым, биш минутлык төш шикелле генә, әле дә булса хәтеремдә.

Ләкин бу рәхәт бик озакка бармаган. Минем анам бу муллада бер ел кадәрме, күпмедер торгач, белмим, нинди авырудандыр вафат булган.

Мин монда әнкәмнең җеназасын күтәреп алып киткәннәрен сизгәч, яланаяк, яланбаш хәлемдә, капка астыннан, үкереп

җылый-җылый, йөгереп чыгып: «Әнкәйне кайтарыгыз, әнкәйне бирегез!» — дип, шактый гына җир мәет күтәрүчеләрдән калмый барганымны хәзер дә хәтерләвемне язамын.

Әни дә үлгәч, мин бөтенләй ятим булып җиткәнгә, мин бу Сасна мулласы өенә дә сыймаганга, ул мулла мине Өчиле авылындагы анамның атасы булган бабайга кайтарып биргән.

Минем анамның анасы булган үз әбием әни кыз чакта ук үлгән булганга, бабай кайсы мулладандыр тол калган бер хатынны аңар ияреп килгән алты баласы илә алган булган.

Өчиле авылы (исеменнән дә мәгълүм) бик кечкенә вә ярлы бер авыл булганга, шуның өстенә мин ятим калган елларда ул вакытларда каты ачлык булганга, бабайның көн күрмеше гаять начар булган.

Менә шул фәкыйрь вә шуның өстенә әллә ничә авызлы булган семья эченә мин ятим бала булып килеп кергәнмен.

Үги әбинең алты күгәрченнәре эчендә мин бер чәүкә булганга, мине җыласам — юатучы, иркәләнем дисәм — сөюче, ашыйсым-эчәсем килсә, кызганучы бер дә булмаган, мине эткәннәр дә төрткәннәр.

Бу семья эчендә фәкыйрьлек шул дәрәҗәгә җиткән булырга кирәк ки, мин хәзер дә булса бабайның күрше баерак авыллардан икмәк сыныклары теләнеп алып кайтканын исемдә тотамын.

Шул рәвешчә көннәр үткән, мин монда торганда чәчәк авыруы белән дә авырганмын, башка әллә нинди хәстәлекләр дә күргәнмен, тәмам зәгыйфьләнгәнмен.

Бу гаиләдә һәммәсе (бер җитеп килә торган Саҗидә исемле кыздан башкасы) минем авыруыма: «Ичмасам чәнчелсә, бер тамак кимер иде»,— дип кенә караганнар.

Мин әле хәзер аерып әйткән Саҗидә апайның, үги әбидән яшереп кенә, мине юатканын вә сөйгәнен, әби килә башлагач та, минем белән эше юк кеше шикелле үзенә икенче кыяфәт биргәнен һаман хәтеремдә саклыйм.

Менә шул вакыттан бирле ул апа минем күңелемә фәрештә булып утырган да калган. Күңелем аны уйлый башлады исә, хәзер күземә ап-ак саф бер фәрештә күренә.

Ни күрсәм дә — күргәнмен, ни булса да — булган, һәрничек мин бу семьяга сыймаганмын. Беркөнне бабай, үги әбинең киңәше илә булырга кирәк, авылыбыздан Казанга бара торган бер ямщикка мине утыртып, Казанга озаткан.

Ямщик Казанга килеп җиткәч (безнең авыл Казаннан 60 кына чакрым), Печән базарында: «Асрарга бала бирәм,

кем ала?!» — дип кычкырып йөргәндә, халык арасыннан бер кеше чыгып, мине ямщиктан алган. Ул мине, бер асрау бала итеп, өенә алып кайткан.

Мин монда торганымны ярты йомык күз белән генә күргән шикелле булам.

Мәсәлән, бервакыт әллә нинди авырудан авырган вакытта, мине бер карчыкка алып барганнарын, ул минем күзгә шикәр салганын, үземнең салдыртмаска азапланганымны, тартышканымны беләм.

Бу яңа ата-анамның хәлен дә бераз язып китим әле.

Миңа әти булганы Мөхәммәтвәли исемле булып, әни булганы Газизә исемле иде. Торулары Яңа бистәдә иде.

Әти талчукта сату итә идеме, әллә тирече идеме шунда — анысын яхшы белмим. Әни, бер дә армый-талмый, байларга кәләпүш эшләп чыгара иде.

Әни Печән базарына кәләпүш чыгарганда яки бер хезмәт илә байларның өенә барганда, кайвакыт мине дә ияртеп баргалый иде.

Мин байлар йорт эченең матурлыгына, идәннән түшәмгә кадәр торган зур көзгеләрен, чиркәү кеби суга торган сәгатьләрен вә сандык кадәр зур органнарын күреп, боларны оҗмахта торалар кеби уйлый идем.

Бервакыт шулай байларга барганда, ишегалдында әллә нинди зиннәтле вә алтынлы койрыгын кояшка каршы ялтыратып йөргән тависны күреп, бигрәк тә сокландым.

Бу ата-анам икесе дә эш кешеләре булдыкларыннан, монда миңа ач торырга тугры килми иде.

Кайчакта әни белән Ташаяк базарына барып, андагы уенчык базарына кызыгып вә самокатларда шатланып-шатланып агач атларга атланган малайларны карап, көнләшеп тора идем.

Мин дә атланыр идем — акчам юк. Әнидән сорарга куркам, ул үзе белеп бирми иде.

Шулай итеп, мин кеше рәхәтенә генә кызыгып кайта идем.

Аннан соң, җәй көне ике бистә арасындагы яшел үлән өстендә малайлар илә каз йоннары куып йөргәнемне, арыгач, Хан мәчетенә юнәлеп ятып, чирәмдә ял иткәнемне бер дә онытмыйм.

Мин бу ата-анамда ике елмы, күпмедер торгач, әти дә, әни дә икесе берьюлы авырый башлаганнар.

Алар, үзләренең үләчәкләреннән куркып: «Без үлсәк, бу бала кем кулына кала, ичмасам, авылына кайтарыйк...» — дип,

теге мине Казанга китергән ямщикны табып, мине янәдән аңар утыртып, Өчиле авылына җибәргәннәр.

Инде миннән мәңгелеккә котылдык дип уйлаган бу семьяның мине ничек каршы алганлыкларын уйлап белергә мөмкин.

Мин кайтып бераз торгач та, әби белән бабай, инде мине шәһәргә җибәрүдән өмид кисеп, кайда булса да бер чит авылга асрарга бирергә уйлашканнар.

Болар Өчилегә килгән һәрбер чит авыл кешесенә үзләрендә асрарга бирергә бер ятим бала барлыгын сөйләгәннәр.

Шулай мәшәкатьләнә торгач, бездән җиде генә чакрым Кырлай исемле авылдан ир баласыз Сәгъди исемле бер кеше килеп, мине үзенә алып киткән.

галәмдә — дөньяда
килмешәк — каян да булса килгән чит кеше
җөмләдән берсе — шулардан берсе
илә — белән
үзләшеп җитү — иялэшеп бетү, читсенмәү
зәгыйфьләнгәнмен — йомшарганмын, көчсезләнгәнмен
өмид — өмет
орган — уен коралы
кеби — кебек
әйттекем — әйткәнем
тавис — кош (павлин)

Сораулар һәм биремнәр.

1. «Исемдә калганнар»ның бу бүлеген тагын нинди кечерәк өлешләргә бүлеп карарга була? Бүлекнең эчтәлеген сөйләү өчен план төзегез.
2. Бүлекнең кайсы урыннары сезгә аеруча нык тәэсир итте? Ни өчен?
3. Габдулла Тукайның тормыш юлы белән танышыгыз. Ул яшәгән төбәкләрнең схемасын сызыгыз. Һәр төбәкнең шагыйрь тормышына йогынтысын ачыклагыз һәм әдәбият дәфтәрләрегезгә языгыз.

II

Бабайлар өеннән чыгып, Сәгъди абзыйның арбасына утырдым. Бабай белән әби (Сәгъди абзыйдан яхшысынмый гына булырга кирәк) мине озатырга чыктылар. Тагы да минем китүемне кызык күргән яланаяклы малайлар да арба тирәсендә йөгергәләп йөриләр иде.

Арба кузгалды. Сәгъди абзый белән без янәшә утырып киттек. Ул юлда миңа: «Менә хәзер Кырлайга кайтып җитәбез, анда әниең каршы чыгып көтеп тора торгандыр. Алла боерса, бездә катык, сөт, ипи күп, теләгәнчә ашарсың»,— дип, миңа барып җитәргә ике-өч кенә чакрым калган бәхетләр илә мине юатып бара иде.

Мин дә, ачык йөзләрне бик күптән күрмәгәнгә күрә, эчемнән бик шатлана идем.

Бу вакыт җәйнең матур чаклары булганга, әтрафтагы яшел чирәмнәр вә урамнар, артык эссе булмыйча, үзенең нурлары белән сөеп кенә торган кояш, икенче яктан, тагы рәхәтләндерәләр иде.

Ниһаять, Кырлайга барып кердек. Сәгъди абзыйның йорты, басу капкасыннан кергәч, күп ерак түгел икән; аз гына баргач, коймасы читәннән булган тәбәнәк кенә салам түбәле бер өйгә туктадык.

Юлда Сәгъди абзый әйткәнчә, вакыйган, минем әни каршы чыккан икән, ул капканы ачты; мине ачык йөз илә каршы алып, арбадан күтәреп төшереп, өйгә дә алып керде.

Тыштагы эшләрен караштыргалагач, атын туаргач, әти дә өйгә керде. Кергәч тә әнигә хитабән: «Хатын, бар, балага катык белән ипи китереп бир»,— дип әмер итте.

Әни дә, шунда ук баздан катык алып менеп, миңа зур гына икмәк телеменең яртысын тоттырды.

Мин исә, Казаннан кайтканнан бирле юньләп аш йөзен күрмәгәнгә күрә, икмәк белән катыкны ялт иттердем.

Тамак туйгач, әнинең рөхсәте илә урамга чыктым. Мин анда чыгып, адашудан куркып, артыма карый-карый гына барадыр идем, менә берзаман тирә-ягымны әллә кайдан килеп чыккан авыл малайлары сарып алдылар.

Алар һәр көн авылның бер башыннан бер башына йөгереп йөреп тә, бу көнгә кадәр мине күрмәгәнгә, аннан соң минем өстемдә Казаннан киеп кайткан каюлы ситсы күлмәк, башымда да мине Өчилегә кире җибәрер алдыннан әнинең, миңа сагынмаклык булсын дип, төрле төсле хәтфәләрдән корамалап ясаган кәләпүше булганга, бу Кырлай малайлары миңа бик гаҗәпләнеп карыйлар иде.

Малайлар карап тордылар-тордылар да таралдылар; мин аларга катыша алмадым, өйгә кереп киттем.

Өйгә кайтып керсәм, анда ике җиткән кызлар күрдем.

Боларның берсе — таза гына гәүдәле, кызыл йөзле, күк күзле, икенчесе — арык кына, сары йөзле генә, култыгында агач таяклары бар, аксак бер кыз иде.

Әни миңа: «Менә болар апайларың: берсе Саҗидә апаең, берсе Сабира апаең, күреш»,— дигәч, мин әкрен генә барып кулымны суздым. Болар Сәгъди абзыйның кызлары булып, аксагы Саҗидә атлы икән.

Шулай итеп, мин монда яхшы гына тора башладым.

Авыл малайлары белән дә таныштым.

Сәгъди абзыйның юлда әйткәненчә, вакыйган, монда катык, сөт күп, шулай ук бәрәңгегә дә ихтыяҗ юк иде.

...Урак вакыты җитте. Әти, әни вә ике апай уракка китә башладылар.

Мин исә уракка бармый идем. Иптәш малайлар илә авыл буенча йөгерә вә болынлыкларда көн буе ауный идем. Әгәр көндез кайвакыт уен арасында карыным ачса, тиз генә өйгә кайтып, ян тәрәзәдән генә өйгә кереп, әнинең минем өлешкә калдырган бер җамаяк бәрәңгесе илә бер телем икмәген ашый идем.

Алар әбәттән (көндезге аш) соң ишекне бикләсәләр дә, минем ашарга кайтасымны белеп, ян тәрәзәне эчтән бикләми китәләр иде.

Урак вакытында бөтен халык һәммәсе эшкә китеп, авылда эшкә ярамаган карчыклардан башка һич кеше дә калмаганлыктан, без бакчалардагы яшел суганнар башына бер дә кәҗәдән ким бәла булмыйдыр идек. Әгәр өй саклаучы карчыклар күрсә, без дәрхаль киртәдән сикереп качадыр идек. Карчык мескеннең орышып, тешен кысып калудан башка кулыннан бер эш тә килмидер иде.

Әгәр уйный торгач тирләсәк, хәзер үземезнең ындыр артындагы кечкенә генә инешкә төшеп, шуннан әллә ничәшәр сәгать чыкмыйча коенып, күлмәк-ыштаннар илә вак балыклар сөзеп ята идек. Күңелле чаклар!

Бервакыт шулай уйнап йөргәннән соңра, кич белән өйгә кайтсам, өй эчендә һәммә кешене күңелсез вә кәефсез күрдем. «Бу нидән икән?»— дип уйлап торгач, Сабира апайның идәннән сәкегә котырган шикелле йөгерүен вә кая барып бәрелгәнен дә белмәвен һәм күзләре әллә нинди коточкыч булып акайганын күргәч, аның урактан «җенләнеп» авырып кайтканын белдем.

Ул төнне өйдәгеләр берсе дә йокламый үткәрделәр. Мин генә, бик йокым килгәч, тыштагы арбага чыгып йокладым.

Иртә белән, таң сызылып килгәндә, колагыма:

«Сабира апаң вафат булды, син йоклап ятасың, тор, тор!» — дигән бер тавыш килгәч, күземне ачып карасам — каршымда әни тора иде.

Бу, билгеле, миңа да гади хәбәр түгел, — йокы тәмле булса да, сикереп тордым.

Шул көнне Сабира апаны җирләделәр. Аны җирләп берничә көн үткәч, әнинең этигә:

— Менә «үксез бала асрасаң, авызың-борының кан итәр; үксез бозау асрасаң, авызың-борының май итәр» шул инде ул; мөгаен, шуның шомлыгыннан булды инде бу! — дип сөйләгәнен ишеткәли башладым.

Андин соң кайчакларда әнинең йә кушкан йомышын тыңламасам, йә жиренә җиткерми эшләсәм, шул сүзне әйткәли торган иде.

Әти белән без бик-бик тату идек. Ул бер дә миңа каты сүз әйтми иде.

Мәсәлән, бервакыт минем Казаннан киеп кайткан күлмәк-ыштаннарым, читек-кәвешләрем, казакиларым тузгач, әти үзенең мин килмәстән бер ел элек үлгән углының күк киндер күлмәге илә бишмәтен миңа бирмәкче булды.

Шунда әни:

— Мин үз улымның төсе итеп саклаган киемнәрне кешегә бирер хәлем юк,— дип, бик озак тарткалашты.

Ахырда әти:

— Йә, хатынланма әле юкка, үзеңнән тумаган бала дип, әллә аны шыр-ялангач йөртерсеңме?— дип, киемнәрне көчләп диярлек миңа алып киертте.

Сораулар һәм биремнәр.

1. Габдулла Тукайны Кырлайда ничек каршылыйлар? Сәгъди абый гаиләсендә кемнәр була?

2. Әсәрдә Кырлай авылы табигате ничек сурәтләнә? Табигатьнең кайсы вакыты сезгә күбрәк ошый? Ни өчен? Тасвирлап сөйләгез.

3. *«Үксез бала асрасаң, авызың-борының кан итәр; үксез бозау асрасаң, авызың-борының май итәр»* мәкаленең әсәрдә кулланылган мәгънәсен аңлатып бирегез.

III

Шулай итеп, урак бетте, көз җитте. Ашлыклар эшен бетергәч, бакчага чыгып, бәрәңге казырга вакыт җитте.

Бу бәрәңге казу вакытында миңа урак вакытындагы кеби уйнап йөрергә туры килмәде: миңа казып чыгарылган бәрәңгеләрне капчыкка тутырырга куштылар. Мин дә үз хезмәтемне яхшы гына эшләдем.

Бу вакыт, көз көненең салкын вакытлары булса да, мин яланаяк идем. Аякларым туңганга, мин аларны балчыкка күмеп утыра идем.

Бервакыт шулай аякны балчыкка күмеп, бәрәңге чүпләгән чагымда, теге бәрәңге казучы аксак Сәҗидә апай ялгыш минем аякка тимер көрәк белән чапты.

Аяк шактый тирән җәрәхәтләнде, мин дә урынымнан сикереп торып, бераз читкә барып утырып егъладым да, соңра җәрәхәткә балчык сибеп, янә хезмәтемдә дәвам иттем; ләкин бу юлы аяклар никадәр туңсалар да, балчыкка күмәргә курыктым.

«Моны ни өчен яздың?» — диерләр.

Ни өчен языйм? Шул вакытта аягым бик авыртканга вә хәзер дә аякта шул җәрәхәтнең эзе булганга тоттым да яздым.

Бара торгач, бакча эшләре дә бетте.

Беркөнне кич белән әти белән әни иртәгә иртүк мине абыстайга укырга илтәчәкләрен миңа мәгълүм иттеләр.

Таң атты, кояш чыкмас борын ук торып чәй эчтек. Чәйне җыештыргач, әни мине кулымнан җитәкләде дә үзебездән биш-алты гына адым булган Фәтхерахман хәзрәт өенә алып барды.

Анда барып кердек. Мине укытачак абыстай кулына чыбык тотып утырган, аның тирә-ягында минем яшемдәге кечкенә кыз балалар күп булганы кеби, шактый җитеп килә торган кызлар да бар иде. Алар арасында, богдай арасындагы берничә борчаклар кеби, берничә минем шикелле ир балалар да бар иде.

Әни иң элек ике бөтен икмәк илә бер тиенме, ике тиенме акчасын абыстайга тоттыргач, алар да, бөтен шәкертләр дә бик озак дога кылдык.

Әни мине тапшырып үзе киткәч, мин кызлар белән бергә «әлеп, би, ти, си, җом, хи»ны, бер дә тартынмыйча, кычкырып укый башладым.

Шул рәвешчә, «әлеп, би, ти, си» не берничә көн такмаклагач, миңа «Иман шарты» да тоттырдылар.

Бу «Иман шарты»ның иҗеге белән сүрәсе миңа кыш буена җитте бугай. Мин бу кышта һаман шул кыска гына «Иман шарты» тирәсендә әйләнүдән уза алмадым.

Фәкать «Иман шарты»н бетерүгә гайләвә буларак, бер-вакыт, абыстай өйдә юк вакытта, бәгъзе шаян кызларның: «Кәлимәтен, тайибәтен, безнең әни бай катын, изүе тулы тәңкә...» — дигән сүзләрен ишеттем.

Ишетелмәгән сүз вә күрелмәгән нәрсә һәрберсе гыйлем булганлыктан, табигый, мин дә бу сүзне яратып отып алдым. Һәм шуны үземнән надан малайлар каршында тәкрарлап, аларны көлдереп йөрер булдым.

IV

Бу Кырлайдагы беренче кышым үтте. Яз җитеп, карлар эри башлады. Озакламый кырлар, игенлекләр тәмам кардан ялангач калып карала башладылар.

Менә бераздан Сабан туе җитте. Мине Сабан туе көнне иртүк уятып, кулыма янчык дәрәҗәсеннән аз гына үткән кечкенә бер капчык тоттырдылар.

Мин, шул капчыкны тотып, авыл буена киттем.

Авыл халкы тегеләй дә иртә торучан булса да, бүген Сабан туе бәйрәме көне булганга, бигрәк тә иртә торганнар вә һәр өйдә, һәркемдә көләч йөз, тәмле сүз иде.

Мин кайсы гына өйгә керсәм дә, минем ятим калган мулла баласы икәнемә игътибарән, миңа, башка малайларга биргән кеби, конфет, бер-ике прәннек кенә бирмичә, һәр йорт иясе дә буяган күкәй бирәләр иде.

Шунлыктан минем капчыгым буялган күкәйләр илә бик тиз тулып, өйгә дә кайтып кердем. Башка малайлар һаман йөреп калдылар шикелле.

Әти белән әни дә минем капчыкның болай тиз тулуына гаҗәпләнделәр дә, шатландылар да.

Ул көнне чәй эчтемме, юкмы — анысын белмим; капчыкны әнигә бирдем дә, үзем, кулыма берничә күкәй тотып, урамга чыгып чаптым.

Мин урамга чыкканда, кояш күтәрелгән, бөтен авыл нурланган, авыл егетләре, авыл кызлары, ак оекларын мөмкин кадәр шомартып киеп, чабата киндерәләрен дә бик тырышып, матурлап бәйләп, урамга чыкканнар иде.

Бер яктан Сабан туе башлыгы да, кулына бер таяк башына чүпрәк таккан әләм тотып, өй саен яулык, ситсы кеби нәрсә җыеп йөри иде. Без — яланаяклы малайлар исә аның артыннан бер дә калмыйча йөгерә идек.

Чүпрәкләр, яулыклар җыелып тәмам булгач, бөтен авыл халкы — хатыны-кызы, баласы-чагасы — болынлыкка төшteләр. Көрәшләр, узышулар башланды. Болынлыкта йөк-йөк белән торган чикләвек, көнбагыш вә кызыл билле ак прәннекләр хисапсыз иде.

Болар арасында егетләр тарафыннан кызларга бирелергә иң муафыйгы, әлбәттә, кызыл билле ак прәннек инде. Чөнки ул прәннек хакында бер авыл җыруы да бар. Болай:

Болынлыкка бөркет килгән,
Куркытадыр казларны;
Кызыл билле ак перәннек
Кызыктыра кызларны.

Атлар да чабышты, малайлар да йөгереште, яулыклар да алынды; шулай итеп, Сабан туе да бетте.

Исемдә юк — бу Сабан туе ничә көн булгандыр, мин бер көнен генә яздым. Бәлки, ул өч-дүрт көн булса да, миңа бер генә көн кеби тоелгандыр.

сарып алдылар — уратып алдылар
сагынмаклык — сагынырлык
корамалап — җыеп
арык — ябык гәүдәле
җамаяк — савыт
дәхаль — шунда ук
вафат булу — үлү, дөнья кую
игътибарән — игътибар итеп, искә алып
әләм — флаг, байрак
муафыйгы — туры килгәне, кулай булганы
җәрәхәтләнде — яраланды

Сораулар һәм биремнәр.

1. Кечкенә Габдуллада Сәгъди абзыйга карата җылы караш кайчан туа? Аларның үзара мөнәсәбәтләре турында сөйләгез.
2. Кырлай авылы мәдрәсәсе Габдуллада нинди истәлекләр калдыра?
3. Кырлайдагы Сабантуй вакыйгасы Габдулла тарафыннан ничек сурәтләнә? Кечкенә хикәя рәвешендә сөйләгез.
4. «Габдулла Тукай» альбомындагы (Казан, 1986) рәсемнәрнең «Исемдә калганнар» белән уртак якларын табып күрсәтегез. Альбомдагы рәсемнәр турында фикер алышыгыз.
5. Шагыйрьнең биографиясе һәм «Исемдә калганнар» әсәре белән танышканнан соң, алар арасындагы уртаклык һәм аермалар турында сөйләгез.

ШҮРӘЛЕ

1

Нәкъ Казан артында бардыр бер авыл — Кырлай, диләр;
Җырлаганда көй өчен «тавыклары җырлай», диләр.
Гәрчә анда тугмасам да, мин бераз торган идем;
Җирне әз-мәз тырмалап чәчкән идем, урган идем.
Ул авылның, һич онытмыйм, һәр ягы урман иде;
Ул болын, яшел үләннәр хәтфәдән юрган иде.
Зурмы, дисәң, зур түгелдер, бу авыл бик кечкенә;
Халкының эчкән суы бик кечкенә — инеш кенә.
Анда бик салкын вә бик эссе түгел, урта һава;
Җил дә вакытында исеп, яңгыр да вакытында ява.
Урманында кып-кызыл кура җиләк тә җир җиләк;
Күз ачып йомганчы һичшиксез җыярсың бер чиләк.
Бик хозур! рәт-рәт тора, гаскәр кеби, чыршы, нарат;
Төпләрендә ятканым бар, хәл җыеп, күккә карап.
Юкә, каеннар төбендә кузгалаклар, гөмбәләр
Берлә бергә үсә аллы-гөлле гөлләр, гонҗәләр.
Ак, кызыл, ал, сап-сары, зәңгәр, яшелдән чәчкәләр;
Һәр тарафка тәмле исләр чәчкәли бу чәчкәләр;
Үпкәлиләр чәчкәләрне төрле төсле күбәләкләр килеп,
киткән булып, тагын да шунда чүгәләп.
Бервакыт чут-чут итеп сайрый Ходайның кошлары;
Китә җаннарны кисеп, ярып садаи хушлары.
Монда бульварлар, клуб һәм танцевальня, цирк та шул;
Монда оркестр, театрлар да шул, концерт та шул.

2

Җәй көнен яздым бераз; языйм әле кыш, көзләрен,
Алсу йөзле, кара кашлы, кара күзле кызларын.
Бу авылның мин җыен, мәйдан, сабаны туйларын
Язмыймын куркып, еракларга китәр дип уйларым...
Тукта, мин юлдин адашканмын икән бит, күр әле;
Әллә ник истән дә чыккан, сүз башым бит: «Шүрәле».
Аз гына сабрит әле, и кариэм! хәзер язам;
Уйласам аулымны, гаклымнан да мин хәзер язам.

3

Билгеле, бу кап-кара урманда һәр ерткыч та бар;
Юк түгел аю, бүре; төлке — җиһан корткыч та бар.
Һәм дә бар монда куян, әрлән, тиен, йомран, поши;
Очрата аучы булып урманда күп йөргән кеше.
Бик куе булганга, монда җен-пәриләр бар, диләр,
Төрле албасты, убырлар, шүрәлеләр бар, диләр.
Һич гаҗәп юк, булса булыр, бик калын, бик күп бит ул;
Күктә ни булмас, дисең, очсыз-кырыйсыз күк бит ул!

гонҗәләр — ачылып бетмәгән чәчәкләр
сабрит — сабыр ит
җиһан — дөнья
шүрәле, албасты, убыр — әкият геройлары

Сораулар һәм бирем.

1. Шагыйрь авыл табигатен ничек тасвирлаган?
2. Кырлай урманында нинди агачлар һәм үсемлекләр үсә? Нинди хайваннар һәм җәнлекләр яши?
3. Бүлекне хикәя рәвешендә сөйләгез.

4

Шул турыдан аз гына — биш-алты сүз сөйлим әле,
Гадәтемчә аз гына җырлыйм әле, көйлим әле.
Бик матур бер айлы кичтә бу авылның бер Җегет
Киткән урманга утынга ялгызы бер ат җигеп.
Тиз барып җиткән Җегет, эшкә тотынган баргач ук,
Кисә башлаган утынны балта берлән тук та тук!
Җәйге төннең гадәтенчә төн бераз салкын икән;
Барча кош-корт йоклаган булганга, урман тын икән.
Шундый тын, яхшы һавада безнең утынчы исә,
Алны-артны, уңны-сулны белмичә, утын кисә.
Балтасы кулда, Җегет эштән бераз туктап тора;
Тукта, чү! Ямьсез тавышлы әллә нәрсә кычкыра.
Сискәнеп, безнең Җегет катып кала аягүрә;
Аңламастан, каршысында әллә нинди «ят» күрә.
Нәрсә бу? Качкынмы, җенме? Йә өрәкме, нәрсә бу?
Коточарлык, бик килешсез, әллә нинди нәрсә бу!

Борны кәп-кәкре — бөгелгәндер тәмам кармак кеби;
Төз түгел куллар, аяклар да — ботак-тармак кеби.
Ялтырый, ялт-йолт киләдер эчкә баткан күзләре,
Кот очар, күрсәң әгәр төнлә түгел — көндезләре.
Яп-ялангач, нәп-нәзек, ләкин кеше төсле үзе;
Урта бармак буйлыгы бар маңлаенда мөгезе.
Кәкре түгелдер моның бармаклары — бик төз төзен,
Тик килешсез — һәрбере дә ярты аршыннан озын.

5

Бик озак торгач карашып, күзне күзгә нык терәп,
Эндәшә батыр утынчы: «Сиңа миннән ни кирәк?»
— Бер дә шикләнмә, Җегет, син; мин карак-угры түгел;
Юл да кисмимен, шулай да мин бигүк тугры түгел.
Гадәтем: ялгыз кешеләрне кытыклап үтерәм;
Мин әле күргәч сине шатлыгымнан үкерәм.
Тик кытыкларга яралгандыр минем бармакларым;
Булгалыйдыр көлдереп адәм үтергән чакларым.
Кил әле, син дә бераз бармакларыңны селкет, и
Яшь Җегет! Килче икәү уйныйк бераз кети-кети.
— Яхшы, яхшы, сүз да юктыр, мин карышмый уйныймын,
Тик сине шартымга күнмәссең диеп, мин уйлыймын.
— Нәрсә шартың, сөйлә, и бичара адәмчек кенәм?
Тик тиз үк уйныйкчы, зинһар, нәрсә кушсаң да күнәм.
— Сөйлием шартымны сиңа, яхшы тыңлап тор: әнә
Шунда бар ич бик озын һәм бик юан бер бүрәнә.
Мин дә көч-ярдәм бирермен, әйдә, иптәш, кузгалыйк,
Шул агачны бергә-бергә ушбу арбага салыйк.
Бүрәнәнең бер очында бар әчелгән ярыгы,
Шул җиреннән нык кына син тот, и урман сарыгы!
Бу киңәшкә Шүрәле дә күнде, килмичә кире,
Китте кушкан җиргә, атлап адымын ире-ире;
Куйды илтеп аузын әчкән бүрәнәгә бармагын,—
Кариәм, күрдеңме инде яшь Җегетнең кармагын!
Суккалыйдыр балта берлән кыстырылган чөйгә бу,
Хәйләсене әкрен-әкрен китерәдер көйгә бу.
Шүрәле тыккан кулын,— селкенмидер, кузгалмыйдыр;
Белми инсан хәйләсен — һич балтага күз салмыйдыр.
Суккалый торгач, ахырда чөй чыгып, бушап китеп,
Шүрәленең бармагы калды, кысылды шап итеп.

Сизде эшне Шүрәле дә: кычкыра да бакыра,
Сызлана һәм ярдәменә шүрәлеләр чакыра.
Хәзер инде Шүрәле безнең Җегеткә ялына,
Тәүбә итә эшләреннән, изгелеккә салына:
— Син бераз кызган мине, коткарчы, и адәм генәм;
Мондин ары үзеңә, углыңа, нәслеңгә тимәм.
Башкалардан да тидермәм, ул минем дустым диеп,
Аңгар урманда йөрергә мин үзем куштым диеп.
Бик авырта кулларым, дустым, җибәр, зинһар җибәр;
Шүрәлене рәнҗетүдән нәрсә бар сиңа, ни бар?
Тибрәнә дә йолкына, бичара гаклыннан шаша;
Шул арада яшь Җегет өйгә китәргә маташа.
Ат башыннан тоткан ул, бу Шүрәлене белми дә;
Ул моның фөрьядларын аслан колакка элми дә.
— И Җегет, һич юк икәндер мәрхәмәт хиссең синең;
Әйтче, зинһар, мәрхәмәтсез! кем син? исмең кем синең?
Иртәгә килгәнче дустлар тәндә җаным торса гәр,
Шул фәлән атлы кеше кысты, диермен сорсалар.
— Әйтсәм әйтим, син белеп кал: чын атым «Былтыр» минем.
Бу Җегет абзаң булыр бу, бик белеп тор син, энем!
Шүрәле фөрьяд итәдер; аудан ычкынмак була
Һәм дә ычкынгач, Җегеткә бер-бер эш кылмак була.
Кычкыра: «Кысты, харап итте явыз «Былтыр» мине,
Аһ, үләм бит, бу бәладән кем килеп йолкыр мине?»
Иртәгесен шүрәлеләр бу фәкыйрьне тиргиләр:
— Син җүләрсең, син котырган, син тилергәнсең,— диләр.
Әйтәләр: «Кычкырма син, тиз яхшылык берлән тыел!
И җүләр! кысканга былтыр, кычкыралармы быел!»

аршын — метр кертелгәнчегә кадәр озынлык үлчәү берәмлеге, 71 см
күнәм — ризалашам, тыңлыйм
кариэм — укучым
инсан — кеше
фөрьяд — зарланып елау
асла — һич тә
мәрхәмәт — яхшылык, игелек, кызгану хисе

Сораулар һәм биремнәр.

1. Шүрәле нинди образ ул? Тормышта очрыймы?
2. Былтыр белән Шүрәленең очрашуы сездә нинди тәэсир калдырды?

3. Егет Шүрәлегә үзенең исемен ни өчен Былтыр дип әйтә?
4. Күренешләр һәм вакыйгаларны сурәтләү матур һәм үтемле булсын өчен шагыйрь нинди сүзләр сайлаган? Шул сүзләр кергән юлларны поэмадан табып укыгыз.
5. Поэманың эчтәлеген тулысынча сөйләгез.

ТУГАН АВЫЛ

Тау башына салынгандыр безнең авыл,
Бер чишмә бар, якын безнең авылга ул;
Аулыбызның ямен, суы тәмен беләм,
Шуңар күрә сөям җаным-тәнем белән.

Ходай шунда җан биргән, мин шунда туган,
Шунда әүвәл Коръән аятен укыган;
Шунда белдем рәсүлемез Мөхәммәтне,
Ничек михнәт, җәфа күргән, ничек торган.

Истән чыкмый монда минем күргәннәрем,
Шатлык белән уйнап гомер сөргәннәрем;
Абый белән бергәләшеп, кара җирне
Сука белән ертып-ертып йөргәннәрем.

Бу дөньяда, бәлки, күп-күп эшләр күрем,
Билгесездер — кая ташлар бу тәкъдирем;
Кая барсам, кайда торсам, нишләсәм дә,
Хәтеремдә мәңге калыр туган җирем.

Ходай — Аллаһы Тәгалә
әүвәл — иң элек, иң башта
рәсүлемез Мөхәммәт — пәйгамбәр, Алланың җирдәге илчесе
Коръән — ислам кануннарын эченә алган һәм шуларны аңлаткан изге китап
аять — Коръән китабыннан өзекләр
сука — авыл хуҗалыгында иң гади җир сөрү коралы (плуг)
тәкъдир — язмыш

Сораулар һәм биремнәр.

1. Шигырьне сәнгатьле итеп укыгыз.
2. Туган авыл, туган җир төшенчәләрен ничек аңлыйсыз?
3. Ни өчен туган җире шагыйрь күңелендә мәңге калачак?
4. «Туган авыл» җырын бергәләп тыңлагыз (Г. Тукай шигыре, А. Монасыйпов музыкасы).

5. Туган җир (туган авыл, шәһәр) турында тагын нинди шигырьләр, җырлар, мәкаль һәм әйтемнәр беләсез? Шул турыда фикер алышыгыз.

КИЧКЕ АЗАН

1

Кичке азан!
Кичке азан!
Моңнар, уйлар
Килә аннан;
Төшә искә
Иске заман,
Хөлусән мөс-
тәмигъ азан.
Фи бәдьиһи
Вә бәгъдә азан.
Күңелне тет-
рәтә, кәән-
нәһү тәсби-
хе рәгъд — азан.
<...>

2

Ханнарга
иреште хизан,
Җылый-җылый
Бирделәр җан:
Сөембикә
дә Чыңгыз хан;
Нә дәүләт кал-
ды да, нә шан!
Һич калмады
Шаннан нишан,
Калды дингә
Дошман ишан!

3

Аһ, ник соң без
Булдык вәйран?
Бөтен дөнья
Калды хәйран,
Гаҗиб, нидән

Бу ханәман
Кисәктән әй-
ләде тайран?!

4

Юк шул без-
ләрдә берләшмәк;
Юк бергә-бер-
гә гөрләшмәк,
Бер җан, бер тән
Булып, һәр неч-
кә серне бер-
гә серләшмәк.
Үтте бездән
Инде дөнья,
Җан бирәбез
Галәлгомъя.
Дөнья! Актык
Сүзне тыңла:
Бәхил бул без-
дән, и дөнья!

5

Сау бул, дөнья!
Инде беттек;
Бетәргә сүз-
не беркеттек;
Вактында җир-
не селкеттек,
Инде беттек,
Инде беттек!

хөлусән мөстәмигъ — ихлас белән тыңланган

фи бәдьиһи вә бәгъдә — башлангычында һәм дәвамында

кәәннәһү тәсбихе рәгъд (рәгыд) — бер-бер артлы күк күкрәгәндәй

хизан — кайгы

нишан — билге, эз

гаҗиб — искитәрлек

ханәман — өй җәмәгате, мал-мөлкәт

әйләде тайран — тузан кебек күккә очты

галәлгомъя — күз йомып, сукырлык белән

Сораулар һәм бирем.

1. Шигырьдә, «Төшә искә иске заман» дигәндә, нинди тарихи чор күздә тотыла?
2. Татар халкының тарихи драмасы әсәрдә нинди сәбәпләр белән бәйләп аңлатыла?
3. Хәзерге татарлар үзләренең үткәненнән нинди сабак алырга тиешләр? Шул хакта әңгәмә корыгыз.

ТАТАР ЯШЬЛӘРЕ

Дикъкатә лаек хәзерге көн татарның яшьләре:
Аңламак, белмәк, тәрәккый, мәгърифәт, хикмәт белән

Әйләнеп һәм нурланып тормакта һәрдәм башлары.
Мондый күрнеш сөйнеченнән инде мин алдан беләм;

Тик болар безгә кирәк диңгез төбе гаувaслары.
Өсттә бу ямьсез болыт баштан китәр, яңгыр явар,

Җиргә рәхмәт күк төшәр яшьләрнең изге касдлары.
Шаулап аккан су булыр тау башлары, тау астлары.

Күк булып күкрәр һавада хөр яшәү даулашлары,
Ялтырар изге көрәшнең хәнҗәре, алмаслары.

Йөрмәсен бәгъре өзек милләт киеп кашсыз йөзек,—
Без аның бик зур фәхерле, чын бриллиант кашлары!

дикъкатә лаек — искә алырга лаек
тәрәккый — прогресс
һәрдәм — һәрвакыт
гаувас — чумып энҗе-мәрҗән эзләүче
касд — теләк, омтылыш
фәхерле — мактанычлы

Сораулар һәм бирем.

1. Шигырьдә сүз кайсы чордагы татар яшьләре турында бара?
2. Шагыйрь үзе күздә тоткан яшьләрнең характерлы сыйфатларын нәрсәләрдә күрә?
3. Бүгенге яшьләргә бу шигырь нәрсә бирә? Шул хакта фикер алышыгыз.

Байназар Әлменов

(1909 — 1976)

Оренбург өлкәсендә туып үскән Байназар Әлменов 1935 елда Казан шәһәренә җитлеккән рәссам буларак килә һәм Татарстан китап нәшриятында эшли башлый. Бөек Ватан сугышыннан кайткач та үзенең яраткан эшен дәвам итә.

Б. Әлменовның төп иҗат юнәлеше — китапларга рәсемнәр төшерү, бизәү. Ул Г. Тукай, Г. Камал һәм хәзерге татар язучыларының әсәрләренә, татар халык әкиятләренә иллюстрацияләр ясый. Аны бигрәк тә Г. Тукай иҗаты кызыксындыра. Тукайның «Шүрәле», «Су анасы» әкиятләренә, «Исемдә калганнар» әсәренә ясалган рәсемнәре аеруча билгеле.

Байназар Әлменов татар халкының күренекле шәхесләре Каюм Насыйри, Габдулла Тукай, Мәҗит Гафури, Галиәсгар Камал, Шәриф Камал, Гадел Кутуй һәм рәссам Харис Якуповларның портретларын иҗат итте.

Аңа 1957 елда Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе дигән мактаулы исем бирелде.

Сораулар һәм биремнәр.

1. Рәссам кем ул? Рәссамнардан кемнәрне беләсез?
2. Үзегез белгән рәссамнарның иҗатлары хакында фикер алышыгыз.
3. Дәреслектә бирелгән картиналарның эчтәлеген аңларга өйрәнегез һәм авторларын хәтерегездә калдырыгыз.
4. Картиналар күргәзмәсенә барып, Татарстан рәссамнары иҗат иткән картиналар белән танышыгыз, тәэсирләрегез турында инша языгыз.

Заһидулла Яруллин

(1888—1964)

Заһидулла Яруллин — үзен музыканың төрле өлкәләрендә сынап караган кеше. Ул — танылган гармунчы, үзлегеннән уйнарга өйрәнгән пианист, «Шәрык» клубы каршында оештырылган беренче музыкаль ансамбль җитәкчесе. Үзешчән композитор-методист, күп кенә җырлар авторы, музыка кораллары көйләүче оста.

Заһидулла Яруллин 1888 елның 12 октябрендә Мамадыш өязе Кече Сон авылында ярлы крестьян гаиләсендә дөньяга килә. Ун яше тулгач, күршеләре Заһидулланы эшкә урнаштыру максаты белән өяз шәһәре — Чистайга алып китә. Заһидулла бер гаиләгә эшкә урнаша, үзенең тырышлыгы, җитезлеге һәм күндәмлеге белән аерылып тора.

1901 елда ул Яр Чаллыга килә һәм чәйханәгә аш өләшүче малай булып урнаша. Шул ук елның көзендә аңа Минзәлә ярминкәсендә булырга туры килә. Монда ул чын җырчыларны, гармунчыларны, скрипкачыларны һәм «бик тә сәер» уен коралларында уйнаучы артистларны күрә. Андагы музыкантлар һәм җырчыларның осталыгы малайны таң калдыра. Шушында алган тәэсирләре йогынтысында ул музыка белән кызыксына башлый. Аның музыкага булган мәхәббәте шул дәрәҗәдә көчле була ки, ул кер юучы рус хатыннарының, алачыктагы тимерчеләрнең эштә көйләгән җырларын качапоса сәгатьләр буе тыңлый ала.

Бөек шагыйрь Габдулла Тукайның үлемен Заһидулла бик авыр кичерә һәм шагыйрь истәлегенә тәэсирле, тирән мәгънәле көй иҗат итә. Башта бу әсәр «Тукай истәлегенә» дип атала һәм инструменталь әсәр буларак языла. Соңрак аңа Тукайның «Өзелгән өмид» (1910) шигыре сайлап алына.

27 яшендә дөньядан киткән шагыйрьнең сагыш-моңы, әрнүле хисләре шигырьдә искиткеч тирән итеп әйтеп бирелгән:

И мөкаддәс, моңлы сазым! Уйнадың син ник бик аз?
Син сынасың, мин сүнәмен, айрылабыз, ахрысы!
Очты дөнья читлегеннән тарсынып күңелем кошы,
Шат яратса да, җиһанга ят яраткан Раббысы.

Алга таба бу әсәр «Тукай маршы» дип йөртелә башлый.

Шул чорда күренекле әдәбият һәм сәнгать әһелләре Г. Камал, Г. Коләхмәтов, Г. Кариев белән еш очрашулар да Яруллинның рухи үсешенә зур гына йогынты ясыйлар. «Сәйяр» труппасының музыкаль ансамблендә пианист һәм җитәкче булып эшләү дә аңа тәэсирсез калмаган, әлбәттә.

Беренче империалистик сугыш башлангач, 1916 елда Заһидулла Яруллинны фронтка алалар, үпкәсенең сәламәт булмавы аркасында, озакламый аны армия хезмәтеннән азат итәләр. Ул Казанга әйләнеп кайта. Революциядән соң Казан гарнизонының хәрби коллегиясе каршындагы драма труппасының катнаш оркестрына даими эшкә урнаша. Биредә ул, үзенә электән таныш булган «Сәйяр» труппасы белән бергә, Казан тирәсендәге мөселман хәрби частьларында концертлар куя, чыгышлар ясый.

1934 елда, сәламәтлеге бик нык какшау сәбәпле, Заһидулла Яруллин туган авылы Кече Сонга кайта һәм гомеренең ахырына хәтле шунда яши. Биредә ул авылдашлары өчен гармуннар ясау һәм төзәтү белән мәшгуль була. Билгеле инде, иҗат эше белән дә шөгыльләнә.

Заһидулла Яруллинның «Вальс», «Колхозчылар җыры», «Элегия», «Авыл көе» кебек музыкаль әсәрләре бүгенге көндә дә милләтебезнең йөзек кашы булып санала.

Татар халкының бөек шагыйре Г. Тукай вафатына Заһидулла Яруллин үлемсез «Тукай маршы» белән җавап бирсә, аның улы — композитор Фәрит Яруллин, Тукай әкиятләренә нигезләнеп, атаклы «Шүрәле» балетын иҗат итте.

Хәзерге вакытта Яруллиннар гаиләсенең музыкаль традицияләрен төпчек уллары — Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, Муса Җәлил исемендәге Республика бүләге лауреаты, композитор Мирсәет Яруллин дәвам иттерә.

Заһидулла Яруллин 1964 елда вафат була. Кабере — Мамадыш районы Кече Сон авылында.

Фәрит Яруллин

(1914—1943)

Фәрит Заһидулла улы Яруллин 1914 елның 1 гыйнварында Казанда туа. Фәриткә музыка сәнгатенә мәхәббәт уятуда әтисе — Заһидулла Яруллинның роле зур була. Аның ярдәмендә ул өч ел эчендә фортепианода оста итеп уйнарга өйрәнә. Инде чын-чынлап профессиональ музыкаль белем алырга кирәк була. 1930 елда ул Казан музыка техникумының виолончель классына укырга керә, бер үк вакытта махсус фортепиано классында да укый.

Ләкин яшь музыкант техникумда уку белән генә чикләнеп калмый, Казанда барган музыкаль тормышта актив катнаша: кинотеатрларда әтисе урынында еш кына пианист булып эшли, үзешчән хор түгәрәгенә җитәкчелек итә, концертларда җырчыларга аккомпаниатор була. Техникумны тәмамлагач, Мәскәү консерваториясе каршындагы Татар опера студиясендә композиторлык белемен үстерә.

Композитор өчен кирәк булган белемнәрне Фәрит профессор Генрих Ильич Литинскийдан ала. Аның классында халкыбызның сөекле композиторы Салих Сәйдәшев тә укый.

Ул студиядә укыганда ук фортепиано белән виолончель өчен соната, кыллы квартетын һәм симфониясенең беренче кисәген, романслар яза. Тематикасы һәм музыкаль төзелеше ягыннан төрле-төрле булсалар да, бу әсәрләрнең барысында да Фәрит Яруллин иҗатына хас үзенчәлекләр: тормышка мәхәббәт, шат күңеллелек бар.

1939 елда Фәрит Яруллин, бөек шагыйрь Габдулла Тукайның «Шүрәле»сен нигез итеп алып, зур күләмле музыкаль әсәр язарга керешә. Башта ул нәрсә килеп чыгасын үзе дә белми. Бервакыт дуслары Муса Җәлил, Әхмәт Фәйзи, Нәҗип Җиһанов белән күрешеп сөйләшкәннән соң, ул бу сюжетка балет язарга кирәк дигән ныклы карарга килә. Тиз арада сценарийның

планы төзелә: шагыйрь Әхмәт Фәйзи зур теләк белән либретто язарга алына, һәм Фәрит музыка язарга керешә.

Сюжетның кызыклы булуы композиторга дәрт һәм илһам бирә. Ул, бөтен күңеле белән бирелеп, булачак балетның аерым сәхнә күренешләрен бер-бер артлы иҗат итә. 1941 елның август аенда Мәскәүдә булачак татар әдәбияты һәм сәнгате декадасында Фәрит Яруллинның «Шүрәле» балетын куярга тәкъдим ителә. Әмма Бөек Ватан сугышы башланып китү декадага әзерлекне кинәт өзә. Композитор Фәрит Яруллинга да дәртләнеп иҗат иткән, инде тәмамланган балетыннан аерылырга туры килә.

1941 елның ахырында, хәрби училище тәмамлап, Яруллин кече лейтенант исемен ала һәм фронтка китә. Фронт тормышы аны чыныктыра, үз-үзенә һәм Ватанга нык ышанган, хак эш өчен көрәшче итеп тәрбияли.

Композиторның гомере 1943 елның 17 октябрендә, иҗаты һәм таланты яңа шаулап чәчәк аткан вакытта, рәхимсез сугыш кырында өзелә.

Сораулар һәм биремнәр.

1. Заһидулла Яруллин турында сөйләгез. Аның беренче уңышлы әсәрен атагыз. Ул әсәрнең язмасын тыңлагыз.
2. Фәрит Яруллин кем ул? Аның сәнгать дөньясына ничек килүе турында сөйләгез.
3. Композиторлар Заһидулла, Фәрит һәм Мирсәет Яруллиннар иҗат иткән нинди әсәрләрне беләсез?

«ШҮРӘЛЕ» БАЛЕТЫ

БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Төн. Урман караңгы. Болытлар арасыннан тонык ай нуры сирпелеп китә. Ябалдашын күккә сузган йөзәр яшьлек агач кәүсәләре каралып, куркыныч булып күренә. Урман ешлыгында, корыган зур агач куышында чытырманлык патшасы Шүрәле яши.

Урман аланына яшь егет Былтыр чыга. Очып барган кошларны күреп, ул аларга җәядән ата һәм агачлар арасына кереп югала.

Кинәт колачлы имәннең бер ботагы җанланып куя. Шүрәле икән! Ул аланга чыга. Аның тирәсенә урмандагы җен-пәриләр җыйнала һәм үзләренең биюләре белән хакимнең күңелен ачарга керешәләр. Кояшның беренче нурлары күренү белән, барлык җен-пәриләр үз өненә кереп кача.

Аланга кошлар төркеме очып төшә. Урман суында коенып, канатларын салып ташлаганнан соң, алар кызга әвереләләр. Араларында чибәр кыз Сөембикә дә бар. Гамьсез генә шаярып, уйнап-көлеп йөрүче бу кызлар, үзләрен мәкерле Шүрәле күзәтәдер дип, башларына да китермиләр. Шүрәле, мыштым гына килеп, Сөембикәнең канатларын урлый. Куркытылган кызлар шундук суга ташланалар һәм, кошка әверелеп, кабат очып китәләр.

Сөембикә генә өметсезлек белән алан уртасында бәргәләнә, очып китәр өчен канатларын эзли. Шүрәле корбанының куркып калуыннан һәм көчсезлегеннән тәм таба, аны үз өненә өстери. Шулвакыт Былтыр күренә. Ул кызны коткара, һәм егет белән Шүрәле арасында көрәш башлана.

Былтыр, урман пәриенең мәкерен сизеп, хәйләгә керешә: Шүрәледән җирдә яткан бүрәнәне күтәрешергә ярдәм сорый. Былтыр бүрәнәдәге чөйне суырып чыгара. Шүрәленең озын бармаклары ярыкка кысылып кала.

Кыз-кош үзенең коткаручысы белән канатларын эзли, өметсез хәлдә үләннәр өстенә ава һәм ачынып елый. Күз яшьләреннән һәм куркудан газапланып, йокыга да китә.

Былтыр йокыга талган Сөембикәнең гүзәллегенә таң кала, аннары кадерле табышын, кулларына сак кына күтәреп, урманнан чыгып китә.

Акылына килгән Шүрәле үрмәләп аланга чыга. Ул, үч алачагын белдереп, егеткә куркынычлы яный.

ИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Былтырның бәйрәмчә бизәлгән ишегалдында кояш балкый. Авыл халкы Былтыр белән Сөембикәнең туена җыйнала. Яшьләр, картлар, бала-чага шатланып күңел ача.

Өлкәннәр Былтыр белән чибәр Сөембикәне тантаналы рәвештә ярәшәләр. Әмма кызның уйлары еракта. Ул югалган канатларын сагына. Кәләшенең күңелен күтәрү өчен, Былтыр егетләрне үзе тирәсенә чакыра, һәм алар дәртле бию

башкаралар. Уен-көлкенең чиге юк, тик Сөембикә һаман да күңелсез.

Төн якынлаша. Кәефле кунаклар таралыша башлый. Берәүгә дә сиздермичә, ишегалдына Шүрәле керә. Караңгы почмакларга кача-поса, ул кунакларны куркытып йөри.

Сагышлы Сөембикәнең ялгыз чагын туры китереп, Шүрәле аңа канатларын ыргыта. Кыз-кош, очасы килүдән дулкынланып, аларны күкрәгенә кыса һәм аптырауда туктап кала: аңа Былтырны калдырып китү дә кызганыч. Әмма зәңгәр киңлекләргә очасы килү теләген җиңү мөмкин түгел. Һавага күтәрелгәч, Шүрәле фәрманы белән, аны шундук кара каргалар көтүе уратып ала.

Куркынган кунаклар Былтырны чакыра. Ул ишегалдына йөгереп чыга һәм кара божра уртасында талпынучы гүзәл аккошны күрә. Кулына факел тотып, Былтыр капкага ташлана һәм төн караңгысына кереп югала.

ӨЧЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Шүрәле өне күренеше. Сөембикә яңадан биредә — урман пәрие әсирлегендә. Шүрәле юкка гына кыз-кошның холкын үзгәртергә тырыша, ул аңа әйләнеп тә карамый.

Шүрәле чакыруы буенча тирә-яктан урмандагы кара көчләр җыйнала. Кыз-кош урман хакименә нәфрәт белән карый. Шүрәленең ачуы чыга. Өзгәләп ташласыннар өчен, ул аны җен-пәриләр карамагына тапшыра... Карга баласы очып килә. Ул Шүрәлегә Былтырның якынлашып килүен хәбәр итә. Шүрәле җиргә ятып тыңлый: еракта — куәтле адымнар тавышы...

Аланга факел тоткан Былтыр йөгереп чыга. Шүрәле һәм аның иярченнәре егеткә ташлана. Хәлиткеч көрәштә Былтыр Сөембикәне явызлар кулыннан тартып ала һәм җен-пәриләр оясына ут төртә. Былтыр, соңгы көчен җыеп, Шүрәлене ут эченә ташлый.

Тирә-юньдә ялкын дәрьясы. Былтыр кызга канатларын суза һәм урманнан тизрәк очып китәргә куша. Ул биредә ялгызы үләргә әзер. Ләкин кыз егетнең теләген үтәүдән баш тарта. Яратканга күрә, ул Былтырны калдырып китә алмый.

Янгын сүнә. Мәхәббәтнең илаһи көченә сокланудан барча табигать яшәрә, чәчәк ата. Сөембикәсен күтәреп, Былтыр урман эченнән чыга.

* * *

«Шүрәле» балетының иң характерлы һәм мөһим билгесе — аның катлаулы музыкаль үсешкә корылган булуында. Әсәрнең увертюрасы безне зур, каршылыклы, давыллы-романтик дөнья белән очрашуга әзерли. Аннары урман — тын, салмак, ягымлы музыка. Автор урманны искиткеч төгәл штрихлар, нюанслар белән җанландыра: чык тамчылары коелу, иртәнге кояш нурларының яфракка килеп кагылуы, кошлар сайравы һәм башка шундый сурәтләр аермачык күз алдына килеп баса. Балетның беренче өлешләрендә үк — Шүрәле, Былтыр һәм Сөембикә кичерешләре алгы планга чыга, киеренкелек көчәя...

Шүрәле баштарак йокысыннан торганда юаш, салмаграк төсмерләр белән тасвирланса, тора-бара буяулар куера. Үткен, чәнечкеле, ватык-сыник шыксыз авазлар һәм сәер интонацияләр аның иләмсез һәм мәкерле булуы турында сөйли. Сөембикә белән очрашу күренешендә музыка урман пәриенең масаючан, корбаны өстеннән тантана итәргә яратучан табигатен ачып сала. Былтыр белән көрәш вакытында бу темага инде янау, дәһшәт авазлары килеп керә.

Былтыр баштарак эчкерсез, саф күңелле, йомшак табигатьле егет буларак күз алдына килеп баса. Шүрәле белән беренче көрәшендә үк музыкада аның тәвәккәллек, көчсезне яклау кебек күркәм сыйфатлары өскә калкып чыга. Аның Сөембикәгә булган мәхәббәте моңлы, сыгылмалы аһәң, якты төсләр белән сурәтләнә. Азакта инде Былтыр явыз көчләргә каршы көрәшүче ир-егеткә, җиңүчегә әверелә. Музыканың бу өлешенә күтәренкелек, киң сулыш хас. Яхшылык явызлыкны җиңәргә тиеш — Былтыр образыннан үсеп чыккан шушы төп фикер балетның азагында кешелекле гимн булып яңгырый.

Сөембикә образы музыкага гына түгел, балетның хореографик тукымасына да өр-яңа бизәкләр алып килә. Ул — теләгән чагында кызлар кыяфәтенә керә ала торган irekle кош — аккош, табигать баласы, яшьлек, гүзәллек, нәфислек гәүдәләнеше. Шүрәле белән Былтыр тартышкан вакытта музыкада аның кичерешләренә дә урын бирелгән: куркып калу, ялвару, тетрәнү төсмерләре. Кыз-аккошның Былтырга булган мәхәббәте, кешеләр арасында калыргамы-юкмы дигән халәте каршылыклы — ул моңая, сагышлана. Менә шушы каршылыкны җиңгәч кенә, Сөембикә темасының ритм һәм

интонациясе үзгәрә. Халыкчан бию көйләре, якты һәм шат күңелле моңнар мәхәббәт хисенең көче турында сөйли.

Йомгак ясап шуны әйтәсе килә: намуслы композитор һәм солдат буларак, Фәрит Яруллин үз гомерен иҗатка, Ватанын саклауга бирде һәм тормышта үлемсезлек яулады. Ул тормышны һәм кешеләрне яратты, алар өчен яшәде һәм моңнарын да халыкка калдырды.

Сүзләрнең мәгънәләрен үзләштерегез:

Либретто — зур музыкаль әсәрнең (опера, оперетта, оратория һ. б.) сүз белән бирелгән тексты.

Сценарий — кинофильм иҗат итү өчен махсус яраклаштырылып язылган әдәби әсәр.

Сюжет — матур әдәбиятта эчтәлекнең нигезе, әсәрдә бирелгән вакыйгалар; сынлы сәнгатьтә сурәтләү предметы.

Фатих Әмирхан

(1886—1926)

XX гасыр татар әдәбиятының күренекле вәкилләреннән берсе булган Фатих Әмирхан (Мөхәммәтфатих Зариф улы Әмирханов) 1886 елның 1 гыйнварында Казанда мулла гаиләсендә туа. Искерәк карашлы кеше булса да, Зариф мулла үз балаларын аң-белемле итәргә тели. Шул сәбәпле Фатихны үз чорында Казанда танылган «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенә укырга бирә. Анда булачак әдип динне өйрәнү белән бергә, үзлегеннән тырышып, бай дөньяви белемнәр дә ала. Мәдрәсәдә укыган елларында Фатих ул вакытта шактый көчәйгән шәкертләр хәрәкәтенә катнашып китә, бераздан бу хәрәкәтнең җитәкчеләреннән берсенә әверелә, мәдрәсәләрдәге искергән тәртипләрне тәнкыйтьләүче «Мәгариф» һәм «Тәрәккый» дигән кульъязма газета һәм журнал чыгаруны оештыра.

«Мөхәммәдия» мәдрәсәсен тәмамлагач, Фатих Петербургта һәм Мәскәүдә төрле курсларда рус телен һәм әдәбиятын өйрәнә. Шушы елларда ул иҗат эше белән дә шөгыльләнә башлый. Аның беренче иҗат адымнары публицистика белән бәйләнгән. Моңа Ф. Әмирханның 1907 елда Мәскәүдәге «Тәрбиятел-этфаль» («Балалар тәрбиясе») журналында җаваплы сәркатип булып эшләве сәбәп булгандыр, мөгаен. Журнал битләрендә аның балалар өчен язылган фәнни-популяр мәкаләләре, атаклы балалар язучысы Г.-Х.Андерсен әкиятләренең ул эшләгән иркле тәрҗемәләре дөнья күрә.

1907 елның апрелендә Казанга кайтып, «Әльислах» исемле газета чыгару мәшәкатьләре белән дәртләнеп йөргәндә, Ф. Әмирхан зур бәхетсезлеккә очрый: аның ике аягы да

гомерлеккә хәрәкәтсез кала. Әмма зур ихтыяр көченә ия булуы аркасында, ул әлеге бәла-казага бирешми, киресенчә, хәзер тормышта үзенең төп өметен иҗатта күреп, бу эш белән тагын да ныграк шөгыльләнә башлый. «Әльислах», «Ялт-Йолт», «Вакыт» кебек газета-журнал редакцияләрендә эшләү белән бергә, Ф. Әмирхан 1907—1917 елларда татарның заманча кыю фикерле прозаигы, драматургы, публицисты һәм әдәби тәнкыйтьчесе булып таныла. Аның күп санлы хикәяләре, «Фәтхулла хәзрәт» һәм «Хәят» повестьлары, «Урталыкта» романы, «Яшьләр» һәм «Тигезсезләр» пьесалары, публицистик һәм тәнкыйть мәкаләләре, үзләрендә шул чордагы идея-эстетик эзләнүләрнең мөһим юнәлешләрен чагылдырулары белән бергә, әдипне узган гасыр башындагы милли-әдәби яңарыш хәрәкәтен әйдәп баручы көчләрнең берсенә дә әвереләр.

Авыру хәлдә дә милләт мәнфәгатьләрен кайгыртып яшәгән Ф. Әмирхан 1917 елгы Февраль һәм Октябрь революцияләрен туган халкына, ниһаять, ирек һәм бәхет алып килер дигән өмет белән каршылый.

Билгеле, әлеге революцияләр тәэсирендә әдиптә тормышта һәм кешеләрдә күзәтелә башлаган үзгәрешләргә тәнкыйтьчел караш та туа. Шул нигездә аның «Март каһарманы» хикәясе белән «Шәфигулла агай» повесте языла. Аларның һәркайсы егерменче еллар башы әдәбиятында идея проблематик яңалыгы белән аерылып тора. Революция тудырган үзгәрешләргә башка күп кенә язучылардан аермалы буларак, тәнкыйть күзлегеннән карап, Ф. Әмирхан аларның һәм тормышта, һәм кешеләр арасында тискәре күренешләр хасил итүен ача. Нәтиҗәдә бу әсәрләр үткәндәге революцион үзгәртеп корулар заманын татар әдәбиятында тәнкыйтьчел рухта яктыртуның беренче үрнәкләре булып тарихка керделәр.

МАРТ КАҺАРМАНЫ

(Язылган вакытта шарж иде, октябрь ахырында фактка әйләнде)

(Өзекләр)

Гыйсмәтулла болай да төче кеше иде. Әмма бу көн, йокысыннан уянганда, ул, тагы да төчерә төшеп:

— Җаным, бәгырем, рабучий туганым! — дип уйлап, бөтен җан вә тәне белән төчеп уянып китте.

1917 елның 4 мартыннан бирле инде ул тәмам социалистка әйләнеп беткән һәм Николайның тәхеттән ваз кичү манифестын укыгач та үзен коточыргыч бер революционер һәм ярлы халык өчен гаять кирәкле бер социалист итеп утыртып куйган иде. Сөйләгәндә дә ул:

— Без, революционерлар, җанымыз-канымызны фида итеп халыкка хөррият алып бирдек. Без, социалистлар, фәкыйрь халыкны якты көнгә җитәкләп чыгардык! — дип кенә сөйли башлый. Ачуы килгән кешеләрне «кан эчүче буржуйлар» дип кенә сүгә иде. Хәтта үзенең ак якасын да ул бер мәртәбә тиз каралганлыгы өчен «кан эчүче буржуй, проклятый» дип сүкте.

Гыйсмәтулла менә ике көн инде бер митингтан икенчесенә йөри, андагы хатибларны бик ихлас белән тыңлый, аларның кайбер сүзләрен вә җөмләләрен ләфызлары белән хәтерендә калдырып, шул сүзләр вә шул җөмләләрне татарчага тәрҗемә итеп кенә сүз арасына кыстырып җибәрә иде вә хәтта бер мәртәбә шул сүзләр вә шул җөмләләрдән укмаштырып бер гәзитәгә бер мәкалә дә язып җибәрде. Митингта сөйләгән хатибларның кайберләре аңар хосусый сурәттә тантаналы тәэсир итәләр. Кайберләре исә әллә ничек кызыктыргыч вә кымырҗыткыч тәэсир калдыралар иде. Хосусән әле революциядән соң гына төрмәдән азат ителгән пеләш башлы, киң маңгайлы бер социалист-революционерның бер нотыгы аңар зур тәэсир калдырган иде. Ул революционер:

— Без, ихтилялчылар, халыкны мөсават вә гадәләт юлына хезмәт итүгә чакырамыз... Без, демократия хәрәкәтенең башында торучылар, халыкны әле галәбәгә ирештек дип тынычланмаска, бәлки революцияне дәвам иттерү өчен кирәк булачак фидаларга хәзер булырга өндимез...— дигән иде. Митинг җәмагасы аны бик тәбрик иткән вә кулларында күтәреп йөрткән иде.

«Без ихтилялчылар», «без демократия хәрәкәтенең башында торучылар» дигән сүзләр Гыйсмәтулланы кыздыра вә кымырҗыталар, халык тарафыннан шулай тәбрикләр күрү һәм кулларда күтәрелеп йөрү аның әллә ничек шулай «демократия хәрәкәтенең башында торучы» буласы килү хисен кузгаталар иде. Ләкин шуның белән бергә, Гыйсмәтулла бу революционерның нотыгында гаеп, зур җитешмәгәнлек таба. Аның һаман әле халыкны корбаннарга өндәп, бер дә революциядән туачак «дөнья җәннәтен» күрсәтмәвен, аның акылсызлыгы ук түгел, бәлки бик үк сизгер түгеллегенә хәмел итә иде...

5 мартта иртә белән йокысыннан уянганда, Гыйсмәтулла:

— Җаным, бәгырем, рабучий туганым! — дип уйлап, бөтен җан вә тәне белән төчеп уянып китте.

— Җаным, бәгырем, рабучий туганнарым, җаным, бәгырем, крәстиян туганнарым, һай җаннарым, бәгырьләрем! — дип, берничә мәртәбәләр тәкрар итте. Бу сүзләрне әйткән саен ул үзендә татлы тамыр капкач кына була торган төчелек шикелле бер төчелек сизә иде. Бу төчелек бара торгач шулкадәр куәтләнеп китте ки, бервакыт Гыйсмәтулла:

— Әмма шул рабучий яки крәстиян туганны очратсам, бер суырып үбәр идем соң!— дип тә уйлап куйды.

Гыйсмәтулла, сигез сәгатьлек эш көненең иң төче тарафдары булса да, үзенең көненә бер генә сәгатьлек тә мөгаен эше булмаганлыктан, башка көннәрне ул йокы урыныннан ашыгып тормый иде. Ләкин ул бу көн болай иркенләп ятмады: өч көн өзлексез митингларга йөргәннән соң, инде ул үзендә социалист һәм революционерлыкта бик зур хәзерлек вә бик зур белем җыелганлык хис итә вә, шул хәзерлек вә белемне халык белән уртаклашыр өчен, мөселманнарга махсус ясалган берәр митингта бик шәп нотык сөйләргә тели вә кымырҗынып йөри иде.

— Мин сөйләсәм бу иске социалистлар шикелле генә сөйләмәм, рабучий һәм крәстиян туганнарга нәрсәләр вәгъдә итәсен үзем белермен...—дип уйланып, Гыйсмәтулла тиз-тиз генә чәй эчте дә берәр җирдә митинг булмас микән дигән фикер белән урамга чыкты.

Урамнан печән йөге белән русмы, чувашмы икәнлеге мәгълүм түгел бер крәстиян үтеп бара. Йөген бик ялкау тарта торган ябык атын чыбыркы белән кыйный-кыйный, һәртөрле кәгазь өстенә язылырга ярамый торган сүзләр белән сүгә иде.

Гыйсмәтулла бу күренештән гаять төчеп китте:

— Крәстиян туган икән, җаным, бәгырем... Нинди сүгенә, багалмам... Аты, мәлгунь, провокатор булырга кирәк, кан эчүче буржуйлар янында булып, былбылымның нерваларын бозып бетерә...— дип уйлап, ихтирам белән елмаеп, печәнчегә озак карап торды вә аннан соң эшләпәсен алып, ихтирамлы бөкрәебрәк, агайны сәламләде:

— Здравствуйте, мой милый, родной крестьянин, моя душа и печень, и соловей мой!

Бу эшне иплә кенә эшләп бетергәч, Гыйсмәтулла икенче ягына борылса, ни күзе белән күрсен, иске генә тужурка вә колаксыз гына бүрек кигән бер кеше килә. Гыйсмәтулланың

йөрәге еш-еш тибә башлады. Ул үзендә бертөрле кәефле каушанкырау хис итте.

— Эшче туган булырга кирәк!..

Моны ничек итеп каршы алырга, моңа ничек итеп үзенең тәгъзыйм вә мәхәббәтен изһар итәргә, әлхасыйл, социалист булган кешегә лазем булган рәвештә ничек итеп моның белән очрашырга кирәклек мәсьәләсен шушы берничә секунд эчендә хәл итеп өлгерергә тиеш иде.

Бераз каударланыбрак, бераз каушабрак, Гыйсмәтулла тротуарның уртасына килә торган кешенең юлы өстенә басты да, ихтирамлы вә тантаналы елмаеп:

— Әссәламегаләйкем, рабучий туган, хөррияте шәрифләр мөбарәк булсын, багалмам, без, революционерлар, сезгә нинди якты көннәр алып бирдек! — дип, аны кысып кочаклап алды һәм бит уртасыннан суырып үпте. Бу кеше рабучий ук түгел, бәлки акчаны бик тырышып, бер тиенләп җыеп торучы бер урам кибетчесе иде. Ләкин шулай да аптырамады, Гыйсмәтулланың үзен кочаклап алды:

— Илаһи амин, иптәш... Шулай бергә-бергә халыкка хөррият алып бирдек инде... Мин үзем рабучий дип рабучий ук булмасам да акчаны эшләп таба торган бик социалист кеше,— диде.

Бу кибетче Гайфулла исемле иде. Ул да инде 4 марттан бирле социалист вә, урам чатларында городовойлар күренми башлаганнан бирле, гаять тә революционер кеше иде.

Ике «революционер туган» гәпләшеп киттеләр. Гыйсмәтулла кан эчүче буржуйларны сүкте. Гайфулла буржуй булып фәкыйрь халыкның канын эчкәнлекләре өчен докторларны да тетеп сүгеп алды: әле моннан бер атна гына әүвәл бер доктор аннан визит өчен өч сум алган иде.

шарж — көлү, карикатура
төчерә — төчеләнә
фида итеп — корбан итеп
проклятый — каһәр суккан, йөзе кара
хатиб — оратор
ләфыз — сүз
ихтилялчы — революционер
мөсавәт вә гадәләт — тигезлек һәм гаделлек
галәбә — җиңү
митинг җәмагасы — митинг халкы
хәмел итә — юрый
тәкрар итте — кабатлады
тәгъзыйм вә мәхәббәтен изһар итәргә — хөрмәтен һәм мәхәббәтен күрсәтергә
лазем — тиеш
хөррияте шәрифләр мөбарәк булсын — изге ирекләр котлы булсын
Илаһи амин — Алла кабул итсен

Сораулар.

1. Хикәядә кайсы вакыттагы вакыйга сурәтләнгән?
2. Ни өчен Гыйсмәтулланың митингта чыгыш ясыйсы килә?
3. Гайфулла ни өчен доктор-табибларны сүгә?

II

Безнең каһарманнар барып җиткәндә, митинг инде башланган, нindидер бер ач яңаклы студент җир хакында нәрсәдер сөйли, әллә нинди цифрлар китерә иде. Гыйсмәтулланың бу студентка ачуы килде. Аның әледән-әле муниципализация дигән шикелле сүзләрне катыштыруы аңар кан эчүче буржуйлык шикелле, кадетлык шикелле тоела башлады. Бу гына бер хәер иде, студент бервакыт әллә нинди цифрлардан соң национализация земли дигән сүзне ычкындырмасынмы! Гыйсмәтулла чыдамады, сикереп урыныннан торып:

— Кан эчүче, буржуй, долой! Долой! — дип кычкыра башлады. Моның артыннан Гайфулла да торды... Ләкин, боларның һәр икесенең тәгаҗҗебенә каршы, башкалар боларга иярмәделәр генә түгел, бәлки кул чаптылар. Боларның тавышларын басу чараларына керештеләр.

Залда тавыш басылгач, студент тагы сүзен дәвам иттерде. Тагы әчпошыргыч цифрлар китерә башлады һәм шул цифрлар арасында «социализация земли» дигән сүзне кыстырды. Моны ишеткәч, Гыйсмәтулла тагы чыдамады, урыныннан сикереп торып кул чабарга, «Браво!» дип кычкырырга тотынды һәм, Гайфуллага карап:

— Без «Долой!» дип кычкыргач, малай «нациализм» дигән сүзләреннән тәүбә итеп, социализмга кайтып өлгерә алмый! — дип куйды.

Гыйсмәтулла митингка кергәч тә, үзен дә хатиблар тәртибенә яздырып куйган иде. Митинг үз тәртибе белән дәвам итә, нәүбәт Гыйсмәтуллага да якынлаша, ул исә үзе әйтәсе сүзләрне һичбер хатиб тарафыннан әйтелмәгәнлегенә шатланып, нәүбәтне сабырсызлык белән көтә иде. Менә бервакыт нәүбәт җитте дә. Гыйсмәтулла тамагын кырды, тагы бер кырды һәм тагы бер кырды да төче генә тавыш белән башлап та җибәрде:

— Җаннарым, бәгырьләрем, рабучий туганнарым һәм крәстиян туганнарым...

Гыйсмәтулла әллә ничек бераз каушап китте, аның әйтәсе сүзләре хәтеренә килми иде. Ләкин туктап торыр хәл юк:

— Әйе, җаннарым, туганнарым... тутый кисәкләрем, рабучий һәм крәстиян кардәшләрем... багалмаларым, бәгырьләрем... Минем әйтәсе сүзем шул, сандугачларым, крәстиян туганнарым... Кан эчүче буржуйлар сез былбылларымның каннарын эчәләр... итләрен ашыйлар... телем-телем турап ашыйлар...

Боларны әйтеп торганда, инде Гыйсмәтулланың башы әйләнгән шикелле була башлады. Әйтәсе шәп сүзләренең һәммәсе баштан очып беткәннәр иде. Ләкин туктап торыр хәл юк:

— Әйе, сез тутый кошларымның майларын эретеп эчәләр... Бала-чагаларыңызны майлап йоталар... Алма шикелле зифа хатын-кызларыңызның эчләрен тибеп яралар...

Гыйсмәтуллага акрын гына идән урыныннан кузгалып йөри башлаган шикелле күренергә тотынды. Ләкин һаман туктап торыр хәл юк:

— Атларыңыз, сыерларыңызны урлап саталар... һи, алтыннарым, күк күгәрченнәрем, рабучий һәм крәстиян туганнарым... Минем әйтәсе сүзем шул гына: теге бая сөйләгән ач өрәк төсле студент әйтә: «Җирне национализм ясарга кирәк»,— ди. Үзеңез уйлап караңыз, туганкайларым, җирне соң национализм ясарга мөмкинме? Шулай «май ясарга кирәк» дигән булып ул студент сезне җирсез калдырып, бөтен җирне байларга бүлеп бирмәкче була. Ул ахырдан гына, сезнең күзне буяр өчен генә «социализм ясарга кирәк» ди башлаган булды...

Идән һаман йөри шикелле тоелгач, Гыйсмәтулла алдындагы графиннан су эчеп җибәрде, һәм бу эш аңар шактый ярдәм бирде:

— Юк, туганкайлар, сез җирне национализм ясатмаңыз, «безгә социализм булсын» дип, нык торыңыз... Кан эчүче буржуйлар хәзергә хәтле дә бик күп таладылар инде...

Гыйсмәтулладан бу сүз чыккач, Гайфулла, урыныннан сикереп торып, бик каты кул чаба башлады вә бу эш безнең хатибны тәмам терелтеп җибәрде.

— Юк, моннан соң талаттырмамыз инде. Һәрбер рабучий туганга сигез сәгатьлек эш көне булсын, торырына зур һәйбәт таш пулат булсын, ашарына һәйбәт тәмле ашлар булсын, эчәренә яхшы заграничный ширбәтләр булсын...

Гыйсмәтулла кыза бара, Гайфулла да кулын тагы да, тагы да катырак чаба иде.

— Киярենә һәйбәт нечкә сукнодан кыйммәтле сюртуклар булсын, башы киң һәйбәт сары шиблетләр булсын, һәрбер

рабучий туганга йөреренә парлап җигелгән ат бирелсен, губернаторларныкы төсле карета булсын, кызына уйнарга рояль булсын. Аңар ноталар хәзинәдән бирелсен. Театрда семьялысына семьясы белән утырыр өчен ложа, семьясызына әүвәлге рәт кресло бирелсен, хатынына муенына тагып йөрер өчен җитәрлек энҗе-мәрҗән бирелсен, рабучий туганны карарга килгән дуктыр акча сорамасын...

Гыйсмәтулла моны әйткәч, Гайфулла: «Права!» дип кычкырып, бер үзе бөтен залны дер селкетеп, кул чабып торды вә шуның белән Гыйсмәтуллага тагын куәт биреп җибәрде:

— Рабучий туганның кәефен бозарлык сүз әйткән кешене каторгага җибәрсеннәр, кан эчүче буржуйлар, урамда очраганда, рабучийга баш алып китәргә закон белән мәҗбүр ясалсын, рабучий туганнарның атларын карарга ак сакаллы мәһабәт кучер булсын, аңар кучер киеме һәм бүрегенә чәнчеп куярга тутый кош койрыгы шәһәр идарәсеннән бирелеп, айлык вазифасы, капиталистларга хосусый налог салынып, шул акчадан бирелсен...

Гыйсмәтулла әйбәт ат шикелле кызганнан-кыза, Гайфулла да кулын чапканнан-чаба, аңар ияреп, төрле җирләрдән бер ун-унбиш кеше дә кул чабып, бөтен залны яңгырата иде.

заграничный ширбәт — чит ил эчемлеге
хәзинәдән — дәүләт хисабына
баш алып — баш киемен салып

Сораулар.

1. Гыйсмәтулланың митингтагы чыгышын ничек бәялисез?
2. Гайфулланың үзен хуплап кул чабуы Гыйсмәтуллага ничек тәэсир итә?

III

Өч-дүрт ай үткәндә инде Гыйсмәтулла бөтенләй икенче Гыйсмәтулла булып киткән иде: ул хәзер лихачта гына йөри, һәрвакытта ике култык астында ике портфель йөртә. Әүвәлдә бүлмәләрендә торып, акча түләми чыккан марҗалар белән очрашканда, алар сүгә башламастан элегрәк, бурычын үтәп өлгерә дә эре генә сдачасын да алмый китә. Аның инде өстбашы да бу елгы марткача үзенең төшенә дә кермәгән рәвештә

шәбәйгән иде. Ул инде хәзер әүвәлге шикелле учительлек правосы алу өчен хосусый хәзерләнеп ятучы Гыйсмәтулла түгел, бәлки кырык төрле демократия мәсьәләрендә әллә ничә төрле лөзуме ишгаль итүче демократия «лидеры» иде.

Шуңар күрә аны, көннең теләсәң нинди вакытында очратмакчы булсаң да, өендә очрата алмыйсың, бәлки урамда ике култыгына ике портфель кыстырып, ямщикта барган хәлдә генә очрата ала идең. Бу авыр хезмәт бәрабәренә, табигый, ул матди җәһәттән яхшы тәэмин ителә иде. «Кәләпүш типчүче хатыннар мәркәз бюросы»ның рәисе буларак ул елга дүрт мең сигез йөз сум, «Тегәрҗеп урамы мөселман демократиясе оешмасы»ның һәйәт идарәсендә рәис мөгавене буларак еллык өч мең алты йөз сум, «Бөтен Русия читек башы сабучылары берегеә»нең мәркәз шурасында сәркатип буларак өч мең алты йөз сум, хәзинәдар буларак тагы өч мең алты йөз сум, «Мөселман кучер һәм дворниклар союзы»ның һәйәт идарә әгъзасы буларак бер мең ике йөз сум, «Печән җыючы мөселман малайлар мәркәз бюросы»нда рәис буларак дүрт мең сигез йөз сум, «Хәерчеләр союзы» җәмгыятенең фәхри рәисе мөгавене буларак бер мең ике йөз сум еллык вазифа ала иде. Бу вазифаларны, табигый, ул оешмалар үзләре түләмиләр, бәлки аларның гомуми җыелышларында бирелгән карарлар буенча яртысыны «милли фонд» кассасыннан вә калган яртысыны шәһәр вә земстволар кассасыннан түләтәләр иде.

Гыйсмәтулланың тышкы киеменең җиңнәре күптән инде бу оешмаларның русча-татарча исемнәре басылган кызыл батистлар белән чолганып беткәнлектән, аның хәленә бик күп кешеләр кызыгалар вә хәтта көнләшәләр иде. Шул җөмләдән Гайфулла белән аның хатыны Сәхипҗамал да Гыйсмәтулланың хәзер Русиядә беренче кешеләрдән берсе икәненә ышансалар да, әллә ничек аңар гыйбтә итми кала алмыйлар иде. Чөнки Гыйсмәтулланың еллык вазифасы егерме дүрт мең булу өстенә, аның җиңенә бәйләгән кызыл чүпрәкләре дә инде алты данәгә җитеп, һәр ике җиңен бөтенләй тутырып торган хәлдә, Гайфулланың мондый чүпрәкләре бары ике җиңенә ике генә, еллык вазифасы да ике оешмадан рәис булып сигез мең дүрт йөз сумнан гына гыйбарәт иде. Сәхипҗамалның хәле исә иренекенә караганда да начаррак иде. Чөнки ул фәкать «Бөтен Русия мөселман солдаткалар мәркәз бюросы»ның гына рәисәсе буларак ала торган вазифасы да фәкать алты мең сум, җиңенә тагып йөри торган чүпрәге дә фәкать бер генә иде. Ире бер дә

солдат булмаган хәлдә, солдаткалар мәркәз бюросына рәисә булып, мондый матур кызыл чүпрәкләр тагып йөрер өчен дә әле аңар шул ук Гыйсмәтулланың тырышуы кирәк булган иде.

Хәер, Гыйсмәтулла үзенең мондый гаҗәп карьерасының башланып китүендә үзе дә Гайфулла вә Сәхипҗамалга бурычлы иде: мартның унбишләре, революциянең әүвәл көннәре, һәртөрле мөәссәләрнең ашыгыч рәвештә яңа баш күтәрә торган дәкыйкаләре иде. Менә шул көндә Гайфулла фатирында кан эчүче буржуйларны ләгънәтләп чәй эчеп утырганда, мәҗлестә Сәхипҗамалның энесе, бер гәзитәнең өләшүче малае булудан истифадә итеп, Гыйсмәтулла, Гайфулла, Сәхипҗамал, аның энесе вә үзеннән гыйбарәт бер «Шәһәрдәге гәзитә язучылары оешмасы» тәртип иткән вә шул оешмадан вәкил буларак сайланып, «Мөселман комитеты»на әгъза булып кергән вә шулай итеп үзенең җәмәгать хезмәтен башлап җибәргән иде. Шул ук «Гәзитә язучылары оешмасы»ннан вәкил булып ул Мәскәүдәге «Мөселман съезды»на да барган вә, шул оешмадан вәкил буларак, Гайфулла вә Сәхипҗамал берлән берлектә, шәһәр думасына гласныйлыкка, өяз земствосына әгъзалыкка, «Эшче вә солдат вәкилләре шурасы»на вәкиллеккә сайланып кергән вә шуннан тәм табып калганнан соң инде, «Кәләпүш типчүче хатыннарымыз бюросы»н үзе оештырып, аннан соң үзе рәислек итә торган башка оешмаларны да укмаштырган иде.

Гыйсмәтулла «Мөселман комитеты»ның вилаять шурасына вәкил тәгаен итү мәҗлесендә җиде оешманың вәкиле буларак хәзер булып, шуларның һәммәсе исеменнән үзен һәм Гайфулла белән Сәхипҗамалны фиһристкә кертүне таләп иткән вә шул аркада болар бөтен Казан әһлиясенең дә вәкиле булып әверелгәннәр иде.

Ләкин бу «Шура»да әксәрият тәшкил иткән крәстияннәр үзләренең кан эчүче буржуйлыклары белән Гыйсмәтулланы җәбер иттеләр, аны жалунияле урын булган һәйәт идарәгә сайламый калдырдылар. Менә бу хәл Гыйсмәтулланың мәсләгендә шактый зур үзгәреш ясады. Ул хәзер инде әүвәлге шикелле бөтен крәстияннәрне «туганнарым, былбылларым» дип атамый, бәлки аларны икегә бүлә: кан эчүче буржуй крәстиян һәм революционный крәстиян. Шуларның әүвәлгеләрен бик сүгә вә бик дошман күрә, нотыкларын да шул «кан эчүче буржуй крәстияннәр игенне сатмый асраганга күрә рабучий туганнар ач калдылар» дип сөйли вә аларны гаскәр белән

бастырырга тиешлек фикерен котлый. «Шура»дагы бөтен крәстиян вәкилләрен шул буржуй крәстияннәр җөмләсеннән хисаплый иде. Бу алмашынудан соң инде ул үзен коры социалист дип атауны ташлап, социалист-максималист дип атап йөртә башлады. Хәзер инде ул Русиядә контрреволюция башланганлык тугрысында бик кызып-кызып сөйли һәм Плеханов белән Керенскийны бик сүгә иде...

мөәссә — учреждение
лөзуме ишгаль итүче — вазифа башкаручы
лидеры — юлбашчысы, монда ирония белән әйтелгән
мәркәз — үзәк
рәис — председатель
һәйәт — комитет
могавене — ярдәмчесе
шура — совет
сәркатип вә хәзинәдар — секретарь һәм кассир
жалуния (жалованье) — хезмәт хакы

Сораулар һәм биремнәр.

1. Өч-дүрт айдан соң Гыйсмәтулла ничек үзгәрә?
2. Гыйсмәтулла гаҗәеп карьерасында ни өчен үзен Гайфулла белән Сәхипҗамалга бурычлы дип исәпли?
3. Ни өчен Гыйсмәтулла моңа кадәр «туганнарым, былбылларым» дип йөрткән крестьяннарны сүгеп йөри башлый?
4. Әдипнең бу хикәясендә әйтергә теләгән фикерен үз сүзләрегез белән аңлатыгыз. Шул хакта әңгәмә корыгыз.

Мәҗит Гафури
(1880—1934)



Мәҗит Гафури 1880 елның 20 июлендә хәзерге Башкортстан Республикасының Гафури районы Җилем-Каран авылында укытучы-хәлфә гаиләсендә туа. Башта үз авылларындагы мәдрәсәдә, аннары күрше Үтәш авылындагы мәдрәсәдә укыган. Шул елларда бер-бер артлы әтисе белән әнисе үлеп китә һәм моннан соң унбер-унике яшьлек Мәҗиткә үз көнен үзе күрергә туры килә.

Берәр зуррак мәдрәсәдә укуын дәвам иттерү теләге белән 1896 елда ул Уфага килә, әмма ярлылыгы аркасында теләгенә ирешә алмый. Ниһаять, 1898 елда Троицк шәһәренә барып мәдрәсәгә укырга керә, анда яшь Гафури аң-белемен үзлегеннән арттыруга да игътибар итә; К. Насыйри, Р. Фәхретдин, Ф. Кәрими кебек күренекле татар әдип-галимнәренең иҗаты белән якыннан таныша. Әдәбият белән кызыксыну аның үзендә дә язу теләген тудыра. Ул Троицк мәдрәсәсендә укыганда беренче әдәби тәҗрибәләрен ясый. 1904 елдан аның язганнары китап рәвешендә дөнья күрә башлый, «Фәкыйрьлек берлә үткән тереклек», «Себер тимер юлы, яки Әхвәле милләт» кебек беренче китаплары басылып чыга.

1905 елда Казанга килеп «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенә укырга керә һәм шул вакытта илдә көчәйгән революцион хәрәкәт йогынтысында үз иҗатында туган халкының реаль тормышына игътибарын көчәйтә, милли азатлык идеяләрен чагылдыра башлый.

1906 елда М. Гафури кабат Уфага китә, һәм аның моннан соңгы тормышы нигездә шушы шәһәрдә үтә. Алга таба

язучының иҗат эшчәнлеге елдан-ел активлаша бара. 1917 елга кадәрге иҗатында ул үзен милләт язмышын кайгырткан, аның азатлыгы өчен көрәшкән әдип итеп таныта. Шундый милли уй-омтылышлар белән яшәгән әдип 1917 елгы Октябрь революциясен дә зур өметләр белән каршылый. Аның бу өметләре шул елда язылган «Татар байрагы» һәм «Кызыл байрак» дигән шигырьләрендә аеруча ачык чагылды.

Мәҗит Гафури үзенең иҗат эшчәнлеген төп ике юнәлештә алып бара. Бер яктан, ул әсәрләрендә, конкрет сыйнфый позициягә күчеп, гади хезмәт халкының тормышын үтә кырыс төсләрдә чагылдыра (мисал өчен, «Кара йөзләр», «Тормыш баскычлары», «Шагыйрьнең алтын приискасында» повестьлары), икенче яктан, игътибарын илдә искене җимереп яңа тормыш төзү өчен алып барылган көрәшкә юнәлтә. Бу көрәшне тәэсирлерәк итеп күрсәтү максатында, әдип әдәбиятның тәрбияви йогынтысы көчлерәк булган формасы — драматургиягә дә мөрәҗәгать итә. Нәтиҗәдә аның авылда яңа тормышка күчүне чагылдырган «Кызыл йолдыз» исемле пьесасы егерменче елларда зур гына популярлык казана. Ә инде 1921 елгы ачлык фаҗигасен ул «Ачлык тырнагында» дигән шигырьләр циклында чагылдыра.

М. Гафури 1934 елның 28 октябрендә Уфа шәһәрендә вафат була.

ТАТАР БАЙРАГЫ

Дүрт йөз ел буе
Тәхкыйрь ителгән
Татарның туы
Бу көн эленгән.

Дүрт йөз ел буе
Хәбестә торган
Татарның уе
Бу көн котылган.

Дүрт йөз ел буе
Ниләр күрмәдек,
Түздек, чыдадык,
Һаман үлмәдек.

Сакланып эчтә
Сынмый килде ул.
Бу көн эленгән
Байрак әнә шул.

Канлы бәгыребез
Янды, сызлады,
Өмид байрагы
Һаман сынмады.

Тәкрар эленгән
Байрак инде аумас.
Татарның исме
Мәңге югалмас.

Башка байраклар
Белән бер сафта
Барсын бу байрак,
Алсын бетмәс дан.

тәхкыйрь — мыскыл
туы — байрагы

хәбестә — ябылуда
тәкрар — кабат

Сораулар һәм бирем.

1. Шигырьдә татар халкының кайсы замандагы тормышы турында сүз бара?
2. Шигырьдә «байрак» сүзе нинди мәгънәдә кулланыла?
3. Шагыйрь татар халкының дүрт йөз ел буе кем тарафыннан изелүен күздә тота?
4. Шигырьне яттан өйрәнегез.

САРЫКНЫ КЕМ АШАГАН?

Бер Аучының бер Сарыгы кырда калган,
Эзләп тә тапмаганнар — ул югалган.
Бер-ике көн үтеп киткәч, безнең Аучы:
«Бүре ашаган сарыкны»,— дип хәбәр алган.

Моны ишеткәч, Аучы чиксез ачуланды,
Ерткычларның бу эшенә көйде, янды.
«Сарыкның үчен алмый калмамын»,— дип,
Җанварларга шушылай дип хәбәр салды:

«Кызганып тора идем үзем сезне,
Ачулансам — калдырмамын һичберегезне.
Сарыгымны кем ашаган булса, шуны
Таләп кыйлам миңа тотып бирүегезне!»

(Аучыны белә урманда һәр җанвар)
Бу хәбәрне ишеткәчтән таң калдылар.
«Аучыны тизрәк риза итәек»,—дип,
Киңәш өчен зур урынга җыйналдылар.

Мәҗлестә Төлке — кятиб, Бүре — рәис,
Рәис сүз башлап әйтте: «Бу нинди эш?
Аучының Сарыгын кем ашады?—
Танмаенча ушбу җирдә әйтү тиеш.

Шул эш өчен чакырдым мин монда сезне,
Ачуланса Аучы кырыр һәммәбезне.
Кем ашаса, шуны биреп котылаек,
Тугрылыктан аермагыз үзегезне...»

Әүвәл Бүре «ашамадым» диде, танды,
Төлке дә тугрылыгын сөйләп алды;
Һәммә ерткыч үзләрене сафладылар,
Бер як читтә ерткыч түгел Куян калды.

Диде Бүре: «Читтә торып ялгыз үзең,
Бур кешенең күзе төсле ике күзең.
Сарыкны ашаган кеше син түгелме?
Әйтеп кал, монда килеп, әйтер сүзең!»

Куян мескен куркуыннан калтырады,
«Ашаучы мин түгел»,—дип, чак әйтә алды.
Шөбһәле кеше төсле җавап биргәч,
Барча ерткыч: «Ашаучы шул!..» — дип аваз салды.

(Ашамый Куян һичбер вакытта ит)
Әйтә алмады, ашаучы мин түгелдер, дип.
Диде Бүре: «Сарык ашап йөргән кеше
Шушы икән, китерегез бәйләргә җеп!»

Шул минутта әллә кайдан җеп таптылар,
Куянның муенына җеп тактылар.
«Явызлыкның җәзасын күр менә инде!»— дип,
Аучының авылына озаттылар!

Бүре төсле ерткычларга киндер җиһан,
Һәркайда золым күрер мескен Куян.
Зарарлы бәндә булып күренерсең,
Башкаларга кыйлмасаң да һичбер зыян.

мәҗлес — киңәшмә
кятиб — секретарь
рәис — председатель
җиһан — дөнья, галәм
золым — изү, кыерсыту

Сораулар һәм бирем.

1. Сарыкны ашауда ни өчен Куянны гаеплиләр?

2. Төлке белән Бүре образлары аша шагыйрь нинди кешеләрне күрсәтергә тели?

3. Аучы образында нинди кеше сурәтләнә?

4. Мәсәлнең мәгънәсе нидән гыйбарәт?

5. Мәсәлне рольләргә бүлеп укыгыз.

МӘСӘЛ ТУРЫНДА

Мәсәл — әдәбиятның борынгы һәм үзенчәлекле жанрларыннан берсе. Ул — гадәттә шигырь белән язылa торган кечкенә күләмле эпик әсәр. Аның геройлары рәвешендә хайваннар алына һәм алар образы аша кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләр чагылдырыла.

Мәсәлнең финалы гадәттә әсәрнең төп идеясе ачылуы белән тәмамлана.

Мәҗит Гафури — татар әдәбиятында мәсәл жанрына актив мөрәҗәгать иткән әдипләрнең берсе.



Галимҗан Ибраһимов
(1887—1938)

Татар халкының классик язучысы Галимҗан Ибраһимов 1887 елның 12 мартында Уфа губернасы Авыргазы районы Солтанморат авылында туган. Ул авыл бик матур урынга — су буена утырган. Аның елга-тугайлары, урман-таулары теләсә кемнең күңелен үзенә җәлеп итәрлек. Солтанморат авылы утырган елга буе кечкенә Галимҗанның иң яраткан урыны була. Ул, үзенең иптәшләре белән бергә, шул елгада су коена, балык тота, яшел үләнле болыннарында уйный, бигрәк тә урманда йөрергә ярата.

Бу хакта Г. Ибраһимовның туганы (аталары бертуган) М. Ибраһимов: «Бу җирләрнең сихри матурлыгы Галимҗанны нечкә күңелле әдип итеп тәрбияләп үстермәдеме икән?» — ди.

Г. Ибраһимовның ата-анасы укымышлы кешеләр була. Әдип әнисен, бик сагынып, җылы хисләр белән искә ала: «Әнием бик миһербанлы, эшчән, кунакчыл кеше иде. Без аны бик ярата идек. Ләкин бик кызганыч, иртә үлеп китте»,— ди ул.

Аның әтисе Гыйрфан абзый ачык фикерле кеше була, балаларын укытуга зур игътибар бирә.

Ул ат чабыштыруны бик ярата. Үзе дә чабышкы атлар асрый.

«Атлар ярату миңа әтидән күчкән булса кирәк. «Алмачуар» дигән хикәям үз тормышымнан алып язылган дисәм дә була. Әти безне бик иркәли иде, дип әйтә алмыйм. Андый кеше түгел иде. Шулай да ул безне кеше итәргә бик тырышты. Заманы өчен үз даирәсендә алдынгы кеше иде. Шуңа күрә, указын

кайтарып, муллалыгын ташлады, гомеренең соңгы көннәренә чаклы гади крестьян булып үткәрде»,— ди язучы.

Галимҗан башта үзенең туган авылы Солтанморатта укый, өч сыйныфлы башлангыч рус мәктәбенә дә йөри.

Бер елны әтиләре Гыйрфан абзый улларын Оренбургка алып китә һәм Галимҗанны кадим мәдрәсәгә — Вәли мулла мәдрәсәсенә урнаштыра. Соңга таба Галимҗан, андагы укыту тәртипләре белән килешә алмыйча, Уфага китә һәм «Галия» мәдрәсәсенә укырга керә. Монда ул шәкертләр хәрәкәтендә актив катнаша. 1909 елда мәдрәсәне ташлап, белемен күтәрү һәм әдәби эш белән шөгыльләнү өчен, Казанга килә. Шул еллардан алып ул иҗади эшкә керешә.

1907 елда «Зәки шәкертнең мәдрәсәдән куылуы» дигән беренче хикәясен, 1909 елда «Татар хатыны ниләр күрми» повестен, 1910—1911 елларда «Диңгездә», «Йөз ел элек», «Карак мулла» кебек хикәяләрен яза. 1912—1914 елларда «Карт ялчы», «Көтүчеләр», «Табигать балалары» һ. б. бик күп әсәрләрен иҗат итә. Революциядән соң аның «Кызыл чәчәкләр», «Адәмнәр», «Казакъ кызы», «Тирән тамырлар», «Безнең көннәр» кебек күренекле әсәрләре бер-бер артлы дөнья күрә.

Көчәеп киткән үпкә авыруы аркасында, ул озак вакытлар Кырымда яшәргә мәҗбүр була. Репрессиягә эләгеп, 1938 елда Казанда Пләтән төрмәсендә үлә.

АЛМАЧУАР

(Өзекләр)

I

Өйдә тутырып бәрәңге пешергәннәр. Мин эттән яман ачыкканмын икән. Күземә ак-кара күренмәде, каз йомыркасы зурлыгындагы бәрәңгеләрне тозлап-тозлап арыш икмәге белән бөгәргә тотындым.

Үзем авыз тулы көенчә бурлы бия турында туктамый һаман сөйлим.

Әнкәй бер ачулана, бер көлә:

— Синә, ахры, ат җене кагылгандыр, торсаң — шул, ятсаң — шул, бар белгәнең шул булды,— ди.

Мин, аның белән карулашырга уйлап, авызымны гына ачкан идем, түбән оч Фәһринең зур улы Сәпәр урам як тәрәзәдән баш тыкты да ут чыккан кебек акырып җибәрде:

— Закир! Закир! Сөенче! Бурлы биян колынлады,— ди.

Ни эшләгәнемне белмәдем, әни, аптырап:

— Ай, бу бала харап була инде шул мал өчен! — дип кычкырып калды, мин, ашъяулыклар, табаклы бәрәңгеләр өстеннән атылып, йортка чаптым.

Әткәй бакча буенда арба төзәтеп маташа иде. Туры аңа ташландым.

— Әткәй, әткәй, әйдә тизрәк, бия колынлаган,— дип акырам. Гаҗәп яратам мин шул әткәйне! Ул әз генә дә ачуланмады, минем сүзне ишетү белән, урыныннан торды да коймага эленгән нуктаны алды:

— Кем әйтте, сөенче бирдеңме?

Ул арада капкадан Фәхри малае Сәпәр сөенче сорап килеп керде.

Минем, каз кавырсыннары, чүпрәкләр сатып, сөенчегә дип әзерләнгән алты тиен акчам бар иде. Карап та тормадым, яшергән җирдән тиз генә алдым да Фәхри малаена китереп тоттырдым. Без әткәй белән Өзән елга буена колынны алырга киттек.

II

Шәп маллар аякланып туа, диләр.

Ахрысы, бу сүз дөрестер.

Без барып җиткәндә, колын үзенең әле бик ныгып бетә алмаган нечкә аяклары белән саклана-саклана басып йөри башлаган иде инде.

Бичаракаем, бик ачыгып туган, күрәсең: әле бер ягына, әле икенче ягына чыгып, әнкәсенең сөт белән тулып каткан имчәкләрен суырып азаплана.

Бу арада бурлы бия бик артык холыксызланып киткәнгә, мин аның янына барырга курыктым. Үзенең нуктасы белән аңа якын килә башлагач та, ул, баласын бирмәскә тырышкан ана арыслан кебек, әллә нинди яшел тавышлар белән чинап, әткәй өстенә ташланмакчы булды. Йомырылып тешләргә, чыелдап, колынының әле бер, әле икенче ягында йөгереп тибәргә итеп карады.

Ләкин безнең әткәй курку дигәннең нәрсә икәнен белми, маллар да аның болай икәнен аңлыйлар булса кирәк. Биянең дулавына — тешләргә, тибәргә омтылуына карамастан, әткәй туры барды да муенына нуктаны ташлады; алай-болай иткәнче,

бурлы биянең башы калын нукта эченә кереп тә өлгерде. Мин аптырап, хәйран булып тик тордым. Шатландыммы, юкмы — белмим.

III

Тик өйгә алып кайтып, бияне кое баганасына бәйләп куйгач кына, мин үз-үземә исәп бирә алырлык булдым.

Колын чыннан да гаҗәеп бер нәрсә иде.

Аның ботлары ничектер җиңел атлыйлар. Бәкәлләре озын, шундый нечкә озын ки, мондыйлар тик чабышкы атларда гына була диләр. Әле яңа гына кибеп килә торган койрыгы белән ялы, әз генә, кыска гына булсалар да, озаклап үреп, кабартып ясаган җефәк бәйләме кебек үзеннән-үзе дулкынланып торалар. Түм-түгәрәк сырты өстеннән, нәкъ арка үзәге турыннан, бармак калынлыгы кара тасма кебек булып, койрыктан ялга җиткәнче, кара җефәк җон сузылган. Озынча, акыллы башның киң маңгаендагы озын яра кашка — бу колынны мең, миллион иптәшләре арасыннан бөтенләй аерып, матурлыгы белән ялгыз итеп күрсәтәләр. Бөтен гәүдәсе әйтерсең Ходайның үз кулы белән, фәрештәләрнең ярдәме белән тигезләп, матур итеп, коелып ясалган. Шундый... сылу, шундый асыл сөяк булып яратылганнар.

Төсе хакында аптырап калдым. Кара түгел, күк дип тә булмый. Анасы кебек саф бурлы да түгел — ничектер, күгелҗем ак чәчәк төсе кебегрәк булып ялтырап тора.

Бер самавыр кайнарлык вакыт үтмәгәндер, йортка бала-чага җыела башлады. Бары да, авызларын ачып, хәйран булып, бу асыл сөяк колынга карап каталар.

Кайдандыр ишетеп, безнең Сафа бабай да ак сакалын җилбердәтеп килеп керде. Ул — бөтен тирә-якка ат тану белән дан тоткан кеше.

«Йа Ходай! Ни әйтер?» — дип, мин аңа карап каттым.

Колынны күргә бабайның йөзе ачылды:

— Сөбханалла... Сөбханалла... Күз тимәсен... Бу колын да үзенең элекке ике агасына охшаган икән,— диде. Дәшмитынмый тагы бик озак карап торды да:

— Шулай, шулай! Яңлышмыйм. Бу да нәкъ агалары кебек...—диде.

Әти, миңа белдермичә генә, әллә кайчаннан кечкенә генә көмеш кыңгырау алып куйган икән. Әни кызыл тасма бирде.

Карт акрын гына, оста гына килеп, колынны кинәт кенә кочаклап алды да:

— Бисмилла... Сөбханалла... Яман күздән, эт-бүредән Ходай сакласын,— дип, догалар укый-укый, минем айгырымның муенына шул кызыл тасма белән кыңгырауны такты.

Тагы бераз читкәрәк китеп карады да әткәйгә:

— Беләсеңме, Хафиз, бу нәкъ агалары кебек булыр, төсе дә бик тиз арада алмачуарга әйләнер... Хәерле булсын, хәсрәтең зур иде, ике өлкән балаңның хафасы сине бик картайткан иде, бурлы бия бу йортка җиңел аяк белән килде, бәрәкәт китерде,— диде.

Ике өлкән баласын хәтергә төшерү һәрвакыт безнең әткәйнең йөрәгенә авыр була; мондый чакта, ничектер, аның тавышы үзгәрә, сүзләре башкачарак чыга. Мин, аптырап, күзләрендә яшь юкмы дип, аңа карыйм.

Юк, ул еламаган. Шулай да әсәрләнгән. Әллә нинди эчке тавыш белән:

— Сөйләмә инде, Сафа абзый, ул ике балам адәм түгел, лачыннар, арысланнар иде. Үзләре дә бәхетсез булды, минем дә вакытсыз чәчләремне агарттылар...— диде. Бераз туктап торып:— Язган шулдыр инде... Менә бар өмет бу кечкенәсендә,— дип кушты.

Сафа бабай тагы, теләкләр теләп, колынны мактады да минем колагымнан шаяртып тартты:

— Закир, бәхетең зур икән: башкортның бурлы биясе атаңны аякка бастырды, сиңа алмачуар колын бирде, бу колын ике агасы кебек асыл сөякләрдән... Күз тимәсен, бу да чабышкы булыр...— дип сөйләнә-сөйләнә чыгып китте.

Мин кая басканымны белмим. Бер көндә әллә ничаклы үскән кебек булдым: уенмыни?! Минем колыным бар. Ул — айгыр! Төсе алмачуарга әйләнәчәк! Тирә-якта дан тоткан ике агасы кебек чабышкы булачак!

Әнә күрегез: ул ничек көмеш тавыш белән яңгыратып кешни! Ничек асыл сөякле гәүдәсе белән матурлап сикереп уйный!

IV

Шул көннән алып Алмачуар минем тормышымның үзәге була. Шатлыкларым, кайгыларым шуннан чыга, шуңа кайталар. Төшемдә шуны күреп саташам. Иртән торуга, киенмәстән, битемне юмастан, мин абзарга, Алмачуарны карарга, аның исәнлеген белергә йөгерәм. Исән, бик исән!

Ул, әкияттәге баһадир кебек, ай үсәсен көн үсә, үзе көннән-көн матурлана, асыллана бара. Хәзер авылда аңа тел тидергән кеше юк. Һәркем аңа:

— Күз тимәсен, сөбханалла! Бигрәк асыл сөяк нәрсә икән! Яхшы нәселдән шул!..— дип кенә карыйлар.

Тирә-якта асыллыгы, сылулыгы белән генә түгел, тавышы, җиңел, җитез, килешле һәм акыллы уйнавы белән минем Алмачуарга тиңдәш булырлык бер колын күренми дә, ишетелми дә.

V

Җәй, аның артыннан көз үтеп китә. Әллә нинди карлы, яңгырлы, болытлы чаклар килә. Мин иртәгә «Покрау» бәйрәме дигән көндә ничектер иртәрәк уяндым, шулай да торырга иренеп ятам.

Кайдадыр, кемнәрнеңдер нәрсә хакындадыр ашыгыч-ашыгыч сөйләшкәннәре ишетелә.

Нидәндер йөрәгем «жу-у» итеп китте.

Колак салдым:

Әткәй белән әнкәй чаршау артында пыш-пыш сөйләшәләр. Тавышларында әллә ни бар: куркалармы, кайгыралармы, нәрсәдәндер, кемнәндер яшерергә телиләрме? Бернәрсә белмим.

— Син аңа белдермәскә тырыш! Ишетмәсен!— диде дә әткәй, кулындагы арканын җилкәсенә салып, тиз генә чыгып китте. Мин тагы курка төштем.

— Ни бар, әнкәй, ни бар?..— дип, әнкәйнең итәгенә барып асылдым.

— Юк, балам, бернәрсә дә юк... Сиңа торырга иртә әле, бар, ят... Менә мин мичкә ягам да белен пешерәм... Самавыр кайнагач, эссе беленгә уятырмын,— диде.

Күңел тынычланмый, ятсам да, күзгә йокы керми.

Әни мич алдында, чыж-пыш итеп, нидер кыздыра калды, мин аннан-моннан киендем дә урамга чыктым.

Каршыма Апуш килә:

— Их, малай, бәхетең бар икән... Исән калган бит,—ди. Мин шашып киттем:

— Ни бар?.. Ни булган? Кем исән? — Апушның күзләре дүрт булды:

— Әй тавык баш! Шуны да белмисеңме?.. Бүген тауга бер көтү бүре килгән. Дүрт колынның бугазын чәйнәп, каннарын

эчкәннәр, үтереп киткәннәр... Синең Алмачуарың үлмәгән, тик азрак яраланган гына...— ди.

Башыма нидер сукты, телем тотлыкты, сүз әйтә алмый катып калдым.

Апуш, моны күргәч:

— Тиле, нәрсә торасың! Бар, йөгер! Әнә алып кайтып киләләр,— дип, түбән очка таба күрсәтте...

Чыннан да, ул яктан бер көтү халык әллә ничаклы бияләр, тайлар, колыннар куып киләләр иде.

Үземне-үзем белмәдем, шул якка очтым.

Ни күрим!

Зур арбага безнең кола ат җигелгән: тәртә янына бурлы бия бәйләнгән, ул бертуктамый кешни, кайдадыр китәргә, ычкынырга азаплана.

Арба янында әткәй килә...

Якынрак баргач, тагы авыр хәл: минем Алмачуарым, аяккулы бәйләнеп, арбага салынган...

Ни эшлим? Аптырадым. Каттым...

— Әткәй, безнең колынны да үтергәннәрмени!— дип кычкырып елап җибәрдем.

Әткәй, мине иркәләп, култыгына алды:

— Елама, Закир... Дүрт колынны үтергәннәр... Безнеке исән... Тик азрак арткы ботыннан тешләнгән генә... Шул ярадан кан күп акмасын дип кенә бәйләп арбага салдык,— ди.

VI

Яра тирән түгел икән. Минем бәхет җиңде: көн-төн карау аркасында, бер атна дигәндә минем Алмачуарым бөтенләй элекке хәленә кайта алды. Тик аның уң ботында бер илле чаклы яра булып, бүренең ике теш эзе генә ак җонлы булып сузылып калды...

Алмачуарым белән бергә мин дә авырган — йокымны, ашау-эчүемне югалткан идем: ул, терелеп, уйный башлагач, мин дә аңардан калышмадым.

Кыш шулай үтеп китте.

алмачуар — аксыл таплары булган җирән яки күк ат

чабышкы — йөгерек, бик шәп чабучы ат

яра кашка — белая отметина на лбу лошади

бәкәл — щиколотка, путовая кость у лошади

Сорау һәм биремнәр.

1. Тексттан колынны сурәтләгән урыннарны табып укыгыз. Шуларга нигезләнеп, колынның рәсемен ясагыз.
2. Колынга бәйле рәвештә Закирның хисләрендә, үз-үзен тотышында нинди үзгәрешләр күзәтергә була.
3. Закирның әтисе һәм Сафа абзый хакында ниләр белдегез?

VII

Икенче яшенә чыкканда, бездә яз көне тайның ялын, койрыгын бөтенләй кыркалар; «кырыкмыш» ясыйлар. Мин алай ямьсез итеп боздырасым килмәде: маңгай чәчен күзенә төшмәслек итеп ясап, тип-тигез кистердем.

Бу хәзер алдан караганда рус боярларының матур кызлары кебек күренеп тора. Ялны да башкалар кебек бөтенләй бетертмәдем: бер чирек кадерлерәк калдырып, үзеннән-үзе дулкынланып, күпереп тора торган итеп төзәттердем генә.

Әнидән алып, ул ялга ике яклап чуклар, тасмалар тактым. Койрыкны да бүтән кешеләр кәбестә күчәне кебек, ялангач беләк кебек ямьсезләп кыркалар. Моңа да якын җибәрмәдем: сөяктән түбән ягын гына кистеләр дә матурлап түгәрәкләделәр. Кырыкмыш тайлар, бигрәк тә язгы сабан өстендә, йолыккан карга кебек чырсыз булып йөриләр. Минем Алмачуар исә кунакка барырга ясанган бояр җегете кебек чибәр булды.

Мин моны Әпсәләм байларның берсендә, этиләр ялланып урак урырга йөргән чакларда күргән идем. Шулай итик дип сөйләп биргәч, әти карышмады:

— Их балам, көенечкә генә булмаса ярар иде синең бу кылануларың,— диде дә бөтенләй мин әйткәнчә эшләде.

Авылда минем тайның болай матур кыркылуын күргәч, малайлар таң-хәйранга калдылар... Алдагы елларда башкалар да шулай ясый башладылар.

VIII

Җәй, көз, кыш үтә. Яз килә.

Минем Алмачуар өченчегә керә. Авылда бу яшькә җиткәч, тайларны «беренче сабанга керде» дип сөйлиләр. Акрынлап, җиңелчәләп җигә башлыйлар.

Мин үзем моңа якын китермәдем.

Безнең Алмачуардан башка ике атыбыз бар. Бурлы бия быел кысыр калды. Ул бура кебек таза, калын булып симереп китте. Берүзе биш атның эшен эшләрлек. Кола айгыр да аңардан күп калышмый. Шулай булганга әткәй дә, Алмачуарны юк-барга җигәргә дип, тел кузгатмый. Сафа бабайның: «Бу колын ике агасына охшаган, бу чабышкы булыр»,— дигән сүзен дә онытмый булырга кирәк. Ләкин гөлләр чәнечкесез булмый икән шул. Гөнаһ шомлыгына каршы, «Тарыны йомшакка чәчсәң, чүп басып харап итә»,— дигән дә, әткәй Кысылдык башкортларыннан мәңге сабан-сука кермәгән бер җир, каты чирәм сатып алган. Тимер сабанны чыдатырлык түгел — урыны-урыны белән ташлы, чыбыклы җирләре дә бар. Шуңа күрә әллә кайчаннан кузгалмый яткан авыр төрән сабанны тартып чыгаралар. Моны ике ат йөртә алмый. Дүрт, иң азында — нык, таза өч кирәк.

Үзара сөйләшкәннәр дә өченчегә Алмачуарны җигәргә булганнар. Моны ишеткәч, мин, еларга җитешеп, әткәйгә бардым:

— Ни бар? Кем тиде?— ди.

— Берәү дә тимәде! Ник минем Алмачуарны сабанга җигәсез?— дидем дә түзә алмый елап ук җибәрдем.

Минем тавышка әнкәй дә килеп керә.

Ул Алмачуарны миннән көнләшә булса кирәк. Кайчан гына шул турыда сүз чыкмасын, мине тиргәргә, каһәрләргә тотына. Әле дә әткәй ни барын сөйләп бетермәде, әнкәй миңа каршы кызып, ачуланып китте:

— Фу, Илаһым,— ди,— нинди бәла-каза килгән дип торам... Бер тай өчен адәм шулчаклы акырыр икән,—ди...— Әллә аны гомер буена җикми асрар идеңме? Менә тилергән нәрсә!..— ди.

Әткәй ачуланмый, кызмый, мине юатырга тырыша:

— Чү, Закир, алай юк өчен елап барма,— ди.— Бернәрсә дә булмас, без аны буразна яклап очка гына җигәрбез... Үзең ат куарсың... Карап кына йөртерсең,— ди.

Мин аның саен ярсыдым, аның саен елый бирдем.

Ашарга чакырдылар — кермәдем. Самавыр кайнаган, диделәр — аңа да карамадым. Туктаусыз еладым да еладым; шулай елый-елый барып, эштән чыгып, бакча буендагы такта өстендә йоклап та калганмын.

* * *

Уянып китсәм, ишегалдында түшәктә ятам.

Төш ауган. Кояш түбәнәеп бара. Дөнья бик рәхәт кенә, талгын гына тора. Йортта бер кеше дә күренми. Сабаннар, арбалар да капка тулы ачык тора.

Сикереп тордым да абзарга йөгердем.

Барсам, ни күрим?! Минем Алмачуар, озын тезген белән бәйләнгән хәлдә, улакның бер башыннан икенче башына йөреп тора. Ахрысы сагынгандыр: мине күрүгә кешнәп үк җибәрде. Телләребез сөйләмәсә дә, без бер-беребезне бик тирән аңлыйбыз. Мин килеп күренүгә, ул шатланып ук китте; өстен, ял, койрыгын тазартканда, йөзен сыйпаганда, айгырым бертуктаусыз иһи... иһи... дип, йомшак кына кешнәп, иркәләнеп тора.

Улагын төзәттем, коега илтеп су эчердем дә өйгә кердем.

Әткәй ярым шелтә, ярым елмаю белән каршы алды:

— Елак малай! Җиндең бит, ахрысы!.. Вилдан абзыйларың да безнең белән бергә янәшә чирәм алганнар икән, шулар белән алмашлап сөрергә булдылар...— ди.

Шатлыгым йөземнән тулып таша. Җир-күге, бөтен дөньясы минем шатлыгымнан һәммәсе биеләр кебек тоела.

Бүген әни яныннан китмәдем. Ни кушса, барын-барын тыңладым.

Утын керт, диде — аны керттем. Каз бәбкәләрен Өзән елгага илтеп кайт, диде — аларны илттем. Тавыклар йомырка салгандыр, ояларны кара, диде — аңа йөгердем.

Әткәйләр киткәндә, катык оеп җитмәгән, икмәк тә пешеп өлгермәгән; шуңа күрә азык алмый киткәннәр икән, аларга ашарга илтергә кирәк булды.

— Бар, Мохтарга әйт,— диде,— аркылы агач белән тотарсыз да яланга икмәк белән катык илтеп кайтырсыз,—диде әнкәй.

Бер сүз карышмадым, тик:

— Мин үзем генә дә илтә алам, әнкәй,— дидем.

— Булдыра алмассың, катыкны түгеп әрәм итәрсең, икәү барыгыз,— дигәч, аңа да күндем.

Яланга баргач, безнекеләр янында сабан сөрә торган Апуш мине көлеп каршы алды:

— Ну, малай, эт икәнсең, җиңдең бит, Алмачуарны җиктермәдең бит,— ди.— Әйдә бирешмә, Закир, чабышкы буласы асыл сөякне сабанга җигеп әрәм иттермә,— ди.

* * *

Бу юлга җинүен җиңдем...

Әмма бу җиңүләр миңа бик кыйбат төшкән чаклар да булды. Мин берәр төрле карулаша башласам, тыңламасам, хәзер күз алдына Алмачуарны китереп куялар.

— Бик күп сөйләнә тагын! Алай бик каршылансаң, Алмачуарны тотарбыз да урманга җигәрбез,— дип куркыталар.

Моңа җавап кайтарырга сүзем булмый, телем киселә: үземне җиксеннәр, аңа риза, тик минем Алмачуарыма гына тимәсеннәр.

Тирә-якта ат тану белән дан чыгарган Сафа бабай:

— Бу колын үзенең ике агасына охшар, алар кебек чабышкы булыр...— дигән иде. Һәммә кеше дә шулай юрыйлар. Урманга, тауга-ташка, сабан-сукага җиксәң, ул ничек чаба алачак? Аңарда нинди чабышкылык калачак?! Ни булса булыр, авырга җиктермим, менәм, чабыштырам, чабарга өйрәтәм, тирә-якта беренче чабышкы ясыйм!

нукта — авызлыксыз йөгән, атны бәйләп кую өчен кулланыла

каз кавырсыннары — казның эре каурыйлары

хафасы — борчуы, кайгысы

бәрәкәт — муллык, барлык; матди иркенлек

шөбһә — шикләнү, ышанмау

кырыкмыш — бер яше тулып, икенче яшькә чыккан һәм, гадәттә, ялы, койрыгы кыркылган тай

Биремнәр.

1. Бүлекләрне игътибар белән укып чыгыгыз һәм исемнәр куегыз. Эчтәлеген сөйләгез.
2. Сөенеч белән сагышның, шатлык белән көенечнең алмашынып торган эпизодларын кабат укыгыз.
3. Түбәндә бирелгән сүзләрнең төп мәгънәләрен аңлатыгыз, синонимнарын табыгыз:

Эттән яман ачыгу, күземә ак-кара күренмәү, каз йомыркасы кадәр, ат җене кагылу, ут чыккан кебек, тормышымның үзәге, тел тидермәү, колак салу, күзләре дүрт булу.

IX

Менә күптән көтелгән көн килеп җитте.

Бүген Сабан туе!

Андый-мондый гына түгел, тирә-якта бик сирәк була торганы —бик зурысы, бик шәбе! Данлыклы чабышкылар җыелалар. Атаклы көрәшчеләр киләләр. Исемле йөгерек ирләр бүген көчләрен сынашмакчылар. Алмачуар белән минем өчен дә бүгенге көн, бәлки, гомергә бер генә килеп китә торган зур көннәрдәндер. Айгырым сыналмаган түгел. Өченче яшенә чыккач та, менәргә өйрәттек. Шуннан бирле авылыбызда үзара ат ярыштырулар күп булды. Әйтәсе дә юк, һичкемнең аты минем Алмачуарга якын килмәде — кузгалып китү белән мин очам, башкалар күз күреме җир артта калалар.

Күрше авылларның атлары белән дә ярышкаладым. Болар арасында күп Сабантуйларында беренче, икенче килгәннәр дә бар иде. Алмачуар боларны да җиңел, бик уйнап уза иде.

Әмма, әмма бу Сабан туе башкарак. Әллә кайдагы, тау эчендәге башкортлар дан тоткан чабышкылары белән килгәннәр, диләр. Араларында бер күк бияне бик мактап сөйлиләр, үткән ел Өфе каласында чаптырганда, бөтен атларны адәм көлкесенә калдырган, диләр.

Башкаларын уйламыйм да. Менә шул күк бия мине куркыта. Кайдан гына килеп чыкты икән соң ул гөнаһ шомлыгы нәрсә!

Әткәй белән Сафа бабай да минем хәлне бик аңлыйлар булса кирәк. Чаба торган атны бөтенләй башкача хәзерләргә тиешле була икән: заманында күп чабышкы асраган Сафа карт, яз чыккач ук, әткәйгә моның юлларын өйрәтте; нәрсә ашатырга, ничек эчертергә, көн саен ничек аз-аз гына йөртеп кайтарырга — һәммәсен әйтеп бирде. Аның белән генә дә калмыйча, һәр көн диярлек, үзе килә, карый, яңадан өйрәтеп китә.

Сабан туена бер атна калгач, бигрәк каты тотына башладылар. Печәннең корысын гына бирәбез, бүлеп-бүлеп солы салабыз, азлап-азлап апара суы эчерәбез... Әти иренми, көн-төн карый. Мин аңа ияреп йөрим. Ансыз да асыл сөяк булган Алмачуарым бу арада карап туйгысыз булып чибәрләнде. Ял, койрык җефәкләнеп, дулкынланып тора. Эч, каеш белән тарттырган кебек, нечкәреп, тип-тигез булып эчкә керде. Буе тагы да озыная төшкән кебек күренә. Аяк атлаулары шундый җиңел инде, әйтерсең ул җиргә басмый, бәлки күзгә күренми торган канатлары белән очып кына бара.

Ул электән дә ашауга бик назлы иде. Ахрысы, ярыш көннәренең якынаюын сизәдер, үзен-үзе бик артык саклый башлады... Шуның белән бергә аны тыюлар бик авырайды.

Мин башка һичбер малайны мендермим. Йөрергә чыкканда һаман үзем менәм. Шул вакытларда кайда гына булса да, нинди генә булса да, атланып кына барырга кирәк чакта да, башка берәр ат, арттан килеп уза башласа, тыеп торырмын дип уйлама,— авызлыкны тешләп ала да канатланып оча гына!

Бер дә шик юк, Алмачуар тиз арада Сабан туе буласын белә, анда үзенең чабачагын да сизә һәм шуңа бик нык хәзерләнә. Минем хәзерләнүем дә аныкыннан ким түгел.

Әткәй белән Сафа бабай, шаяртыпмы, чынлапмы; кайбер вакыт башка берәр малайны мендереп чаптыру турында сөйлиләр:

— Син яшьсең, Алмачуар да әле зур җирләрдә чабып өйрәнмәгән,— диләр.

Мин якын да килмим. Тагы әйтсәләр, күзләрем яшәрә башлый. Сафа бабай мине юата:

— Ярар, балам, ярар, ни күрсәң үзең күрерсең, узсаң да— үзең, уздырсаң да — үзең!— ди.

X

Бүген бөтен авылның асты өскә килә. Әллә ничә йөзләп җегетләр, ат менеп чыкканнар да, яшь киленле йортларга кереп, сөлге җыеп йөриләр. Малайлар, кайсы атта, кайсы җәяү, өйдән өйгә йомырка сорарга чыкканнар. Аларга яшелле-кызыллы буяуга буяп әзерләп куйганнар. Хатын-кыз бертуктаусыз кайный: киенәләр, ясаналар, буяналар, тырт-мырт өйдән өйгә йөгерәләр.

Башка Сабан туйларында мин дә шулар эчендә кайнаша идем. Бусында күңелем ул якка бармый.

Алмачуарның йөрәге түзми, баскан җирендә тора алмый. Мин аңа менеп, берничә мәртәбә урап кердем. Яраулануы җитсен, дим.

Сафа бабай әйтә: «Яраулануы килмәсә, иң шәп атлар да артта калалар»,— ди.

Камчының иң зәһәрен әзерләделәр. Аңа этидән беләзеккә эләрлек итеп элмәк куйдырдым. Өскә кызыл киҗеле күлмәкнең калынын кидем. Түбәтәй төшеп кала, диләр, чабарга

барган малайларның күбе аны кими, башларына яулыкмыниме, бернәрсә генә бәйлиләр.

Мин дә, әнкәйнең сандык төпләрен актарып, бер яшел яулыгын эзләтеп алдым. Кызыл яулыкны яратмыйм. Минем ат чибәрлектә беренче: аңа атланган малай да начар күренмәсен дим.

XI

Мәзин, өйлә намазына азан әйтергә дип, манарага менгән генә иде, тагы Сафа бабай килде:

— Атлар китәргә вакыт җитә, әйдәгез, мәйданга барыйк,— ди.

Йөрәгем суга, тәнем бераз калтырый, күкрәгем никтер кысып-кысып ала.

Алмачуар миннән дә яманрак тынычсызлана.

Әти айгырны җитәкләде, мин аякны чишендем, чалбарны салдым да бер кулга камчы белән яшел яулыкны алдым.

Өчәүләп Җамали карт тыкрыгыннан туры мәйданга таба карап киттек.

Безнең авылның кояш батыш ягында зур киң бер сырт бар. Сабан туен һәрвакыт шунда ясыйлар.

Бер якта аллы-гөлле, кызыллы-яшелле чүпрәк диңгезе үз алдында дулкынланып тора,— болар хатын-кызлар. Икенче якта, бик куе булып, ирләр бер түгәрәк ясап оешканнар. Монда көрәш барадыр. Болардан читтә бала-чага, карт-коры, сатучыфәлән, ат, арба, белмим, әллә ниләр кара болыт кебек бөтен сыртны каплап алганнар. Бераз еракта, басу киртәсе буендарак, атлар йөреп тора. Кайберенең өстендә яулыклы малай, кайберләрен икенче атка менгән кеше җитәкләп йөртә... Барсының да эчләре суырылган. Бары да — карап торырга сөлек кебек маллар. Болар — чабышкылар.

Без теге халык диңгезеннән сулга, шул чабышкылар йөргән якка таба киттек. Боларга якынайган саен, минем Алмачуарның сабырсызлыгы арта бара иде.

Ул арада мәйданнан Садыйк абзый атка атланып килеп чыкты. Кулында зур таяк, аның башына кызыл башлы сөлге эленгән... Ул чабышкыларга якынрак килде дә:

— Вакыт җитте, китә башлагыз, алдан килүчеләр Ялгыз каен янында көтәрләр,— дип кычкырды.

Мине Алмачуарга күтәреп мендерделәр, яулыкны урадылар; кәләпүшне әткәйгә бирдем.

Башка сүз әйтмәделәр. Тик Сафа бабай гына:

— Башта бик куалама, аерманың бу ягына чыккач, кызганма, нык сук! Берүк тезгенеңне иркен куй! Тарткалап баруны ярата торган мал түгел бу!— дип, кат-кат әйтеп калды.

Без, Ялгыз каенга карап, үзеннән-үзе очарга барган атларыбызны көч белән тыя-тыя киттек.

Сораулар һәм биремнәр.

1. Бүлекләргә исемнәр куегыз, эчтәлеген сөйләгез.
2. Галимҗан Ибраһимов Сабан туен ничек тасвирлаган? Ат чабышына хәзерлек ничек бара?
3. Тексттан Алмачуарны тасвирлаган урыннарны табып укыгыз.
4. Авыл халкының бер-берсенә ярдәмләшүе, киңәшләшүе хакындагы өзекләрне табып укыгыз. Фикер алышыгыз.

XII

Ялгыз каен бездән унбиш чакрым.

Башка елларда булса, җиде-сигез чакрымнан чаптыралар иде, быел, төрле илләрнең данлыклы атлары килгәнгә, шулай ерактан куйганнар, диләр. Ялгыз каенга ничек килеп җиткәнне белмим. Бу — бик артык газап булды. Әлбәттә, атлап кына барырга кирәк. Алмачуарны тыяр хәл юк. Алда яисә артта берәр ат күрсә, авызлыкны тешләп ала да оча гына. Мин барып җиткәндә, атларның күбесе андалар иде инде. Ерак китмичә, туктаусыз йөреп торалар.

Боларны күргәч, каушап калдым: берсеннән-берсе сылу, бер-берсеннән асыл маллар. Өметем азаеп ук калды. Болар бит берсе дә Алмачуардан ким түгел!

Теге данлыклы Күк бия дә килеп җитте. Күрүгә шуңардан күземне алмадым. Гаҗәп бер мал икән: кыска яллы, сирәк койрыклы, чандыр гәүдәле нәрсә. Очасы тар, бер якка бераз чалыш, аркасы бераз бөкрерәк. Әмма күкрәк дигәне бөтенләй арысланныкы — шундый киң, шундый нык күренә. Тезләре ике яккарак китеп тора, бәкәлләренә карагач, тагы хәйран калдым: алар шундый озыннар ки, мин гомеремдә андыйны күргәнем юк. Күзләре зурлар, уйнап, ялкынланып торалар. Өстенә кечкенә, кап-кара, башы бөтенләй ялангач, кулына камчы тотып, бер башкорт малае менгән.

Кечкенә булса да, күп чапкан малайдыр, ахры: бер дә каушамый, атның холкын бик белгәнгә охшый.

Чабышкылар арасында иң тыныч торганы шул Күк бия иде.

Атлар килеп бетте. Садыйк абзый безне тезә башлады. Бусы бик зур бәла икән: инде тигезләп тездем генә дигәндә, йә берәүнең аты, кузгалып, алга китеп бара, йә баскан урынында тора алмыйча, кире чигенә. Күп азаплардан соң тезеп җиткерде:

— Берәү, икәү, өчәү! Һайди, туганнар!— дип кычкырып та җибәрде.

Башкалар кая киткәннәрдер, узганнардырмы, артта калганнардырмы, белә алмадым. Урыннан кузгалуга, без өч ат: мин, Күк бия, тагы бер җирән чабышкы, бер-беребезгә бәрелә язып, янәшә оча идек.

Аяклар җиргә тияме, әллә атлар яшерен канатлары белән һавадан бараламы — әле дә аерып җитә алмыйм. Агачлар, елгалар, зур-зур баткаклар — алда, ничектер, күзгә чалынырга өлгерә алмыйлар, без аларны яшен кебек үтеп кенә киткән булабыз.

Аеркул дигән бер тайгак елга бар. Бу юлда иң куркыныч нәрсә шул, диләр иде.

Очкан кошлар кебек, без бер-беребезне таптап, узып, каулашып ул баткаклы елгага өчәү килеп кердек, ләкин ярның янында Күк бия белән минем Алмачуар гына иде, өченче иптәш — җирән чабышкы, малае белән баштүбән шунда баткакка чумды булса кирәк...

Инде икәү ярышабыз...

Көчләр бертигез: бервакыт аның аты чак кына арттан бара, ләкин тагы бер каулый, минем атның башы Күк биянең койрыгы янында кала.

Тагы бер баткак; минем башым әйләнә, үзем егылам кебек булам. Күңелгә шөбһә килә; күзне йомам да Алмачуарның ялларына тотынам. Ачсам, баткакны чыкканбыз, ләкин Күк бия миннән өч-дүрт сажин алдан оча.

Инде якынлыйбыз да бугай, авылның манаралары күренгән кебек була.

Гайрәт белән бер тартам, камчы белән уңга-сулга җан ачуы белән сугам. Алмачуарым «эһ» дип суырып ала да, күз ачып йомганчы, Күк биянең алдына барып чыга...

Менә авыл, менә басу капкасы, менә сырт өстен каплаган кара болыт кузгала!

Чабышкы ияләре безгә каршы ат өстендә киләләр.

Арада әткәй дә күренеп кала.

— Һайди, Закир, тагы бер сук! Тагы бер! Тагы!

— Һайди, Алмачуар!

— Һайди, Күк бия!

— Һайди, Алмачуар!

— Һайди, Күк бия!..

Ике яклап безне каулыйлар... Кычкыралар, сугалар, шаулашалар.

Ләкин Алмачуар белән Күк бия бөтенләй диярлек янәшә киләләр.

Тагы бер тартып җибәрдем, тагы бер бөтен гайрәтем белән уңнан-сулдан сугам...

Алмачуар «эһ» дип бер суырып ала да, Күк бияне аршин ярым чамасы калдырып, мәйданга килеп тә керәбез...

Кара болыт икегә ярыла.

Күк биянең башы минем Алмачуарның кабыргасындарак булган хәлдә чикне дә узып китәбез!

Шау-шу, тавыш, тапталыш! Әйтерсең мәхшәр көне!

Старостаның бер кулында яшел чапан — бусы беренче килгәнгә, икенче кулында зур сөлге — бусы икенче килгәнгә билгеләнгән.

Тузан, шау-шу эчендә староста, ялгышмы, ничектер, чапанны Күк биягә сузды, минем Алмачуарның муенына сөлгене ташлады:

— Син икенче килдең бугай,— ди.

Ни эшләгәнемне белмәдем, күз алдым караңгыланды, камчы белән уратып-уратып старостаның йөзенә селтәдем дә, кызулык белән Күк биядән чапанны тартып алып, бу кара болыт эченнән чыгып, читкә киттем. Камчы тигәндерме, юкмы — белмәдем...

Аны карап торырга вакыт та юк: чабып килгән атны туктатырга ярамавы һәркемгә билгеле бит!

Ул арада Сафа бабай, әткәй, күршеләр килеп, мине ат башыннан кочаклап алдылар, һәммәсе мактый, һәммәсе рәхмәт укый. Сафа бабай, кат-кат башымнан сыйпап:

— Егетсең, балам, йөзне хур итмәдең,— ди.

Әткәй Алмачуарны җитәкләп йөртә башлады. Мин, яулыкны ташлап, кәләпүш кидем дә кайнашып торган халык туфанына барып кердем.

Малайлар мине куркыта башладылар:

— Камчы белән сугып старостаның битен яргансың. Ну, бирер үзеңә дә кирәгеңне!— диештеләр.

Ул арада староста үзе дә килде. Йөзе чыннан да ярылган булса кирәк: ак яулык белән бер күзе ашасыннан бәйләгән.

Мин аңардан курыкмадым, тик аптырап калдым. Ул ачуланмады гына түгел, мине кочаклады, башымнан сыйпады да:

— Мин балачакта үзем дә атка менеп күп чапкан кеше... Алдан килеп тә, икенченең буләген бирсәләр, җан түзәлми аңа... Мин сиңа ачуланмыйм, арыгансың, бар кайт инде,— дип, миңа егерме тиенлек көмеш бирде.

Дөнья минеке иде. Бөтен тирә-якта дан тоткан Күк бияне узып килү Алмачуар өчен һичкемнең акылына килмәгән бер бәхет иде.

XIII

Ләкин бу бәхет тиз арада бик артык авыр бәхетсезлеккә әйләнде. Белмим, атымны кызу каулап яндырганмынмы, белмим, килеп җиткәч, староста белән талашып, туктап тору харап иткәнме — ни дә булса булган: Сабан туеның икенче көнендә Алмачуар аякларына баса алмас булды, ашавыннан, эчүеннән калды. Бичаракаем, адәмнән болай акыллырак күзләре белән һәркемгә мөлдерәп карап, бер атнага якын ыңгырашып ятты да җомга көн, иртә белән сәгать унда дөньядан үтте.

* * *

Алмачуар җан биргәндә мин аның баш очында идем. Елый алмадым. Йөрәгем таш булып катты.

Шуннан соң дөньяда һичбер малга, һичбер әйбергә күңелем дә, күзем дә төшмәде: һичбер нәрсәне сөя алмадым.

Алмачуар минем йөрәгемдә: җиргә, күккә, адәмнәргә, бөтен нәрсәләргә булган мәхәббәтемне үзе белән бергә алып китте.

чакрым — километр
гайрәт — көч, куәт
камчы — каеш яки баудан үреп, ишеп ясалган кыска саплы чыбыркы

Сораулар һәм биремнәр.

1. Күк бия белән Алмачуарның узышу күренешен сурәтләп бирегез.
2. Ярышта нинди хаталар җибәрелә?
3. Җиңү яулаган Закирга авыл кешеләренең мөнәсәбәте ничек?
4. Алмачуар ни өчен һәлак була? Закир бу бәхетсезлекне ничек кичерә?
5. Алмачуарның үлеме сездә нинди тәэсир калдырды? «Алмачуар» хикәясендәге образларның кайсысы хәтерегездә калды? Һәрберсен аерым-аерым характерлагыз.
6. Хикәянең эчтәлеге буенча план төзегез, шуның нигезендә әсәрнең тулы эчтәлеген сөйләгез.

Гадел Кутуй

(1903—1945)

Гадел Кутуй 1903 елның 28 ноябрендә хәзерге Пенза өлкәсенә кергән Татар Кынадысы авылында крестьян гаиләсендә туа. 1912 елда Кутуевлар гаиләсе Самара губернасындагы Алексеевск авылына күченә. Туган авылында укырга һәм язарга өйрәнгән Гаделша биредә рус мәктәбенә укырга керә. 1917 елда аларның гаиләләре Самара шәһәренә килеп урнаша. Монда ул язучы А. Неверов оештырган әдәби түгәрәккә йөри башлый, анда рус поэзиясе, бигрәк тә В. Маяковский иҗаты белән кызыксына һәм үзе дә рус телендә шигырьләр иҗат итә. Бер үк вакытта яшь Гаделшада татар әдәбияты белән дә якыннанрак танышу теләге көчәя. Шушы максаттан һәм югары белем алу нияте белән, ул, 1920 елда Казанга килеп, андагы политехника институтының химия факультетына укырга керә. Әмма техник фәннәрдән тәм таба алмый һәм икенче курстан соң институтны ташлап, татар-башкорт хәрби мәктәбендә әдәбият укыта башлый. Бу вакытта ул Казандагы әдәби тормышта актив катнаша һәм әдәбияттагы үзгәрешләр ташкынына кушыла.

Аның заман модасына ияреп язылган шигырьләре ул вакытта әдәби даирәләрдә зур гына шау-шу туугa сәбәпче булалар. Бераздан Г. Кутуй үзе дә беренче шигъри адымнарының формалистик мавыгуга корылган булуын аңлый. Әдәби белемен арттыру нияте белән, ул 1925 елда Казандагы Көнчыгыш педагогия институтының рус теле һәм әдәбияты бүлегенә укырга керә һәм, аны 1929 елда тәмамлагач, мәктәпләрдә һәм Казан авиация техникумында әдәбият укыта.

Бер үк вакытта ул иҗат эшчәнлеген дә киң җәелдерә: шигырьләр, хикәяләр, пьесалар яза, матбугат битләрендә күп кенә публицистик мәкаләләр, очерклар һәм фельетоннар бастыра.

1935 елда Г. Кутуйның иң күренекле әсәре — «Тапшырылмаган хатлар» повесте дөнья күрә.

Сугыш башлангач, Г. Кутуй, башка бик күп татар әдипләре кебек үк, фронтка китә. Фронт газеталарында сугышчыларның батырлыкларын һәм патриотик хисләрен чагылдырган күп санлы әдәби-публицистик язмалары басыла. 1944 елда Казанга иҗади командировкага кайткач, ул балалар өчен «Рөстәм маҗаралары» дигән маҗаралы повестен иҗат итә. Аның 1944 елда иҗат иткән «Без — сталинградчылар» һәм «Сагыну» нәсерләре татар әдәбиятының традицион жанрын сугыш елларында заман рухына туры китереп яңгыратуның күркәм үрнәкләре булдылар.

1945 елның язында сәламәтлеге начарланган Г. Кутуй госпитальгә эләгә һәм 15 июньдә Польшаның Згеж шәһәрендә үлә.

НӘСЕР

«Нәсер» сүзе гарәпчәдән алынган һәм проза төшенчәсен аңлата. Көнчыгыш әдәбиятларына карый торган бу жанрны шигъри проза дип атарга мөмкин. Әдипләр аны геройның гаять киеренке һәм нечкә уй-кичерешләрен зур эмоциональ көч һәм шигъри ритм белән чагылдыру максатында файдаланалар. Нәсергә гадәттә җәмгыять тормышы киеренке төс алган, анда кискен үзгәрешләр барлыкка килгән вакытларда һәм шушы киеренкелек-үзгәрешләрнең шәхес күңеленә тәэсирен ачу өчен мөрәҗәгать итәләр. Татар әдәбиятында да ул иҗтимагый-сәяси һәм үзгәрешләр чорында, мисал өчен Октябрь революциясе алды елларында, гражданнар һәм Ватан сугышы көннәрендә бермә-бер активлашып киткән иде. Ватан сугышы елларында күп кенә әдипләр мөрәҗәгать иткән нәсер жанрының иң күркәм үрнәкләрен Гадел Кутуй бирде. Аның нәсерләрендә ил язмышы хәл ителгән әлеге елларда совет кешеләренең патриотик хисләре аеруча калку булып гәүдәләнде.

САГЫНУ

(Нәсер)

Мин чит илдә матур гөлләр, хуш исле чәчәкләр исним. Ләкин күпме генә иснәмим, барыбер һава җитми, сулыш кысыла. Гүя үз илемнең энҗе чәчәкләре түгел, аның әреме дә бүген миңа шифа булыр иде.

Сагындым, бик сагындым сине, туган ил!

Мин шаулап аккан елгалардан, тирән коелардан алып сап-салкын су эчәм. Әмма күпме эчсәм дә, сусавымны баса алмам. Мин үз илемнең борынгы Иделен, тын Донын, якты Арагвасын, шигъри Дим буйларын сагынам. Гүя бу мөкатдәс елгаларның суларын түгел, хәтфә болынлыктагы чишмәләре-безнең бер йотым суын да бүген мин ширбәт итеп эчәр идем.

Сагындым, бик сагындым сине, туган ил!

Мин Карпат тауларына мендем, Финляндия күлләре янында ял иттем. Ләкин Эльбрус кебек мәһабәт, Казбек шикелле гүзәл тауларны, үз илемдәге Аккош күледәй сихри күлләрне очратмадым.

Синдәгедәй илаһи матурлык, синдәгедәй шагыйранә мәһабәтлек бер җирдә дә юк, туган ил!

Мин чит авыллар һәм чит шәһәрләр аша узам. Җиңү мине Берлинга алып бара. Чит ил балалары миңа бәйләм-бәйләм чәчәкләр сузалар, чит ил картлары миңа хәмер тәкъдим итәләр, чит ил кызлары миңа җимешләр сузып елмаялар һәм ялваралар:

— Син безне үлемнән коткардың, инде кил, чибәр егет, кунак бул, бездә кал!— диләр.

Әмма мин елмая алмыйм, чөнки хәмерләре исертми, елмаюлары җылытмый. Мин юлымны дәвам итәм. Мин газиз илемне, аның ямьле бәйрәмнәрен, аның талган аякларны да биетә торган хәмерләрен, йөрәккә җылы өргән нечкә билләрен сагынам, гөнаһсыз балаларын күргәндәй булам.

Сагындым, бик сагындым сине, туган ил!

Мин горур атлыйм. Чөнки мин чит илдә әсир булып түгел, җиңүче булып йөрим. Миңа һәр йортның капкасы, һәр өйнең ишеге ачык. Ләкин берсенә дә керәсем килми минем. Мин ата-баба корган илемдәге изге йорт турында уйлыйм һәм, шунда тизрәк кайтып керер өчен, Берлинга ашыгам. Берлинга мин, илем белән аерылу кайгысын моннан соң һичкайчан татымас өчен, чиксез ачу белән барам. Ачуым шулкадәр

көчле, сагынуым шундый татлы ки, мин түзмим, җырлап җибәрәм:

Иле ямьсез, суы тәмсез,
Өйгә кайтасым килә!—

дип җырлыйм мин.

Без мәйданга керәбез. Поляк яшьләре, безне котлап, үзләренең иң матур җырларын җырлыйлар. Әмма минем күңел еракта. Мин үзебезнең Кызыл мәйданыбызны сагынам һәм туган илдән килгән хатларны укыйм. Дусларым, кардәшләрем миннән, сагынасыңмы, дип сорыйлар. Минем бугазыма төер тыгыла. Мин төерне йота-йота җавап язам:

Телеграм баганасы — олы юлга маяк ул,
Сагынасыңмы дип сорыйсыз — сагынмаган кая ул!

Сагындым, бик сагындым сине, туган ил!

Сине сагынган саен, миндә көч-дәрт арта, рухым канатлана. Чит илдә йөреп, мин ачык аңладым: совет кешесе өчен үз иленнән дә изгерәк, үз иленнән дә кадерлерәк, үз иленнән дә гүзәлрәк ил дөньяда юк ул.

Сагынган саен сагынасы килә. Сагынуым шундый көчле булганга, кайтуым да ышанычлы. Кайтыр булмасам, бу кадәр сагынмас идем.

Сагындым, бик сагындым сине, изге туган ил!

мөкатдәс — изге, бөек, хөрмәтле

мәһабәт — сокландыргыч матур, күркәм

Сораулар һәм биремнәр.

1. Г. Кутуйның тормышы һәм иҗаты турында сөйләгез. Сез аның нинди әсәрләрен беләсез?

2. Нәсердә автор сагыну хисен ничек чагылдырган? Сагыну хисләре әсәрдә нинди вакыйгалар белән бәйләнештә бирелгән?

3. Сагынуның тирәнлеген аңлату өчен автор кулланган алымнарга игътибар итегез. Өндәү җөмләләрне дөрес интонация белән укыгыз.

4. Халык җырының әсәр эчтәлегендә тоткан урынын билгеләгез.

5. Нәсердә сурәтләү чарасы рәвешендә кулланылган чагыштыруларга һәм капма-каршы куюларга игътибар итегез.

6. Сагыну хисе кешедә кайчан туа? Шул хакта әңгәмә корыгыз.

7. Нәсернең баштагы өлешен «Мин Карпат тауларына мендем» дигән җөмләгә кадәр ятлагыз.

РӨСТӘМ МАҖАРАЛАРЫ

(Өзекләр)

ӘБИ ӘКИЯТЕ

Моннан берничә ай элек, кышкы салкын көннәрнең берсендә, Казанга Рөстәмнең әбисе килде. Аның килүен Рөстәм түземсезләнеп көтте. Кадерле кунакның кайчан килергә җыенуын ишеткәч тә, Рөстәм календарьда билге ясап куйды һәм көн саен иртә белән:

— Тагын биш кенә көн калды, тагын дүрт кенә көн калды!— дип әйтә торды.

Әби календарьда билгеләнгән вакыттан бер көн элек килде. Рөстәм моңа шатланды да. Ләкин әбисен ул каршы чыгып алырга теләгән иде. Ә әби Рөстәм югында, Рөстәм кинода чакта килеп төште.

Әби аңа ап-ак җылы оеклар, ап-ак җылы киез итекләр, куян тиресеннән тегелгән ап-ак бүрек, ап-ак бияләйләр һәм бик күп итеп чикләвек алып килгән иде.

Шәфкатьле әбисен Рөстәм элек тә күргән иде. Үткән елны ул бөтен җәйне аның белән бергә авылда уздырды. Ләкин ул чакта әби дә, Рөстәм үзе дә әллә ничек бер-берсен аңламыйлар, сөйләргә сүз тапмыйлар иде. Ә хәзер... хәзер бөтенләй башка... Рөстәм дәресләрен хәзерләп бетерүгә, әби аңа һәр кич төрле-төрле көйләр җырлап җибәрә. Рөстәм башта әбинең җырлау рәвешен генә ярата иде, хәзер ияләшкәч, аның көйләрен дә ярата. Моңлы итеп җырлый ул!

Шундый күңелле әбиеңне ничек яратмыйсың, ди. Ярата, бик ярата Рөстәм аны! Ашка яки чәйгә утырганда, Гайшә апа беренче тәлинкәне, беренче чынаякны балага куя иде.

— Әбигә, әүвәл әбигә!— дип кычкыра башлады Рөстәм.

Ярата, бик ярата Рөстәм аны! Хәтта ул мәктәп буфетыннан алынган конфет, прәннекләрдән дә аңа өлеш чыгара. Ә әкиятләре ни тора әбинең! Нинди матур сөйли ул аларны... Тыңлап туйгысыз! Андый әкиятләрне Рөстәм китапларда да укыганы юк әле.

Кышкы кичләрнең берсе иде. Гайшә апа белән Һашим абый Академия театрына спектакль карарга киттеләр. Өйдә Рөстәм белән әби генә калдылар. Шул кичне Рөстәм яңа әкият тыңлады. Әби аны бик тәмләп, бик озак итеп сөйләде. Аның кыскача эчтәлеге менә болай иде:

...Абага — карап торырга гап-гади үсемлек. Исе дисәң — хуш исе юк, яфрагы дисәң — яфрагы да әллә ни түгел. Ләкин

шул абаганың искиткеч бер хикмәте бар. Абага чәчәк атмый, диләр. Ялганлыйлар! Ата икән. Мең вә миллион абагалар арасында бер абага очрый, ди, менә шушы күп абагалардан сирәк очрый торганы яз көне, җиде төн уртасында, ике-өч секундка чәчәк ата, ди. Ул чәчәк атканда, яшен яшьни, күк күкри, кара урман яктыра, ди. Бу вакыт абага шундый матур була, ди, аның йолдызлардай атып торган чәчәкләреннән күзләр чагыла, ди, аннан таралган хуш истән башлар әйләнә, ди.

Абага чәчәген өзеп, телләре астына кыстырырга өлгергән кешеләр кеше күзенә күренмәс хәлгә киләләр, ди. Дөньяда тереклек булганнан бирле, тылсымлы абага чәчәген өзеп, кеше күзенә күренмичә йөрергә теләүчеләр бихисап күп булган, ди. Ләкин андый абаганы табуы кыен икән. Кайберәүләр, илдән илгә йөреп, бөтен гомерләрен әнә шундый абаганы эзләп уздырганнар. Әмма юкка: я таба алмаганнар, я аның чәчәк аткан вакытына туры килмәгәннәр, я чәчәк аткан чакта яшен яшьнәүдән, күк күкрәүдән, җен-пәриләрдән куркып, яктылык нурлары сугудан үлгәннәр.

Менә шуннан соң кешеләр абагадан ваз кичкәннәр, абага чәчәк атмый дип йөри башлаганнар. Әмма ул чәчәк ата икән. Бары тик аның чәчәк ату вакытын туры китерерлек бәхетле, аның чәчәген курыкмыйча өзә алырлык батыр йөрәкле кеше генә юк дисәм, хата булыр... Борын-борын заманда андый бәхетле, андый гайрәтле бер кеше булган икән, ди. Ул бихисап вакыт кеше күзенә күренмичә йөргән, ди. Эх, менә хәзер булсын иде ул кеше! Адәм ашаучы немецларны берәм-берәм тотып ярсын иде ул кеше.

Шуннан соң әби Рөстәмгә абага чәчәген өзә алган батыр турында әкият сөйләде. Ай арты ай узды, әби авылга кайтып китте. Ә абага турындагы әкияте аның мәңге онытылмаслык булып Рөстәмнең хәтерендә калды.

ваз кичтеләр — баш тарттылар **бихисап** — күп

Сораулар.

1. Әбисе Гайшә апа белән оныгы Рөстәм арасындагы җылы мөнәсәбәт нәрсәгә нигезләнгән?

2. Әбисе Рөстәмгә нинди әкият сөйләп, мәңге онытылмаслык тәэсир ясый?

3. Сезнең дә шундый тылсымлы әкиятләр тыңлаганыгыз яки укыганыгыз бармы?

КЕМ СОРЫЙ?

Абага чәчәкләрен ашаганнан соң, Рөстәм белән ул үзе дә аңлый алмаган хәл булды, һәрбер үсемлекнең, һәрбер гөлчәчәкнең кеше әле өйрәнеп җитмәгән хосусияте бар. Әгәр дә фән, гыйлем табигать биргән барлык әйберләрнең дә серләренә төшенсә иде, электрик утлар, радио аша рәсемнәр тапшырулар, диңгез асларында корабльләрдә йөзүләр генә түгел, хәзергә хыял җитмәслек могҗизалар туар иде. Шундый заман килер, зуп-зур шәһәрне ел буена җылытырга бер каен агачындагы көч җитәчәк, хәзергә фән күзе төшмәгән нинди дә булса гапгади үлән кешене картлык үлеменнән коткарачак, кешене үлемгә алып барган ютәл авыруыннан азат итәчәк...

Рөстәм белми калды: төн буе яңгыр яуды. Ләкин яңгырның да, яшен яшьнәүләрнең дә һичбер бәйләнешләре юк иде. Абага чәчәкләренең тәэсире ашказаны аша Рөстәмнең бөтен тәненә таралды, яшь тәнгә үзгәреш кертеп аны изрәтте, йокыга талдырды. Рөстәм бер тәүлектән артыграк йоклады. Уяну белән, ул үзен шундый рәхәт, шундый җиңеләеп киткәндәй хис итте ки, урманнан ничек чыкканын да сизми калды. Ләкин күтәренке кәеф озакка бармады. Инде өйгә ничек кайтып керергә? Тамак ач, өс-баш чыланган. Шул абага артыннан җенләнеп йөреп, нихәтле дәрес калдырылды. Укытучы абыйларга нәрсә әйтергә? Пионер була торып ялганларгамы? Әбиләр әкиятен тыңлап, могҗиза эзләргә урманга бардым, урманда яшәдем дияргәме? Шуны сөйләп кеше көлдерергәме? «Б» классындагы Өтер Вәли бигрәк тә рәхәтләнер инде: «Ышанмагыз, малайлар, шуның сүзенә! Вечно мактана ул! Урманда кундым дип ялганлый. Әбисе кочагында чикләвек ашап яткан ул!» — дип көләр. Хурлыгы ни тора! «Чынлап та, үзең абага чәчәкләрен ашадым дисең, ә үзең күренәсең... Ничек инде ул алай?» — дип, бүтән малайлар да теңкәгә тиеп бетәрләр. «Эх әби, әби, сине тыңлап юләргә калдым!» Бу сүзләрне Рөстәм чын-чынлап әрнеп әйтте. Өйгә кайтып кергәч тә, ул иң элек әбине күрер, җен-пәриләрне күрмәдем, абага чәчәгеңне учлап-учлап ашадым... ашасам да үзгәрмәдем: күрәм дә, күренәм дә дип ачынып сөйләр.

Бу вакыт Рөстәм трамвайлар туктала торган урынга килеп җиткән иде инде. Җәяү байтак киленде, килә-килә өс-башы да кибәргә өлгерде. Почмакта портфельле бер иптәш басып тора иде. Рөстәм аның янына килде һәм:

— Абый, сәгать ничә?— дип сорады.

Рөстәмнең соравы портфельле иптәшне сискәндереп җибәрде. Ул як-якка борылып карады, күзләрен уды, кул сәгатенә күз салды һәм сөйләнә-сөйләнә китеп барды:

— Сәгать сигез... Ә кем сорый — белмим... Колагыма шулай чагылды, күрәсең...

Рөстәм шатлыгыннан нишләргә белмәде. Сикерәсе, биисе килде. Димәк, әби ялганламаган, хыял чынга әйләнде. Димәк, Рөстәм чынлап та күзгә күренмәс кеше булды. Мөгаен шулай микән, теге иптәш сукыр түгел идеме дип, Рөстәм трамвай вагонына асылынган ике малай янына йөгереп барып, дәүрәк күренгәненең борынына чиертте. Чиертү яхшы ук каты булды, күрәсең, малай:

— Нишләп син, Кылый, тик торганда борынга чиертәсең? Кутырым барын оныттыңмыни?— дип, юлдашына акырды һәм чалт иттереп аның яңагына сукты.

Рөстәмгә бу кызык тоелды. Башланган кыйнашта ул этәчләнгән шук малайны җиңәргә булышты. Борын эчендәге кутырны шакшылыктан күреп, янә бер тапкыр авырткан борынга чиертте.

Димәк, дөрес! Малайлар да аның күренмәс кеше булуын раслад̆ылар. Ул өйгә кайтырга ашыкты. Ләкин өй эчтән бикле иде. Тәрәзәдән карап әбисен күрде. Рөстәм башта тәрәзә чиертергә дә, «әби, ач!» дип кычкырырга да уйлаган иде, ләкин бу фикереннән тиз кайтты, бик ашыйсы килсә дә, ишек ачылганны көтәргә булды. Озак торып та көтә алмагач, ишек дөбердәтте.

— Кем бар?

Рөстәм тиз таныды: әби тавышы иде бу. Инде кем дип җавап кайтарырга? Ул аптырап калды. Бераз дәшми торганнан соң, тавышын үзгәртеп эндәште:

— Бу мин... мәктәптән килгән идем... Рөстәм кайтмадымы?

— Юк, бәбкәм, юк. Кайтмады. Кем буласың? Атың ничек? — Әби ишекне ачты. Шул арада Рөстәм өйгә кереп китте.

— Ай Алла,— диде әби,— кай арада күздән югалды?..— Ишек ачып та, сораучыны күрмәгәнгә гаҗәпләнеп, сөйләнә-сөйләнә, әби Рөстәм басып торган бүлмәгә әйләнеп керде. Нәрсәдер карады да яңадан чыкты, тагын керде. Ул йомышны — эшлисе эшен онытты. Рөстәм, әби чыгып китүгә, шкаф тирәсендә актарына башлады. Икмәккә май якканда, кулыннан пычагы зыңгылдап идәнгә төшеп китте. Тавышка әби керде һәм идәндә яткан пычакны алып куйды.

— Күселәр ияләшә башлады, ахрысы. Мәче алып кайтырга кирәк. — Рөстәм әбинең бу сүзләреннән чак кына кычкырып көлеп җибәрмәде. Мин ашаган майны да күсегә сылтарлар микән дип, ул туйганчы ашады. Кухняга чыгып, әбинең күз алдында йотлыга-йотлыга су эчте. Чүмечне куйганда, янә тавыш чыгарды. Әби табагач алды һәм өстәл астына иелде:

— Ышыт-ышыт, нәләт суккырлары!

Рөстәм, кычкырып көлмәс өчен, телен тешләде. Өстәл артына утырып, әлеге мәгълүм язуны язды. Аны китап эченә салды да дәресләрен карарга кереште.

Гайшә апа кергәндә, букча өстәлдә ята иде. Ул шуңа ташланды. Рөстәм утырган урыныннан сикереп торды, әнкәсенең муенына сарылырга, йөгереп барып әнкәсен кочарга, күп-күп итеп үбәргә теләде. Ләкин аяклар тыңламадылар. Ул баскан урынында катып калды. Рөстәм үзенең нинди авыр хәлдә калуын хәзер генә аңлады: димәк, әнисе аны күрми һәм күрмәячәк. Рөстәм аның кайгы-хәсрәтен тыңлар, аның елап утыруын күрер, ул йоклаган чакта, аның янына барыр, үбәр дә бәлки. Әтисе белән дә, әбисе белән дә шул ук хәл булыр. Ә алар Рөстәмне юк дип йөрерләр...

Гайшә апа ишегалдына чыгып, улым, улым дип, Рөстәмне эзләп йөргән чакта, Рөстәм үзенчә бер карарга килде: китәргә булды. Өйдә калса, аңарда әти-әнисен кызгану хисе өстенлек алачак. Аны фронт көтә, башлары киселми калган немецларның башларын кисәргә кирәк. Ул букчасын алды һәм ишеккә таба атлады. Нәкъ шул чакта әнисе кайтып керде, букчага дип, өстәлгә кулын сузды. Мәгълүм ки, букча озак табылмый торды. Рөстәм, ата-ананың тирән хәсрәтләнүләренә түзә алмыйча, букчаны өстәлгә китереп куйды. Баягы язу килеп чыккач, Рөстәм аны ник язганына үкенде. Аны букчада онытып калдыруына ачуланды. Инде эзләү башланачак, кирәкмәгәнгә йөрүләр китәчәк, бик ихтимал, Рөстәмгә дә комачаулык ясарлар. Ә эзләүдән ни файда? Барыбер таба алмаячаклар ич... Тапсалар ни? Менә бит ул аларның яннарында басып тора... Күрмиләр генә! Әйе, ата-ана өчен, бүтәннәр өчен хәзер ул бар да, юк та.

Бу хәл Рөстәмне кинәт олыландырып җибәрде, болай да акыллы иде ул, зурлар сүзенә колак салырга ярата торган иде. Хәзер исә тагы да үсте, җитдиләнде, искиткеч вакыйга аның үзенең дә искиткеч булуын таләп итте. Рөстәм үз язмышын үзе хәл итәргә тиеш икәнлекне аңлады һәм зурларча акыл йөртә башлады.

хосусияте — асылы, үзлеге
шук малай — шаян малай

мәгълүм — билгеле, таныш

Сораулар һәм бирем.

1. Рөстәмнең могҗиза турындагы хыялы ничек тормышка аша?
2. Әсәрдә чынлык дөньясы белән хыял дөньясы ничек яраштырып бирелгән?
3. Рөстәмнең нинди сыйфатлары сезгә ошый?
4. «Рөстәм мажаралары» повестен тулысынча укыгыз һәм фикер алышыгыз.



Хәсән Туфан
(1900—1981)

Хәсән Туфан (Хәсән Фәхри улы) 1900 елның 9 декабрендә хәзерге Татарстанның Аксубай районы Иске Кармәт авылында эшче-крестьян гаиләсендә дөньяга килә. Башта ул әтисеннән, үзлегеннән укырга-язарга өйрәнә, ә 1905 елгы революциядән соң туган авылында мәктәп ачылгач, бераз вакыт шунда укып ала. Ундүрт яшеннән ул үз көнен үзе күрә башлый: Урал якларына барып чыга, анда бакыр рудныгында һәм металлургия комбинатында эшли. Уфадагы «Галия» мәдрәсәсендә укый. Г. Ибраһимовтан әдәбият буенча дәресләр ала, Ш. Бабич оештырган әдәби түгәрәккә йөри, мәдрәсәдә үткәрелгән кичәләрдә С. Рәмиев, М. Гафури, С. Сүнчәләй кебек шагыйрьләрне тыңлап, ул әдәбият белән якыннан таныша, үзе дә әдәби иҗатка тартыла. Аның бу өлкәдәге беренче тәҗрибәләренә Г. Ибраһимов белән Ш. Бабич та игътибар итәләр.

1924 елда «Кызыл Татарстан» газетасында Х. Туфанның беренче шигыре басыла. Озакламый ул татар поэзиясенә эчтәлек ягыннан да, форма өлкәсендә дә яңалык алып килгән үзенчәлекле шагыйрь булып таныла.

Дөнья күрергә теләп, Х. Туфан 1928 елда Кавказ һәм Урта Азия якларына җәяүләп сәяхәткә чыгып китә. Ике елга сузылган әлеге сәяхәт вакытында ул җирле халыкларның тормышы һәм иҗаты белән таныша. Боларның барысы аның иҗатына да йогынты ясый.

Утызынчы еллар ахырында татар әдәбиятына зур фаҗигаләр, югалтулар китергән репрессияләр фаҗигасе Х. Туфанга

да кагыла. 1937 елда уйдырма гаепләр тагып, Язучылар союзыннан чыгаралар, эшеннән куалар, әсәрләрен дөньяга чыгару хокукыннан мәхрүм итәләр һәм 1940 елның ноябрь аенда Хәсән Туфанны кулга алалар. Шагыйрьнең шуннан соңгы уналты ел гомере төрмәләрдә һәм лагерьларда авыр хезмәттә, ачлыкта үтә. Бу газаплардан ул бары 1956 елда гына котыла.

Шушы тоткынлык елларында аның поэзиясе яңа югарылыкка күтәрелә. Бу елларда язган шигырьләре («Алга барышлый», «Иртәләр җитте исә», «Гөлләр инде яфрак яралар», «Агыла да болыт агыла», «Ромашкалар», «Тамчылар ни диләр», «Әйткән идең», «Кая шулай ашыгасың, йөрәк?», «Сүз кушасы килә талларга» һ. б.) тирән лирик моң һәм киң фәлсәфи аһәң белән сугарылган.

1966 елда Хәсән Туфанга «Сайланма әсәрләр»е өчен Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләге бирелде.

Х. Туфан 1981 елның 10 июнендә Казанда вафат булды.

КИЕК КАЗЛАР

Яңгырларда-явымнарда,
Давылларда-җилләрдә
Киек казлар кыйгылдаша
Мин белмәгән телләрдә.

Киек казлар кыйгылдаша,
Җырлашалар микәнни?
Туган илләр кала бит дип
Елашалар микәнни?

Безнең дә бит шулар сыман
Киткән еллар бар иде;
Кыйгак-кыйгак, илем ерак,
Дигән чорлар бар иде.

Киек казлар кыйгылдаша,
Сау бул, якташ, диләрдер;
Әллә кайтыр, әллә кайтмас
Безнең башлар, диләрдер.

Казлар кебек очасылар,
Китәселәр юк инде;
Кыйгак-кыйгак, илем ерак,
Дияселәр юк инде.

Кыйгылдашып болытларда
Мин белмәгән телләрдә,
Киек казлар китеп бара
Мин күрмәгән илләргә.

Сораулар һәм биремнәр.

1. Хәсән Туфанның тормыш юлы һәм иҗаты турында сөйләгез.
2. «Киек казлар» шигыренең эчтәлеге белән автор биографиясе арасында уртаклык бармы? Шул хакта фикер алышыгыз.
3. Шигырьнең төзелешенә игътибар итегез. Рифма һәм ритмны күзәтегез.
4. Җылы якка китүче нинди кошларны беләсез, алар ни сәбәпле китәләр дип уйлыйсыз?

ТАЛАНТЛЫ СИН, КЕШЕ ТУГАНЫМ

Азмы йөрдем
Илләр эчендә...
Каршы алып һәр җир үз күреп,
Озатып калды изге дус кебек.
Гомер итеп юллар өстендә,
Азмы гиздем илләр эчендә.
Янтарь сыман сары каралты
Көлемсери юлым читендә,
Туктап калдым баскан җиремдә:
Эндәшкәндәй
Үзенә каратты
Янтарь сыман сары каралты.
Үзе бары гади агачтан,
Балта белән иҗат ителгән.
Ләкин аңа
Кеше хисеннән,
Матурлыктан нидер катнашкан,
Үзе гәрчә гади агачтан.
Очрый һаман миңа юлларда
Илһам белән тулы йөрәкләр.
Йөрәк катнашмаган хезмәтләр

Юлыкмады миңа юлларда,
Илләр аша үткән елларда.
Талантлы син, Кеше туганым,
Сәләтле син һәрбер иҗатка.
Дөнья дигән бөек китапка
Языла бара хезмәт юлларың,
Талантлы син, Кеше туганым.

каралты — төрле хуҗалык корылмалары
юлыкмады — очрамады

Сораулар һәм биремнәр.

1. Шигъри строфаларда бер үк сүзтезмәләрнең кабатлануын сез ничек аңлыйсыз? Шагыйрь аларны нинди максатта кулланган дип уйлыйсыз?
2. Шагыйрь Кешене ничек бәяли? Авторның биографиясенә бәйләп, шигырьнең эчтәлеген аныклагыз, шул хакта фикер алышыгыз.
3. «Сары каралты» сүзтезмәсе бу очракта нәрсә аңлата?
4. Шигырьне сәнгатьле итеп укырга өйрәнегез.

Газиз Кашапов

(1942—1991)

Газиз Кашапов (Газизҗан Салих улы Кашапов) 1942 елның 21 августында Татарстанның Аксубай районы Яңа Үзи авылында туа. Бик иртә ятим калган Газизне әбисе тәрбияләп үстерә. 1957 елда туган авылындагы җидееллык мәктәпне, 1960 елда Иске Ибрай урта мәктәбен тәмамлап, берничә ел авылда бухгалтер ярдәмчесе, тракторчы һәм клуб мөдире булып эшли. 1962 елда армиягә чакырылып, анда хәрби училищеда укый һәм 1971 елга кадәр хәрби хезмәттә була. Армиядә хәрби вазифа үтәгәндә яраланып, авырып китә, озак кына госпитальдә дәваланса да, сәламәтлеген ныгыта алмыйча отставкага чыгарга мәҗбүр була.

Туган ягына әйләнеп кайткач, 1973 елда Г. Кашапов Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегенә читтән торып укырга керә, төрле җирләрдә — Татарстан китап нәшриятында, Әлмәттә «Хезмәт байрагы» газетасында, КамАЗ радиотапшырулар редакциясендә, Татарстан Язучылар берлегенең Чаллы бүлегендә эшли.

Г. Кашапов иҗат эшенә 1970 елларда керешә. Аның җәмәгатьчелек игътибарын җәлеп иткән беренче күләмле әсәре «Сәмум җиле» повесте (1978) яшь авторның хәрби хезмәттә күргән-кичергәннәренә нигезләнеп язылган. Анда армиянең тыныч вакыттагы тормышы сурәтләнә. Моннан соң язылган «Солдат иртә ир була» һәм «Җир җылысы» повестьларында да язучының шәхси тормыш тәҗрибәсе үзен нык сиздерә. Прозаикның иң күләмле әсәре — «Язмышыңа ышан» романы (1987) хәзерге фән-техника прогрессы күренешен — атом электр станциясе төзелүне реалистик планда чагылдыруы белән киң җәмәгатьчелекнең игътибарын җәлеп итте.

Газиз Кашаповның соңгы иҗади казанышы — якташы, халык шагыйре Хәсән Туфанның әдәби образын тудырган «Киек каз юлы» романы (1992).

Вакытсыз дөньядан киткән Г. Кашаповның истәлеген мәңгеләштерү максатында туган авылы Яңа Үзидә аның музее ачылды.

КИЕК КАЗ ЮЛЫ

(*Өзек*)

Хизбулланың кәефе күтәренке, йөрәге дулкынланып-дулкынланып тибә, алга — Уралга таба ашкына. Кичәгенәк әзисе бик күптән көтелгән, артыннан йөри-йөри арып-талып беткән «пашпорт» дигән нәрсәләрне үзенә дә, абыйларына да, Хизбуллага да бит әле җитмәсә алып кайтты. Юлның башы бик әйбәт башлана, ә ахырлары ничек буласын кем белсен соң аның...

Ә мәшәкатьләр, китүдән элек бүтән төрле эшләр бик күп булды. Аларны зур әзисе белән әтисе, аннары Үзидән килгәләгән җизнәсе, ул да яңа җиргә китәргә уйлаган-ниятләгән икән, ничекләр генә башкарып бетергәннәрдер, Хизбулла төгәл белми, әмма хәленнән килсә булышырдай булып йөрде ул. Көн саен зур әзисе белән әтисенең Аксубайдагы вулыслар яныннан, аннары хәтта Чистайдагы өяз дигән төштән кайтканнарын түземсезлек белән көтте...

Язгы гөрләвекләр бетеп, Кармәт елгасының суы тонykланып, урамнарга яшел чирәмнәр шытып-шытып чыккач та, яңа җиргә китәргә ризалык бирелгән кәгазьне тотып, зур әзисе Сәгыйть кайтып керде.

Ул көнне Хизбулланың күңелендә бәйрәм булды, аның барлык тойгылары, омтылышлары кинәт кенә дуларга, бөтерелергә керешге. «Ниһаять булды, мин дә ерак җирләргә китәм, китәм, китәм»,— дип уйлады ул.

Әтисе белән зур әзисе ул кичне байтак кына сөйләшеп утырдылар.

Хизбулланың колагына кергәннәрдән һәм аны башта әллә ничек куркытып алган, аннары да озак кына борчып йөргән нәрсә — үзләренең, әтисенең, зур әзисенең һәм бүтәннәрнең, билгеле инде, Хизбулланың да фамилия дигәннәре юк икән. Моны инде Хизбулла Чистайда чакта ук белгән иде, әмма ул чагында моның әллә ни кирәге чыкмады, Хизбулланың да

андый нәрсәгә исе китмәде. Ә менә «пашпорт» дигән нәрсәне ала башлагач... иң беренче кирәк нәрсә шушы «пашпорт» икән... Нindидер бик кирәкле кәгазь икән ул үзе. Аңа язар өчен фамилия дигән кушамат кирәк икән.

Кызыктырмы, әллә инде кызганычтырмы, әмма дә ләкин Кармәт башында яшәүче кыпчак-болгарларның варислары булган мөселман-татарларның фамилияләре юк икән. Аргы як чувашларның бар, Хизбулла моны яхшы белә, ә менә бу яктагы татарларның юк. Алай гынамы, бөтенләй үк юк түгел ул, әмма бүтәннәрнеке кебек тә түгел. Әйтик, Иске Адәмсуындагыларның фамилияләре бар. Алар үзләренең бабаларының исемнәре белән язылалар. Бабасы, әйтик, Төхфәт икән, оныгы Төхфәтуллин була инде. Анда укырга баргач та малайлар Хизбулланың фамилиясе булган нәрсәдән көлгәннәр иде шул. Тик хәлфәләре аларны орышкачтын да, үртәшүдән туктаганнар иде.

Ул чагында Хизбулланы ни өчендер әнисенең исеме белән атыйлар — Гөлзизин, диләр, әтисен исә — Зөләйхин, диләр иде. Моның нindидер үртәшү икәнлеген белсә дә, Хизбулланың ачуы килмәде, чөнки әнисенең малае буласы бик килә иде ул вакытларда. Хәер, хәзер дә ул әнисен ярата, аның улы икәнлегеннән беркайчан да баш тартмый, әмма инде бөтен илдәге кешеләрнекечә булсын иде аның да фамилия дигән кушаматы.

Зур әзисе кайткач та, кичкырын, әтисе белән әнә шул хакта сүз чыкты. Хизбулла, билгеле инде, хәзер, соңгы елда бигрәкләр дә, әтисенең кул астына кереп киткән кеше, сүзгә кушылмыйча булдыра алмады.

Ул, сүз кузгалуга, әтисе белән зур әзисеннән:

— Нигә, нигә шулай Гөлзизин безнең фамилиябез? Нигә бүтәннәрнеке алай түгел, ата-бабаларының исеме белән аларның фамилияләре, безнеке исә әниебезнең исеме белән? — дип сорап куйды.

Әтисенең күзе кысылды, иреннәре юкарды, кашлары сикерешеп куйдылар. Ул зур улына, төпчегенә карап-карап алды, тамагын кыргалап чистартты һәм салмак кына, сынаулы карашы белән улларын гына түгел, өй эчен дә сөзеп ала-ала сөйләп китте.

—...Мәгълүм булсын сезгә һәм дә гомерегез буена онытмагыз, оланнар. Сез генә түгел, балаларыгызның балаларына да онытмаска әйтеп калдырыгыз. Бу хәлләр безнең каныбыз, халкыбыз яшәгән-тереклек кылган вакытта онытылмаска

тиеш. Чөнки бу җәбер-золымнар бары тик пәйгамбәрләр кичергәннәргә генә тиң. Бу хәлләрне сез үзегез дә беркадәр беләсез инде. Безнең Кармәт авылындагы кешеләр Ходайның каргышына юлыккан бәндәләрдер, мөгаен. Әле сезнең хәтердәдер: безне берничә тапкыр шул юлга бастырырга тырышып карадылар. Шул юлда иң соңгы корбаннарның берсе булып туганыгыз Нәсимә вафат булды. Безнең авылның күпчелек кешеләрен Явыз Иван патшаның иярченнәре чукындырганнар. Кабатлап әйтәм, күпчелеген чукындырганнар. Ул афәттән сакланып калучылар берничә гаилә генә булган. Аларны Олы аралар диләр. Ә без исә Кече аралар саналабыз. Безнең динебезне пычратканнар, чукындырганнар. Әмма ләкин ул — көчләп кылынган золым. Безнең бабаларыбыз аны санга сукмаганнар һәм барыбер үз диннәрен саклап килгәннәр. Бирелмәгәннәр-сатылмаганнар! Шуның өчен дә аларны, әрхәрәйләр килеп, алар бөһтаны буенча инде, аннары гөбернатордан килүчеләр, бөтен хокукларыннан, кешелек хокукыннан, җирдә яшәү хокукыннан мәхрүм иткәннәр. Моны сез дә беләсез әле. Безнең бит әле бишенче елдан соң гына мәчетебез булды, аннары гына кечкенә булса да мәдрәсә ачтык, шуннан соң гына халыкның бәйрәмнәре уздырыла башлады. Шуннан соң гына кяферләргә кушылырга өндәүчеләр күренми башлады, Аллага шөкер. Менә шул... безнең авылның кешеләре, әрхәрәйләрнең тырышлыгын аяк астына салып таптап, үзләренең диненә гел кире кайтканнар. Шуның өчен дә аларны мөкрәһләр дигәннәр. Урыслар исә «отпавший»лар дип мыскыллыйлар... Шуның өчен безнең авылда үз баласына үз исемен бирергә, фамилиясен ата-бабасыннан башлап язарга ярамаган. Ләкин бит бәндәне ничек тә булса атарга кирәк. Шуның өчен дә әрхәрәй иярченнәре — мәкерле җаннар, безне мыскыллап, гомер буена үзебезнең кем икәнлегебезне онытмасын өчен, фамилия кушканнар, кушканнар, ләкин кешеләрнекечә түгел, аны мыскыллап-мәсхәрәләп кушканнар — анасының исемен балага фамилия иткәннәр. Шулай итеп минем фамилиям, кәгазьдокумент дигән нәрсәләргә языла торганы — әбиегез исеменнән чыга да Зөләйхин була. Әзиләреңә дә, сиңа да, Хизбулла, теркәгән вакытта ук әниегезнең исеме белән йөрергә куштылар — Гөлзизин ясадылар. Дөрес, без авылда алай дип телгә алмый идек, без бит әле атасының яки бабасының исеме белән йөртә килдек. Безне әнә алдыбызда да, артыбызда да дигәндәй — Дуфанның Фәхри-Таһиры, ә сезне исә, Дуфан Фәхри-

Таһирының Сәгыйте, йә булмаса, Хизбулласы, диләр... Әмма соңгы вакытта, бигрәкләр дә мәчет салганчы, мине, беләсез бит инде, үзебезнең тирәләр, авыл халкы сораганга күрә халык йоласын башкарып килүче булганга, зурлап-хөрмәтләп Хәзрәт дип йөртәләр. Сезне дә, ишеткәнем бар, кем балалары дисәләр, Хәзрәт балалары дип белгертәләр. Шулай булгач та, балалар, минем сезгә сүзем шул: чит-ят җирләргә китәргә рөхсәт алып кайткач, хәзер инде «пашпорт» та бирәселәре булгач, сез үзегезне әнә шулай итеп — Хәзрәтовлар итеп яздырырсыз дип уйлап торам мин. Сезгә сүзем шул минем. Ә теге хәлләр турында, үзебезнең тарихыбыз турында — Болгар бабаларыбызның, Биләр халкының, аннары инде Казаныбызның ничек-ничек харап булулары турында сез онытмасын өчен Дуфан бабагыз язып калдырган «Борынгы дәфтәр» бар. Ул дәфтәрне Дуфан бабагыз Җаббар бабагызга сакларга биреп калдырган, аны ул миңа бирде һәм биргәндә, Хизбулла дөньяга килеп аңа исем кушкан мәҗлестә, шушы балаңа әманәт итәрсең, диде. Шулай булгач, ул дәфтәр әлегә миндә сакланыр, урынын беләсез, Хизбулла, син беләсең, мин вафат булсам, әгәр дә мәгәр, гомерләрем булып, сезнең белән яңа җиргә — яңа йортка күчәсе булса онытмагыз, иң башлап шул дәфтәрне алыгыз, әгәр дә... Карагыз аны, бабайлар рухы безнең шунда саклана, сезнең йөрәкләрегезгә шуннан салына инде ул...

Әтиләре сөйләгәннәрне Хизбулла аннан-моннан сөйләгәннәрдән, хәтерендә уелып-уелып калганнардан белә иде инде, әмма бу хәтле аныклап ишеткәне юк иде. Хәзер инде ул моны гомеренең буена да онытмас, онытмас, әлбәттә. Шулай да киләчәк юлга китәр алдыннан фамилия дигән нәрсәне, әнә бит, теге вакытта Адәмсуында да көлделәр малайлар, ничектер Хәзрәтов белән бәйләмәскәдер иде...

Ул, әтисенең туктап калуыннан файдаланып:

— Әти, этием,— диде.— Син ачуланма, зинһар, без бит синең сүзеңне тыңламаска җыенмыйбыз, тик минем үземә, нишләптер, фамилиябезне бүтәнчәрәк яздырсак яхшырак булмасмы дигән фикер килде әле.

Әтисе Хизбуллага таба гаҗәпләнеп карады, ә әзисе исә аның ботыннан чеметеп алды. Дөрес тә, чөнки моңарчы бу өйдә ата-ана сүзенә каршы төшкән кеше юк әле. Мондый кирелек хәерлегә саналмый да.

— Йә, алайса, атаң әйткәнне ошатмыйсың икән, ничек димәкче буласың соң? — диде әтисе, күзләрен кысып, ирен-

нәрен юкартып: — Әйтеп кара соң, сүзеңне-фикереңне. Азау тешең чыга башлаган сыман күренә синең дә...

— Әгәр дә, эти, син безнең бабайны шундый да акыллы, уңган-булган һәм бөтен тирә-якта да абруйлы кеше дисең икән, аннары бөтен авыл халкы безне Дуфаннныкылар дип йөртә икән, нигә соң безгә ул «пашпорт»ка да Дуфаннар дип яздырмаска?

Хизбулла этисе орышыр дип туктап калды, чөнки зур әзисе икенче тапкыр инде аның ботыннан чеметеп куйды. Этисе исә башта кашларын гына түгел, иреннәрен дә бераз бөрештереп тыңлаган булса, хәзер, төпчек улының сүзен ишетеп мәгънәсенә төшенгәч тә, ихтыярсыздан елмаеп куйды, аның йөзе ачылып китте.

— Бик хуплар идем дә бит, улым,— диде ул.— Бу — бабаңның исеме түгел, кушаматы... Аның холкына карап шулай дигәннәр. Анысын, анысын инде, Хизбулла, әгәр дә мәгәр, уебызны гамәлгә ашырып, сине «Галия»ләрдә укытып чыгарсак, аннары инде син үзең дә Гаяз хәзрәт Исхакый, Нәҗип хәлфә кебек була башласаң, исемеңне шулай итеп куярсың. Әнә бит ул да язганнарының астына авылның исеме белән куя — Думави, ди. Аннары инде минем дусларым, Бубый авылындагы дусларым Гобәйдулла белән Габдулла да, үзләрен Бубый дип йөртәләр, югыйсә бит алар Фәйзулла аты белән йөрергә тиешләр...

Хизбулла инде бу хакта әллә ничә тапкыр уйлаган иде. Нәҗип хәлфәдән күреп тә, аннары газеталардагы шагыйрьләрне, хикәят, кыйсса язучыларның исемнәрен күреп тә, «әгәр дә мәгәр мин дә шулай яза башласам, исемнәрне Кармәти дип куярмын дип ниятләнгән иде. Бу хакта хәтта бер тапкыр Хәсәнҗан абзыйсы белән дә киңәшкән иде, ул да бу фикерне хуплаган иде... Ә менә этисе... этисе аңа бигрәкләр дә тылсымлы, эченә әллә нинди әйтелмәгән-күрелмәгән мәгънәләр салган исем алырга куша түгелме соң?

— Ярар, алайса, эти, шулай булыр,— диде Хизбулла, күзләрен уйчанландырып, үзе дә сизмәстән татлы хыялларга бирелә башлап.

— Юк инде, эти, мин үзем дә, Мөхетдин белән Зөфәр дә синеңчә яздырабыз, Хәзрәтов булабыз. Андый укымышлыларның аның рәте-чираты бер дә булмый,— дип куйды Сәгыйть әзисе, Хизбуллага карамыйча гына.— Эш муеннан, әнә алган шахтабызны казырга, атлык, йорт-җирлек акча

тупларга кирәк... Уен белән мавыгырга өлгерерсең әле... Әнәгенәк быел кайткач Касыймны да җибәрергә исәбебез юк. Чөнки бит бакырны кем казый? Укып юньле кеше булмас барыбер. Кяфер уйлары гына керә күңелгә... Син җыен, җыена тор, мин бит сине алып ук китәм үзебезнең янга, әти белән дә шулай сүләштек инде,— диде.

Әтисе олы улының сүзләренә колак сала иде инде.

— Ярар, шулай эшләрбез, Ходай язганча булыр,— диде.

Губернатор дигәннәреннән рөхсәт алуын алганнар, әмма ләкин ул гына читкә китеп барыр өчен җитми икән әле. Әле тагын вулыста да, өяздә дә шул «пашпорт»ларны бирүчеләр бар икән. Ә алар янына барганда коры кул белән барырга ярамый икән. Чөнки коры кашык авызны ерта икән, аны шуның өчен дә, тегеләрнең авызларын ертмасын өчен, майларга кирәк икән. Майлар өчен кем акча... ничектер инде ул, акча белән майлап була димени? Ә, әйе, акчасын бирәләр дә май алып киләләрдер инде, ә кем инде сарыктыр-нидер суеп алып бара икән. Кайсыберләр исә балын да эләктереп бара да шуны иплэп кенә тегеләргә бирә икән. Шуннан инде тегеләр үзләренең ишләре белән уртаклашалар, тиешле кәгазь «пашпорт»ны язалар икән...

Зур әзисе белән әтисе шул хакта озак сөйләштеләр. Ахыр чиктә Аксубай вулысындагыларга әтисе белән барырга, ул андагыларны белә иде, ә инде өязгә барганда Закирҗан җизнәсен алырга булдылар. Ул теге вакытта, Сираҗетдин абзый артыннан йөргәндә, андагыларны тәмам белеп бетергән икән, кемнең нәрсә теләгәнен дә бик яхшы белә икән...

Кирәк- яракларны әзерләделәр. Сөйләшеп-белешеп кайткач та, башта бер сарыкны, аннары инде, тегеләрнең абжур авызлары туймыйча, тамаклары тыгылмыйча калса, тагын былтыргы бозауны да кызганмаска иттеләр. Әтисе ул бозауны бик яратып карый иде, ялан гына: «Моңардан бик мул сөт бирә торган сыер булыр»,— дия иде дә бит...

Зур әзисе Сәгыйть, кайсы көннәрдә әтисе дә вулыс юлын таптый башладылар. Кызык кына икән ул «пашпорт» бирүчеләр, бер барасың, вакытлары булмый — нәрсә турындадыр сөйләшеп утыралар, икенче барасың — вулыс башлыгы юк, аның рөхсәтеннән башка язарга ярамый, өченче барасың — вулыс башлыгы бар, тик инде тегесе, «пашпорт»ны язып бирүчесе юк. Дөрестән дә, мәчегә уен инде бу, әмма бит тычканга шактый кыен булып чыга ласа...

Беркөнне зур әзисе, аннан кайткач та:

— Безнең Урал шахталары ягында булсамы, бу бәндәләрне бик тиз акылларына утыртырлар, болай тинтерәтеп йөретергә ирек бирмәсләр иде инде. Рабучийлар мондый кимсетүләргә һич ирек куймыйлар, хәзер бастовать итәләр,— дип кызыпкызып сөйләде. Ул үзе, зур әзисе, алай тиз кызып китә торганнардан түгел, һәр нәрсәне биш кенә түгел, җиде кат уйлый инде, ди әтисе аның турында. Сабыр гына, салмак кына карарга килә, аннары инде аны үзенең сүзеннән кайтарырмын димә, ди.

— Иртәгә сине дә алып барабыз Аксубайга,— диде зур әзисе кичкырын.— Карточкага төшәргә кирәк.

Хизбулла өчен бу яңалык иде. Дөрес, ул инде кешеләрнең карточкага төшкәннәрен күргәне бар. Рәсем кебек була, кешенең үз төсен, аның бер мәлен туктатып төшерә дә калдыра. Чистайда укыганда хәтта малайлар белән, Нәҗип хәлфә белән бергә барып шул сурәткә төшәргә дип тә сүз беркетеп куйганнар иде. Хизбуллага көтмәгәндә-уйламаганда кайтып китәргә туры килгәч кенә, ул ниятләрен башкарып чыга алмадылар. Малайлар барып өлгерделәрме икән? Белмим шул, юктыр, Хизбулла кайтып күпме генә торды ул чагында, Касыйм әзисе кайтып Иж-Бубый мәдрәсәсенең туздырылуын, Нәҗип хәлфәнең дә кулга алынуын белдерделәр...

Гадәттә әтисе дә, аннан күреп инде зур әзисе дә, вулыска барасы булса, иртә таңнан торып чәйләр эчәләр, кеше-кара йөри башлаганчы, югыйсә аларның кайсысы очрый бит әле, авыр аяклысы очраса, көт тә тор, юлың уңмый да уңмый, шуның өчен дә, соңыннан теге бичарага «аягың авыр булды» дип ачылышлы булганчыга хәтле, иртә белән көтү куа башлаганчы ук чыгып китүең хәерлерәк.

Бүген дә шулай иттеләр. Хизбуллага, сурәткә төшәсе булгач, яңа күлмәген, яңа кәләпүшен, аягына әтисе тегеп биргән, «Галия»гә баргач кына киярге дигән читекләрне кигерттеләр. Аның өстеннән ялтырап торган калуш та кигәч, зур әзисе әйтмешли, Хизбулла бөтенләй көязгә әверелде, сәүдәгәр малае булды. Ни өчен шулай сәүдәгәр малаена охшаткандыр инде әзисе, Хизбулла моны төпченеп тормады.

Кузгалдылар. Капкадан чыктылар да урамга, бигрәк тә китәсе якка таба күз салдылар, бер кеше дә күренми, урам бупбуш иде.

— Хәерле сәгатьтә! — диде әтисе.

— Амин,— диде гадәтенчә капка төбенә чыгып басып, авызын яулыгының чите белән каплап баскан әнисе.— Амин, Ходаем...

— Киттек,— диде зур әзисе.— Тугыз чакрымны атлыйсы бар...— Аннары өстәп куйды: — Әнә тегендә, тау башына менгәч тә ял итеп алырбыз, иртәрәк булса... Аннан Аксубай уч төбендәге кебек инде.

Зур әзисе кузгалды, аның артыннан, яңа гына тегелгән, әле киеп язылмаган читекләрен шыгырт-шыгырт иттереп, Хизбулла да көяз генә атлап китте.

Бераз баргач та, артларына борылып, әтисе белән әнисенә «керегез инде» диделәр дә тагын алга таба атлый башладылар.

Ике йорт үткәч тә, Бәдрун Минаплары тыкрыгы чатыннан узабыз инде дигәндә генә, чаттан Козгын Әзгаре килеп чыкты. Зур әзисе, аны күргәч тә, өлгеррәк атлап, тыкрык чатыннан узып китмәкче булган иде, ахрысы, әмма өлгерә алмадылар. Козгын Әзгаре аңа каршы чыгып басты.

— Кая болай ашыгасыз, Дуфаннар кебек?..

— Кая кирәк җиргә ашыгабыз, Әзгар абзый, кая кирәк төшкә,— диде зур әзисе, бер дә генә тартынып тормыйча.— Үзеңнең арбаң юлыңда булсын...

— Ә, алай икән,—дип сузды Козгын Әзгаре.— Беләм инде, беләм, яңа җиргә китеп олагырга җыенасыз. Анда китеп кенә... Әллә анда барган яңа кешеләрне дә мондагы кебек котыртып ятарбыз дип уйлыйсызмы? Юк, анда да...— Козгын Әзгаре әйтеп бетермәде, шулай да аның тел төбендә ятканны, «анда да безнең кебек шымчылар табылыр, алар күзеннән арына алмассыз» дигәнне зур әзисе генә түгел, хәтта Хизбулла да төшенде инде.

— Ничава,— диде Сәгыйть әзисе. — Без рабучий халыкка әллә ни кирәкми, яшәргә йорт-җир җиткерсәк...

Акыллының теле күңелендә, акылсызның күңеле телендә дигәндәй:

— Зимагурларга күп кирәк инде ул, югыйсә нишләп шулай йөрер идегез. Шуннан, сез зимагур-алаканатлардан кайта да инде бөтен коткы,— дип үҗәтләнде Козгын Әзгаре.

Көтмәгәндә генә зур әзисе Козгын Әзгаренең янына ук барды да аның колагына нәрсәдер, нибары бер-ике сүз генә әйтте. Симез ат, артык туйса, лыпшык була икән, тегене корт чакты диярсең, сикереп куйды, күзләрен алаландырып, Хизбуллага таба карады да:

— Ярый ла, ярый ла, Сәгыйть, мин бит, мин бит юри генә, кызык өчен генә сөйләнәм, әллә шуны да белмисеңме,— диде теге,— юлыгызда булыгыз...

Алар киттеләр, авылны чыгып юлга төшкәнче, бүтән бер кеше дә очрамады.

— Зур әзи, син Козгынга нәрсә дип әйттең, колагына нәрсә дидең?

— Әйттем инде, сиңа андый сүзләрне белергә ярамый,— дип кырт кисте әзисе. Хизбулланың моңа бераз гына үпкәлисе килде килүен, тик әзисенең холкын бераз белгәнгә күрә дәшмәде, иреннәрен турсайтыбрак бераз атлады да аннары иртәнге кырларга, үләннәргә, алар өстенә куна-куна очкан кошларга, ерактагы офыкка карап бара-бара онытылып ук китте.

Эх-ма, дип уйлады ул. Китәсе иде менә шундый басуларның ярмаланып торган туфраклы сукмаклары белән еракеракларга, офыкның читенә таба барасы иде дә күгелҗем-яшькелт күк эченә кереп китәсе иде. Анда, әллә нинди болытлар артындагы дөньяларда,ниләр генә юктыр. Анда кешеләрнең дә бик кызыклары бардыр, мөгаен; очрашулар, төрле нәрсәләр — могҗизалар күреп йөрисе дә йөрисе иде. Әнә теге китаплардагы дәрвишләр кебек: телисең икән — Бохарага барасың, телисең икән — Сәмәркандка таба юл тотасың. Сине берәү дә туктатмый, берәү дә сиңа тузга язмаган исем-фамилия кушып үртәшми, синең кем икәнлегеңне дә белергә теләми. Ә син атлыйсың да атлыйсың. Юлыңда сиңа кызык хәлләр очрый, бәлки Хуҗа Насретдинга юлыгасың. Ә инде бәхетең бик алга китсә, көт тә тор, Хозыр Ильяс бабай үзе синең каршыңа килеп чыга да сиңа гомерлек киңәшен бирә. Ярдәмен итә. Юк, Хизбулламы, Хизбулла башта, моннан чыгып киткәч тә, мөгаен, Чистайга барыр иде, анда инде теге мәдрәсәдәге малайлар янында кунып чыгар, алар белән күреп сөйләшер иде. Юк, алар, билгеле инде, күбесе мулла булырга җыеналар, Хизбулланың чакыруына кушылмаслар, дәрвишлеккә, илләр гизәргә чыгып китмәсләр. Китмәсәләр бит, Хизбулла аларны чакырып та тормас, әнә тотар да теге урыс малае Алеша — Лешага әйтер. Ул инде теләсә кайсы якларга китәргә дә әзер. Ул бит теге вакытта да Хизбуллага: «Беркөнне мин сине пароходта йөртеп кайтам әле»,— дигән иде. Димәк, инде аның пароходларга утырганы бардыр... Китәрләр икәү аның белән чыгып, Хизбулла аңа әйтер: «Безнең, дияр, Алеша, борынгы башкалабыз шәһәре булган Болгарны карап узыйк әле, дияр.

Миндә, дияр, бер борынгы дәфтәр бар, дияр, шунда язылганнарны сөйлим әле сиңа, дияр. Юл озын, сөйләргә, күп нәрсәне сөйләргә мөмкин ич. Китәрләр шулай борынгы Болгарны карарга, бабайлар җирен күрергә. Аннары инде, аннары бәлки дә Иделгә чыгарлар, әгәр дә мәгәр аларны тотып алып пароходларыннан куып чыгармасалар, ары таба да барырга мөмкин. Дөрес, алай пароход эченнән генә күп нәрсәне күреп булмыйдыр инде, Хизбулла юлдашын җәяү барырга чакырыр. Ә нигә, авылдан авылга, авылдан авылга барасың да барасың, «Кая барабыз, Хизбуш?» — дияр теге. Хизбулла исә аңа вәкарь белән генә: «Без, дияр, хәзер синең белән минем бабайлар һәм дә эти йөргән далалар аша Комык якларына юл тотарбыз. Анда, беләсеңме, дияр, сөт тә, май да, ит тә буа буарлык, мал күп, шунда тукланырбыз да, тегесен-монысын да карарбыз. Далаларны күрербез, андагы кешеләр бик киң күңелләләр дип сөйли иде эти, адашмабыз... Җәй буена шулай йөрербез, ә аннары, аннары инде, далаларда көтүләр көтеп, мин бәлки комык балаларына бераз сабак та укытырмын, шулай итеп акча эшләгәч тә, без синең белән, Алеша, китәрбез, китәрбез... Беләсеңме, кай тарафларга?» «Белмим»,— дияр аңа Алеша, зәңгәр күк кебек күзләрен елтыратып. «Белмәсәң бел,— дияр Хизбулла аңа,— без синең белән хәзер Уфа дигән шәһәргә юл тотарбыз. Анда, беләсеңме, шундый бер мәдрәсә-мәктәп бар, анда бик күп җирләрдән килгән балалар белем ала. Анда укып чыкканнар барысы да зур әдипләр булалар, шаирләр-язучылар булалар...» «Ә анда сезнең ул мәдрәсәгезгә мине алырлармы соң, мин бит, мин бит урыс баласы»,— дияр Алеша. Хизбулла дәшмәс, чөнки ул монысын белеп үк бетерми. Чистайдагы мәдрәсәдә бер генә урыс баласы да юк иде... Мөгаен, мөгаен алмыйлардыр... «Ярар ла, алмасалар бит, син шунда, шәһәрдәге бүтән школага керерсең, сезнең кебек урыс балалары өчен дә школ бардыр бит...» Алеша зәңгәр күзләрен елтыратып алыр да: «Юк инде, Хизбуш, дияр, син укырга яратасың, әнә әллә нинди китапларда язылганнарны сөйлисең, мин аларны тыңларга яратам, тик, малай, нишләптер, аларны укып утырырга минем түземлегем җитми. Мин кермәм андый мәдрәсәгә, шунда яшәрмен. Берәр завод кебек нәрсә булса, шунда эшләрмен җәйгә хәтле өйрәнчек булып... Ә аннары, аннары инде без синең белән сәяхәтебезне дәвам итәрбез...»

Аксубайның Кармәт башыннан барып кергән урам очында ук аларны өчме-дүртме эт бөтерелеп чыгып каршы алды.

Ярый ла әзисенең кулында таягы бар икән, ул шуның белән селтәнеп-селтәнеп аларны куркытмакчы булды. Тегеләр бөтерелеп киләләр дә шул таякны тешләп-тешләп алмакчы булалар, әмма таяк та җитез генә аларның берәр төшенә кунып алырга өлгерә, чинап җибәрәләр дә читкә сикерәләр. Байтак кына шулай эт-көчекләр белән этләшеп бардылар. Аннары, алты-җиде йортны узгач та, бер кое янындагы олы гына гәүдәле, бөтен битен-авызын сакал-мыек баскан чуваш агай чыгып тегеләрне куып җибәрде.

— Ычта кайан, Дуфан апзый малае? — диде ул зур әзисенә.

— Вулыстан,— диде зур әзисе яшермичә.

— Фахри-Таһир питчәй авани?

— Лаех ку, бик лаех.*

— Яңа җиргә аны да алып китәсезме? Ай пусы начар пит, без монда аннан пашка нишләрпез? Ул пит пезгә пич тә чыгара, тәрәз дә куя, рамнар да ясап бирә иде,— диде теге абзый, бер сүзне татарча, икенчесен чувашчалап.—Ай якшы та кеше, якшы та кеше инте...

— Кайтканда кереп чык пезгә, пәрәңге пешереп ашарпыз... Лаех?

— Мужыт керербез дә әле, Ерофей бабай,— диде Сәгыйть әзисе. Хизбуллага бу Гарәфи абзый дигәндәй ишетелде.— Рәхмәт чакыруыңа.

Тагын бераздан, Аксубайның уртасыннан агып ята торган кечкенә генә бер елга аша салынган агач күперне чыккач та, сул яктагы вулыс йортының аскы каты таштан салынган бинасы яныннан уздылар.

— Менә шушында инде этине яткырдылар теге вакытта,— диде зур әзисе.— Өтермә булыр. Бик күп укыган кешеләрнең мондый йортны урап үтәсе юк аның,— дип өстәп куйды тагын...— Укыган кешене чукынган кеше диләр аны...

Хизбулланың әзисе, үзе Иж-Бубыйда укыган булса да, нишләптер аны укытырга бик теләми иде бугай.

— Пашпортны да шушыннан килеп алабыз,— диде әзисе.— Син курыкма, безне хәзер үк япмаслар әле. Бер үгездән ике тире тунамыйлар, ни булса да булыр.— Ул көлеп куйды,

---

* — Дуфан абзый малае, кая барасың?

— Вулыска.

— Фәһри-Таһир агай исәнме?

— Бик яхшы әле, яхшы...

аннары Хизбулланың аркасына кулын куйды да алга таба әйдәп китте.— Әйдә, хәзер карточкага төшәргә барабыз...

Козгын Әзгаре димәссең, аягы җиңел булды тагын. Әллә ни озын-озакка сузмыйча гына карточкага да төштеләр, аннары соңыннан гына паспорт бирүчегә дә керделәр. Аннан зур әзисе елмаеп ук чыкты. «Булды, киләсе атнага килеп алабыз «пашпорт»ларны,— диде ул, Хизбуллага карап. Түлке... түлке бит зур әзисе аркасындагы капчыкны онытып калдырган лабаса... Ул шундук:

— Әзи, әзи, син бит аркаңа асып кергән капчыкны онытып калдыргансың лабаса,— диде Хизбулла, коты алынып. Зур әзисе аңа әйтеп бетерергә ирек бирмәде, тартып китерде дә үзенә кысты. Аннары гына Хизбулланың колагына табарак иелә төшеп:

— Онытмадым ла... Сүләмә аның турында... Ярамый... Ишетерләр,— дип пышылдады.

Хизбулла аңлады. Әнисе теге сарык ите янына тагын бер каклаган каз да куйган иде шул... Хизбулла исә: «Куна калсак, ашарыбызга бар әле»,— дип уйлап тора иде...

Бер атнадан дигәне тагын ун көнгә сузылды әле. Ниһаять, көннәрнең берсендә алар әтисе белән бергә китеп бардылар. Алар бу юлы өч көн йөреп, Хизбулланың түземлеген байтак сынаганнан соң гына, Закирҗан җизнәсе белән өчәүләшеп кайтып керделәр.

Кайткач та зур әзисе:

— Иртәгедән аннарыга, җомга көнне кузгалырбыз,— диде.— Җыен...

Хизбуллага нәрсә, аның инде җыенасы җыенган. Киемнәрен әнисе күптән әзерләп куйды. Әтисе исә үзе ят якларда йөргәндәге тал чыбыкларыннан үргән сандыгын бирде, киемнәрен, оекбашларын шуңа җайлап куйдылар. Теге вакытта җизнәсе алып кайткан «Су анасы» китабын, тагын берничә китап-дәфтәрне шунда салды, төбенә үк яшереп куйды Хизбулла һәм эшен беткәнгә санады.

Шунда гына ул үзенең Хәсәнҗан абыйсы, аннан да бигрәк Әминәне күреп, алар белән сөйләшмичә китә язганын исенә төшерде һәм, тиз генә өйдән чыгып, аларга таба китте.

Хәсәнҗан абзый өйлә намазында булып чыкты. Әминәнең әнисе дә каядыр чыгып киткән икән. Хизбулла барып кергәндә, кызый ишегалдында чебеш ашатып йөри иде.

Капка ачылган тавышка борылып карады Әминә. Хизбулла аның күз карашыннан, элеккеге кебек аңа каршы басып,

оялып кына, каш астыннан гына булса да аңа таба карамавыннан, эшли торган эшеннән аерылмавыннан ук аңлады: Әминә үпкәләгән иде.

Хизбулланың тәне эсселе-суыклы булып китте. Ничек-ничек соң ул әллә кайчан ук Әминә янына килмәгән? Менә бит үзсөяр, дип, үз-үзен битәрләде Хизбулла. Өфертеп җибәрергә дә бик урынлы булыр сиңа, диде. Ничек соң ул, үзенең китәсен белеп тә, аны күрмичә йөргән әллә ничә көн буена. Ә бит, ә бит теге вакытта, печән җыйган чакта... Баткак елгасы буендагы болында нинди матур сөйләшеп йөргәннәр иде алар...

Печән чабарга керешкәннең икенче көнендә, өйлә вакытлары узгачрак, Әминә аларга ашарга китерде. Әтисенең кичектерелмәс эше чыккан икән, шуның өчен Әминәсен атка утыртып җибәргән. Ул килгәндә, Хизбулла кичә тапкан чишмәсен зурайтып, аны тирәнәйтеп, үзләре алып килгән чиләк белән суын-пычрагын түгеп кайнаша иде. Куллары чалгы сабын тотарга авыртса да, ул бирешергә теләмәде, иртә белән үк әтисе янәшәсенә басты. Әтисе аңа:

— Бүгенгә сабыр итәсеңме әллә, Хизбулла улым,— диеп караган иде.

— Юк! — дип кырт кисте ул. Һәм берничә пакусны чыкты да. Ләкин төн эчендә кипшенгән, бераз тартыла башлаган ярадан кабат кан сава башлады, әчеттерергә кереште. Телисеңме-теләмисеңме, туктарга туры килде аңа.

Әминә, килеп җиткәч тә аңа таба килеп:

— Ә син ялкау Хизбулламы әллә, нигә печән чапмыйсың?— дип, елмаеп-көлеп сорады. Билгеле инде, шаяртып әйткәндер ул, тик барыбер Хизбулланың моңа беркадәр ачуы чыкты.

— Ә синең ни эшең бар аның хәтле? — дип ычкындырды.

Әминә эшнең нәрсәдә икәнен аңлаган иде инде. Хизбулланың дорфалануына исе китмәде. Арбасыннан төште дә, Хизбулланың янына ук килеп:

— Кая, күрсәт әле? Күрсәт кулыңны,— диде.

Хизбулла үзе дә сизмәстән аңа буйсынды, учларын өскә таба тотып Әминәгә күрсәтте. Әминә аларны үзенең ике кулы белән берьюлы тотып алды, үзенәрәк тартып китерде һәм, көтмәгәндә генә: «И-и-и, мескеннәремне нишләткәннәр, ничек кабартып чыгарганнар, ничек канатып бетергәннәр»,— дип, шундук «өф-ф-ф, өф-ф-ф» дип өшкергәндәй итеп алды, аннары тагын «тьфү-фү, тф-фү» дигән булды да... үбеп алды.

Билгеле инде, моңарчы әле Хизбулланы әнисеннән башка берәүнең дә «пәп» иткәне юк иде, аңа бик җиңел булып китте. Ул рәхмәтле күзләре белән, ләкин әле һаман да шикләнебрәк Әминәнең күзләренә карады. Аларда, Әминәнең коңгырт, күк йөзе сыман тирән карашында шаяруның әсәре дә күренми иде. Хизбуллага җиңел, шундый рәхәт булып китте.

— Нишлисе-е-ең?— дип куйды Әминә берни булмаган сыман, Хизбулланың кулын җибәрмәгән килеш, ияге белән генә чишмәгә таба ымлап.— Нишлисе-е-ең?..

— Чишмә ачам, аның күзе томаланган,— диде Хизбулла.— Моннан күп еллар элек, ди әти, бу чишмәнең суы шундый тәмле иде, ди. Аны, маллар йөртеп, тирә-ягын ишкәннәр, аннары инде ул үзе үк томаланган, ди...

— Ярар, алайса, мин бу чишмәне Хизбулла чишмәсе дип атармын, яме?

Әминәнең күзләрендә әллә нинди бер моңсулык ята иде.

Хизбулла дәшмәде. Аңа карап торды, шулай да, дип уйлады ул, бу Әминә дигән кыз аңа авылдагы барлык кызлардан да якынрак, аның белән сөйләшүе дә җанга рәхәтлек өстәп тора, күңел дә күтәрелеп китә...

— Беләсеңме, Хизбулла,— диде Әминә тынычланып, басынкы тавыш белән.— Беләсеңме, мин дә быел көзгә авылдан китәрмен, ахрысы. Чөнки бит... былтыр үзебезнең әни үлгәннән соң килгән яшь әни, яшь әни...— диде Әминә һәм сүзен дәвам итә алмыйча елап җибәрде. Күрәсең, аның күңеле тулган булгандыр инде...

Хәзер инде Хизбулла баскан җиреннән Әминә янынарак күтәрелде. Аның куллары ирексездән Әминәнең җилкә башыннан сыйпап, аркасыннан җиңелчә генә кагылып үтте.

— Нитмә... Әминә, елама-моңайма син. Хәсәнҗан абзый сине беркайчан да ташламас, сине ярата бит ул. Ул бит сине укырга илтермен генә диде.

— Әйе, ул мине быел Аксубайдагы урысча мәктәпкә бирмәкче була... Ничек барырмын? Мин бит анда... урысча белмим... Мулла кызы башым белән... Авылга кайтып ничекләр күренермен икән соң?

Монысына җавапны Хизбулла үзе дә белми иде. Шулай да тынычландырырга теләп, ул:

— Урысчаны өйрәнерсең, анысы аның берни дә түгел. Мин бит өйрәндем әнә, аптырамыйм хәзер,— диде.

— Ә без, Хизбулла, син дә Уралыңа китсәң, бүтән сөйләшмәбез, очрашмабыз микәнни инде? — диде Әминә, баягы халәтеннән чыгып, ягымлы итеп карый-карый.— Хатлар да язышмабызмы?

Хизбулла җанланып китте.

— Әйе шул, нишләп хатлар язышмабыз икән без? — диде ул.— Әнә бит әзиләрдән хатлар килә безгә. Мин дә сиңа язармын...

— Кешеләр белмәсләрме икән соң?

— Син бит Аксубайда булам дисең.

— Булам да бит... Ә син, син, Хизбулла, миңа ничек тә булса бүтән исем белән яз. Аны без икәү генә белик, ул безнең серебез булыр, яме,— диде.

Хизбулла бу хакта уйламаган иде.

— Ничек әйтим соң? Үз исемең дә бик матур бит. — Әминә бу хакта уйлаган булып чыкты, ахрысы.

— Син миңа, беләсеңме, ни дип... Миңниса дип яз. Ул безнең әнинең авылдагы сеңлесенең исеме. Ул апа шундый матур, шундый ягымлы иде... Былтыр суга батып үлде...

— Миңниса... Миңниса... Ниса, — дип җибәрде һич көтмәгәндә Хизбулла, әлеге исемне кыскартып. Һәм шундук шатланып:

— Ниса, Ниса диярмен мин сиңа. Авылда юк исем, берәүнең дә башына килмәс. Гел Ниса диярмен, яме?

— Ярар соң,— диде Әминә.—Болай тагын да матуррак кебек...

Ул көн шундый матур, шундый истәлекле булып узды ки, печән өсте беткәч тә, аннары җәйге урак өсләрендә дә, көзге якка чыккач та Хизбулла аны гел шулай дип, үз итеп, серле итеп, Ниса дип кенә йөртә башлады.

Көннәрнең берендә исә ул үзенә дә исем тапты. Ул Әминәгә:

— Син мине, Әминә, беләсеңме ничек дип ата. Искәндәр диген, яме.

— Кем соң ул?

— Мин аны бер китапта укыган идем. Искәндәр ул бик зур бер кеше булган. Аның турында әллә нинди риваятьләр бар икән. Патша да булган, сугышларда бик батыр булган...

— Ярар, әйтермен соң,— дип килеште Әминә-Ниса.— Үзеңә ошаса, миңа бик ошый, авылда юк исем...

Инде менә Хизбулла китә. Дөрес, былтыргы көзне Әминәне дә әтисе Аксубайга илткән иде, ләкин ул анда ике-өч ай гына

укыды. Авылның усаллары, Гобәш картның Нуругы, Хәсәнҗан абзыйның йөзенә бәреп:

— Син, мулла, үзең мулла башың белән кызыңны урыс авылына алып барып, урысча укырга бирдең. Кемнән сорап эшләдең син моны? Бөтен мәхәлләне мыскыл итеп. Үзең бит безне мөселман булырга чакырдың. Авылга килеп, коткы тараттың. Мәчет салдырдың. Халыкны кыстый-кыстый дингә өйрәттең. Ә үзең кызыңны марҗа итәргә җыенасың? Бу ни хәл бу?— дип бәйләнде.— Алып кайтмасаң, барыбер берәр җомгада тавыш куптарам, кешеләрне кузгатам,— дип үзегенә үтеп бетте.

Әминәгә тагын да шул бавырын бала басмаган үги әнисе янына кайтырга туры килде.

Менә хәзер инде Хизбулла шушы Әминәне, үзенең Нисасын, төшләренә кереп уята торган Нисаны калдырып, Урал якларына китәргә җыена. Җитмәсә әле кичә килергә дә оныткан, аздан гына китеп бармаган... Үпкәләрсең дә, сөйләшмәссең дә шул. Китәм дигәч тә, тәмам башы-күзе тонган булып чыкты Хизбулланың. Үзенә әллә нинди риваятьләрдәге исемне куша тагын. Искәндәр, имеш...

— Үпкәләмә, Ниса, үпкәләмә инде. Мин бит сине күрмичә барыбер китмим, китми идем...

— Шулаймы,—диде Ниса, өрфия шәлен уң кулы белән күтәрә төшеп. Ул үпкәләвен онытты, йөзе ачылып китте.— Шулаймы? Дөресме, Искәндәр?..

— Дөрес булмыйча ни... Мин бит беләм: син үзең дә быел Казанга, Әет остазбикә мәктәбенә китәргә җыенасың. Кичә этиең минем эти белән сөйләшеп утырганда әйтте...

Бу Ниса өчен яңалык иде бугай, ул тагын бер кат баягыча:

— Шулаймы?..— дип сузды.

Ләкин аларга әллә ни озак, электәгечә сөйләшеп торырга туры килмәде, ишектә Хәсәнҗан абзыйның яшь хатыны, яшь остазбикә Вазифа күренде.

— Нәрсә анда чекерәешеп торасыз? Эшең беткәнме синең, оятсыз, җир бит! Шул малай актыгына карыйсың да торасың. Менә атаңа әйтеп кирәгеңне бирдерермен әле! — дип, бөтен сүзнең тәмен җибәрде. Нишләп тә булмый инде, болай булгач, китәргә туры килә.

— Сау бул, Ниса,— дип пышылдады Хизбулла.— Мин иртәгә иртүк китәм инде. Казанга баргач та, мин сиңа хат язармын, яме. — Аннары акрын гына өстәп куйды: — Мин сине, Ниса, онытмам... Гел сагынырмын яме?

— Мин дә...— диде Әминә-Ниса, иреннәрен кыймылдатып. Аның иреннәре үзләреннән-үзләре сизелер-сизелмәс калтырый иде...

Хизбулла теләр-теләмәс кенә борылды да, артына карарга да куркып, әллә ничек җилкәләрен җыера төшеп, өйләренә таба атлады.

Инде ничәмә-ничә ел буена ул авылыннан китәргә, яңа җирләр күрергә, зур мәдрәсәдә укырга — белем алырга, Уфага барып, «Галия»гә керергә ашкынды. Түземсезләнеп көтте. Әмма гел сәбәп чыгып кына торды. Инде хәзер менә бөтен сәбәпләр дә бетте кебек, барлык каршылыклар да җиңелде.

Иртәгә Хизбулла дигән какча гәүдәле, озынча битле, моңлы карашлы, җырулар-шигырьләр яратучы хыялый малай иртүк юлга кузгалган булыр. Ул инде көтү белән бергә, бәлки аңардан алдарак та әле урманның гать юлыннан Чистай дигән шәһәр ягына, аның пристанена таба бара торган булыр. Ул инде, таң атар-атмас борын, йокысыннан торыр, ызбадан чыгар, болдырдан төшәр һәм ишегалдындагы таныш ташларны, ком сибелгән сукмакны узар, җил капканың келәсен кулы белән күтәреп ачар да яшеллеккә күмелгән урам чирәмнәренә соңгы тапкыр карар һәм аны алырга кайткан Сәгыйть әзисе янына, арбадагы күксегән печән өстенә сикереп менеп утырыр. Аннары соңгы көннәрдә кешеләрдән яшереп елый-елый күзләрен кызартып бетергән әнисен сикереп төшеп тагын бер, иң соңгы тапкыр кочаклар, аның җылы, һәрвакыт көч һәм ышаныч өстәп торучы күкрәгенә сыеныр. Аннары бу араларда әллә ничегрәк пошаманга төшеп, сөйләшер-сөйләшмәс булып, нәрсәгәдер ачуланып йөрүче әтисен дә кочаклап алыр. Аның ышанычлы кулларына барып тотыныр, көчле күкрәгенә елышыр, кочаклаган саен кытыклап йөдәтә торган ак сакалының бөртекләреннән иң соңгы тапкыр рәхәт кытыклану алыр һәм:

— Сау бул, әтием, кайгырма. Яңа җиргә барып йорт-җирне җиткерү белән, без сезне кайтып алырбыз, яме,— дияр.

Бәлки, шулвакыт җан дусты Минзаһир уянып чыкса, ә ул һичшиксез чыкмыйча калмас, Хизбулла аны да арбадан төшеп кочаклап алыр, аның күлмәге астыннан кабарып-тәртеп торган калак сөякләреннән кагар, арык тәненә килеп сыеныр. «Син дә, Минзаһир, безнең янга кил»,— дияр...

Баде-саба җиле исәр...

Иртәнге салкынча һавада, бәлки, берничә чыпчык чыркылдашып алыр, кыек башына кунган күгәрченнәр гөрләшеп

куяр, бәлки, алар кызгылт күзләрен мөлдерәтеп тыныч кына карап торырлар да кыек башыннан капка төбендәге тупылларның мәһабәт ботакларына күчәрләр, Хизбулланың үзләреннән китүен, бөтенләйгә китүен шулай аңламыйча калырлар.

Аннары ат кузгалып китәр. Алар урам буйлап авыл читенә чыгарлар һәм... Хизбулла соңгы тапкыр, юк әле, авылга түгел, үзләренең урамының буеннан-буена күз ташлар да алдагы урманга, аның серле яшеллегенә таба китәр. Аннары инде урман авызына керер алдыннан гына иң соңгы тапкыр борылып карар ул үзләренең Кармәт башына, кулларын болгап алыр да:

— Сау бул! — дияр һәм, мөгаен, аерылып китүнең чын асылын шунда гына төшенер... елап ук җибәрер...

Авылның салам һәм кабык түбәле йортлары, яңа салынган мәчетләрнең манара башындагы әллә кайлардан балкып күренеп торган ялтыравык ярымае, күк йөзендәге сердәшсерле Ай, иске алачык, Салкын чишмә, Әрәмә елгасы, чуваш ягындагы дус-ишләр, сау булыгыз, дияр Хизбулла.

Печән чапкан ләкләкле болыннарым, Баткак елгасы буе, Ази урманы, аның эчендәге Тирән елга, Торна күле урманы, Акташ урманы, Аю аланы урманы, Акташ аланы, Акбалчык елгасы, Үгез елгасы, Каенсар, Күрләк аланы, Какы аланы, Атау елгасы кыры, Төбәк, Алмантай, су буендагы бай тирәкләр һәм тагын, тагын бик күп урыннар — һәммәсе дә сау булыгыз.

Сау бул, тыйнак, ләкин әледән-әле, җае чыккан саен шаяртып алырга яратучы, илгәзәк күңелле, көләч йөзле, әллә нинди әйтелмәгән серләр тулы коңгырт-кара күзле Әминә... Ниса... Сылукай...

Сау булыгыз, күгелҗем күк йөзендәге иксез-чиксез биеклекләрдә йөзеп йөрүче йолдызлар, ак болытлар, болытларга кунып сайраучы тургайлар, сау булыгыз...

Авылның бөтен урамнары, урам буйлап койрыкларын болгап йөгерүче көчек малайлары, Актырнаклар, Озын колаклар, кәҗә бәтиләре, тупыл башындагы чыпчыклар, чәукәләр һәм күгәрченнәр — сау булыгыз...

Авылдаш малайлар, Атнагул Зарифы, хәтта үзәкләргә үтеп беткән, әмма дегет лагуны булудан туктамаган Козгын Әзгаренең Шәйдугы, син дә — һәммәгез дә сау булыгыз. Апаларәбиләр, абзыйлар-бабайлар, Хәсәнҗан абзый, Фәйруша абзый, Тырым Дәүләтша абзый, Хәсәнша бабай төбенекеләр, күптән

түгел генә жандарлыгыннан чыккан Беркүз Ярмалай абзый, ишетәсезме — сау булыгыз...

Сау бул, Туган авыл!

Сау бул, михнәтләргә бирешмәгән Кармәт башы!..

Куе кара урманнар кочагына сыенып аккан Кармәт елгасы үзәнендәге сагышларга мул, кайгы-хәсрәтләргә бай яшәгән, җәбер-золымнардан, көчләү-мәсхәрәләүләрдән исән-имин чыккан Туган җир — хуш-сау бул.

Зәңгәр хыяллар аръягындагы киңлекләргә, кеше күңелен сыйдыра торган иркенлекләргә, шау-шулы тормышка, иҗат багбостанына кертеп, көрәшләргә, җиңелү-җиңүләргә, олы фаҗигаләргә юлыктырып, багана умартасының балын эчертеп һәм дә килер дан-хөрмәт-ихтирамнарны баеклап алып китә Хизбулла атлы малайны Тәкъдир дигән кодрәт иясе.

Хәерле юл сиңа, Хизбулла!..

Хәерле юл...

Сораулар һәм биремнәр.

1. Хизбуллага ни өчен «Гөлзизин» дигән фамилия бирәләр? Үз сүзләрегез белән аңлатыгыз.
2. Ә яшь герой үзе нигә «Кармәти» дигән фамилия алырга тели?
3. Хизбулланың авылдан читкә китәргә теләвенең сәбәпләрен аңлатып бирегез.
4. Читкә киткәндә Хизбулла күңеленнән кемнәр һәм нәрсәләр белән саубуллаша?
5. «Туган җир» төшенчәсе яшь герой тарафыннан ничек аңлатыла? Бу төшенчәне сез ничек аңлыйсыз? Шул хакта әңгәмә корыгыз.

Зифа Басыйрова
(1910—1979)

Зифа Җәмил кызы Басыйровага җырчы булу өчен махсус музыкаль белем алырга, консерваторияләрдә укырга туры килмәгән. Ул атаклы җырчылар сафына нәселдән килгән табигый музыкаль сәләте, моңлы күңеле, тавышының ягымлы лирик тембры ярдәмендә килеп кергән. Табигать Зифа Басыйровага җанны сафландыра торган ягымлы, матур тавыш бүләк иткән.

Һәр җырчының үз моңы, үз тавышы, үз аһәңе булган кебек, Зифа Басыйрованың да үзенә генә хас үзенчәлекләре бар. Бигрәк тә ул «Рамай» җырын гаҗәеп зур осталык белән башкара. Бу җыр сугыштан соңгы елларда иң популяр җырларның берсе була. «Рамай» җырын күпләр башкара, әмма халыкның күңел түрендә фәкать Зифа Басыйрова җырлаган «Рамай» гына саклана. Чөнки бу җырның җаннарга үтеп керә торган ниндидер романтик серле рухын бүтән беркемнең дә аның кебек тылсымлы моң белән бизәп бирә алганы юк.

Зифа Басыйрова,— замандашлары кебек үк, үлем-җитем белән тулган сугыш елларының ачысын татыган кеше. Яшьли ятим калган Мөслим ягы кызына бик күп кыенлыклар кичерергә, авыр тормыш мәктәбе узарга туры килгән. Ирен, беренче балалары тугач ук, халык дошманы дигән яман исем тагып кулга алалар, һәм Зифа яшь баласы белән ялгызы кала. Бу газаплар бәлки коточкыч фаҗига белән тәмамланган булыр иде, тик аның юлында яхшы күңелле, олы җанлы, мәрхәмәтле кешеләр — күршеләре очрап ярдәм кулы сузалар.

Зифа Басыйрова Ватан сугышы һәм аннан соңгы елларда татар халкының иң яраткан җырчысы булды.

Аны тыңлаганда һәр көйне үз зәвыгына туры китереп, җаны аша уздырып башкаруына игътибар итәсең. Салих

Сәйдәшев музыкасына язылган «Хуш, авылым!» («Күзләр» пьесасыннан Рәйсә җыры), татар халык җырлары («Мөслим», «Су буйлап» һ. б.) — әнә шундыйлар. Ул җырлый башласа, дөнья мәшәкатьләрен бөтенләй онытып, музыка дөньясына чумасың.

Зифа Басыйрованың исеме дөньяның татарлар яшәгән барлык почмакларында билгеле. Кайда гына чыгыш ясаса да, ул тыңлаучыны үзенә әсир итте, чөнки аның иҗаты халыкчан иде.

Җыр сәнгатенә зур өлеш керткән Татарстанның атказанган артисткасы Зифа Басыйрованың исеме халкыбыз күңелендә мәңге сакланыр.

Биремнәр.

1. Зифа Басыйрова башкаруында җырлар тыңлагыз һәм иҗаты турында фикер алышыгыз.
2. Зифа Басыйрова башкарган җырларны туплап, әдәбият дәфтәрегезгә языгыз.

Роза Хафизова

1929 елда туган

Балалар язучысы Роза Сәет кызы Хафизова 1929 елның 6 февралендә Бөгелмә шәһәрендә хезмәткәр гаиләсендә туа. Хәзерге Лениногорск районы Сарабиккол авылындагы җидееллык һәм Иске Шөгер урта мәктәпләрен тәмамлагач, 1947 елда ул Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегенә укырга керә. Университетны тәмамлаганнан соң, 1951—1952 елларда Төмән өлкәсенең Тобол шәһәрендәге урта мәктәптә татар балаларына туган тел һәм әдәбият укыта. Озакламый Казанга кайта һәм үзенең хезмәт юлын журналистика белән бәйли. 1952—1960 елларда «Яшь сталинчы» (хәзерге «Татарстан яшьләре»), Чистайдагы «Сталин байрагы» һәм башка күп тиражлы газета редакцияләрендә, Татарстан китап нәшриятында эшли. 1962—1988 елларда «Ялкын» журналының баш мөхәррире вазифасын башкара.

Үзенең хезмәт юлын нигездә балалар матбугатына багышлавы Р. Хафизованың иҗат эшчәнлегенә дә эз сала. «Ялкын» журналы редакциясендә эшли башлаган елларыннан иҗат эшенә алынып, ул әсәрләрен тулысынча яшь укучыга багышлый. «Кыңгыраулар җыры» (1967), «Әкиятләр» (1979), «Кашкарыйлар озын гомерле» (1984), «Сак-Сок тавышы» (1987), «Актәпи ник моңая?» (1991) кебек җыентыкларына тупланган хикәяләрендә, әкиятләрендә һәм повестьларында автор яшь буынны тәрбияләүгә караган мөһим мәсьәләләрне үзенең бай тормыш тәҗрибәсенә һәм иҗат фантазиясенә нигезләнеп яктырта, яшүсмерләргә үрнәк булырлык образлар тудыра. Р. Хафизованың әсәрләре рус, казакъ, үзбәк, украин телләренә дә тәрҗемә ителгән.

КАШКАРЫЙЛАР ОЗЫН ГОМЕРЛЕ

(Өзек)

ТИЛЕ БОЯР ХӘЗИНӘСЕ

Хәйләкәр соң безнең Шушма елгасы. Тау астыннан нәни генә чишмә булып башлана да уңай җирдән үзенә юл сабып ага бирә. Үзе, челтер-челтер көйләп, бертуктаусыз нидер сөйли. Чишмәнең сүзләре хикмәтле, күрәсең, кошлар яр буенда үскән куакларга куналар да тын калалар. Башларын кырын салып, беравык тыңлап туйгач, дәррәү күтәрелеп очалар. Ә елга ага бирә. Тирә-юньдәге ваграк чишмәләр, аның яңгыравык серләрен белергә омтылып якын ук киләләр дә, утка төшкән күбәләкләр кебек, үзләре дә сизмәстән, аңа кушылып китәләр. Еракарак киткән саен, Шушманың суы арта, ярлары киңәя бара. Ул инде башланган җирендәгечә чатыр чапмый, салмакланa, тоныклана. Аның ярларына куе булып зифа таллар тезелә. Алар, кайчан карасаң, башларын түбән иеп, дулкыннар белән серләшәләр, ә шәүләләре суда чагыла. Гаҗәп, әй!

Шушманың сул ягында өсләре урман белән капланган тау тезмәләре сузылган. Картлар аларны Урал тауларының дәвамы диләр. Шулайдыр, бәлки. Ә безнең өчен ул таулар — балачак зәңгәр хыялларының көмеш ыңгырчагы. Ярты гомеребез шунда уза. Шушма гомерлек юлдашы булган тауларга әле якынлаша, әле, кылтаеп, ерак ук китә. Үз чибәрлеген белгән яшь кыз кебек, назлы боргалана-боргалана ага ул. Шушманың нәкъ шулай көйсезләнеп боргаланган урынында култык-култык ярымутраулар хасил булган. Безнең бәләкәй «Артек», район пионер лагере, нәкъ шундый утрауларның берсенә, тау итәгенә урнашып, тәпиләрен Шушма ярына сузган. Элек бу урында ниндидер «Көл бояры»ның утары булган, ди. Хикмәтле бояр булган ул, үзен Тиле бояр дип тә йөрткәннәр. Кызык.

Лагерь безнең авылдан җиде чакрым ераклыкта. Смена саен анда һәр авылдан ике-өч пионер ял итә. Бу юлы без өчәү, ике малай, бер кыз барабыз. Салих, Закуан һәм мин. Өчебез дә күршеләр. Закуан безгә кардәш тә тиешле. Салихның инде бу лагерьга икенче тапкыр баруы. Шуңа күрә Тиле бояр тарихын бик яхшы белә ул.

...Тиле бояр бу җирләргә Октябрь революциясе алдыннан гына каяндыр ерактан килеп урнашкан. Килүгә, тирә-юнь

авыллардан йөкләп-йөкләп көл җыярга тотынган. Бушка түгел, һәр олавына акча түләгән (Салих аның күпме түләгәнен генә хәтереннән чыгарган). Боярның кием-салымы да мондагыча түгел, бик хикмәтле булган. Чалбар балаклары тездән генә, башында карга оясы кебек эшләпә, кулында һәрвакыт кыска каеш чыбыркы йөрткән. Боярның сөйләшүе дә, үз-үзен тотышы да авыл халкына сәер тоелган. Ул иртүк торып чыга икән дә тиктомалга җан-фәрманга чабарга тотына икән. Аннары, чапкан шәпкә киемнәрен салып ташлап, суга чума икән. Халык карап-карап торган да аңа Тиле бояр дигән кушамат таккан.

Ни кормак булгандыр Тиле бояр Шушма буйларында — анысы мәгълүм түгел. Тик аны Октябрь революциясе дулкыны куркыткан. Шартлау тавышлары безнең якларга килеп ишетелүгә, Тиле бояр койрыгын сыртка салган. Җыйган көлен, корган корылмаларын, йорт-җирен ташлап, каядыр китеп югалган. Соңыннан күрше Ишмәк авыл Советы, аның төзелеп бетмәгән йортын үзенә күчереп, клуб ясаткан. Җыйган көлен яңгыр юган, җил куган. Тора-бара көлнең эзе дә калмаган. Урман буендагы ике озынча корылмасының гына гомере озын икән. Безнең пионер лагере нәкъ шунда урнашкан да инде.

Безнең лагерь җирендә Тиле боярның түгәрәк алан ясап утырткан сәрби агачлары үсә. Күрәсең, ул анда бакча ясап хозур кылмак булгандыр. Хәер, хикмәт анда түгел, хикмәт бөтенләй икенче нәрсәдә...

Лагерьга килгәннең икенче көнне, төшке аштан соң, Салих Закуан белән икебезне шыпырт кына чакырып чыгарды. Без, ниндидер сер барын сизенеп, палаталар артлатып урманга тайдык. Быргы безнең арттан: «Йокы сәгате җитә, йокларга әзерләнегез, йокларга!» — дип кычкырта калды.

Их, яратам шул сер дигән нәрсәне. Сернең исен сизсәм дә сулышым каба! Ә бу юлы нинди генә сер диген әле! Урманга эчкәре үк кергәч, Салих як-ягына каранды да: «Бу серне беркемгә дә әйтмәм»,— дип, Закуан белән мине җир ашатып ант иттерде. Аннары пышылдап кына серне чиште.

— Көл боярының алтын-көмеше бик күп булган, ди. Койрыгына безнекеләр баса башлагач, ул аларны хәзинә ясап каядыр шушы тирәгә күмгән дә үзе элдерткән, ди. Ничәмәничә еллар шул хәзинәне эзлиләр, ди. Әмма таба алган кеше юк. Ул алтыннарга хәзер убыр ияләшкән, ди. Аның шушы урман өстеннән очып йөргәнен күргән кешеләр күп икән.

Салих сөйләгәндә, Закуан белән минем сулышлар кысылды. Менә бу сер, ичмасам. Мин сагаеп тирә-якка күз салып алдым. Үзем утырган агач төбен малайларга сиздерми генә капшап карадым. Кем белә, бәлки без шул хәзинә өстенә басып йөрибездер. Агачлар, минем уйларны раслаган кебек, әкрен генә шаулашып утыра бирәләр. Биек-биек төз наратлар. Бу урман бигрәк куе, серле. Кояш нурлары да тиз генә үтеп керә алмый аңа. Хәзинә турында ишеткәч, урман миңа бигрәк тә серле булып тоелды. Арысланнар, юлбарысларның безнең якта яшәмәвен белсәм дә, әллә нинди җанварлар килеп чыгар кебек тоелды. Әзрәк шикләнгәндәй иттем. Тик сиздерәсем килмәде. Кызларның шулай булыр инде ул дип уйлауларыннан курыктым.

Закуан да үрә каткан иде. Хәзинә турында ишетү аның зиһенен чуалткан, күрәсең. Шундый ул Закуан, аңа аз гына оеткы салу да җитә, хәзер хыял уты кабына да китә.

— Чынмы? Дөресме? — диде ул пышылдап кына Салихка.

Салих аңа «Әллә ышанмыйсыңмы?» дигәндәй шелтәле караш ташлады да чертләтеп төкереп куйды.

— Их-ма! — диде Закуан. — Их, тапсак!

Мин, күзләрем талганчы, тирә-юньдәге түмгәкләрне күзәттем. Шушы бер түмгәктә хәзинә ятса, әй! Ничек табарга икән?

— Шул шул менә! — диде Салих.— Әллә тикмәгә генә икенче ел рәттән мин бу лагерьга киләммe? Ирекле көннән монда килеп, сәгатьләп яшәр идемме соң?!

Бу сүзләрне әйткәндә Салихның коңгырт күзләре кысыла төште, тавышы да моңсу булып ишетелде. Бәлки, миңа гына шулай тоелгандыр. Кем белә. Хәер, шунысы дөрес инде: җәен безнең Сарайлы авылында җан рәхәте. Шушмасы дисеңме, урманы, болыны дисеңме — җаның ни тели. Авыл үзе дә таллар бакчасы эчендә утыра. Адым саен ябалдаш ботаклы юан-юан таллар да сәрби куаклары. Тал башларында меңләгән карга оясы. Шуңа күрә безнең авылда иртә яздан кара көзгә хәтле «кар да кар» карга тавышы тынып тормый. Авылга исемне, минемчә, ялгыш кушканнар. «Сарайлы» түгел, «Каргалы» кушарга кирәк иде аңа. Сараен күргәнебез юк, каргасы көне-төне күз алдында.

Менә шундый авылны калдырып җәен монда, Тиле бояр сараена килеп ят әле. Ни күңелле булса да, үз иркең түгел инде. Быргы белән ятасы, быргы белән торасы. Ә Салих безнең гел үз иркендә йөрергә ярата. Кызык кына малай ул. Закуан

белән миннән бер класска зуррак укый, быел алтынчыга күчте. Әтисе белән бертуган апаларында тора. Элек алар Чиләбедә яшәгәннәр. Аннары әтисе белән әнисенә нидер булган. Әтисе Салихны әллә кайчан, без бәләкәй чакта ук, апаларына кайтарып киткән. Аның әтисен өлкәннәр яхшы беләләр. Ул безнең авылда совет власте урнаштырып йөргән. Хәзер Салихның әтисе турында никтер беркем берни сөйләми. Әйтерсең ул бөтенләй булмаган да. Салих үзе дә әти-әнисен никтер телгә алмый.

Салихның апасы Фатыйма исемле. Кап-кара чәчле, каратут йөзле, кыска аяклы бер апа, кайчан карасаң да ыңгыр-шыңгыр йөри, гел чирли. Аның Салихтан зур ике кызы бар. Сәлимәсе сигезенчегә, Әхсәнәсе унынчыга күчте. Кыланчык үзләре — чебен тимәс чер итәргә генә торалар. Узган яз Мөгәҗи тавында шапталка уйнаганда безне уенга катнаштырмаганнары өчен, Әхсәнәнең күлмәге эченә бака салган идек. Бөтен авылны җыйды. Ярый әле мин салганны белмәделәр, юкса күрәселәр бар иде. Минем Якуб абыем шул Әхсәнә белән Сәлимә өчен үлә дә китә. Күрше кызлары, имеш. Мин аның бердәнбер сеңлесе булсам да исе дә китми. Бу юлы да мин икәнне белгән булса, мөгаен, Әхсәнәне яклар иде. Бөтен кеше алдында оятлы ясап тукмавы да бар. Анысы инде бурычлы булып калмас идем калуын. Үчне абыемнан түгел, Әхсәнәсе белән Сәлимәсеннән алыр идем. Тик менә бу абый дигән кешеләр нигә гел зур кызлар янында чуалалар икән соң? Сеңлесе булсам да, Якуб абыемның миңа исе дә китми. Маңгаема берне чиртә дә эше бетте. Җитмәсә тагы «Зил-лә» дип үртәгән була. Тулы исемемнең Тәнзилә икәнен белми диярсең. Мине бит болай гына Зилә дип йөртәләр. Русларның Татьянаны Таня дип йөрткәннәре кебек. Миңа ни, теләсә ничек атасалар да барыбер, мыскал да үртәлмим. Абыемның гына шул Әхсәнәләрне яклавына ачуым килә.

Салихның җизнәсен авылда Төче коймак Шәйхетдин дип йөртәләр. Аның бите бәләкәй генә, түм-түгәрәк, чынлап та нәкъ төче коймак. Аны күргәч, минем гел көләсе генә килеп тора. Өлкәннәрдән көләргә генә ярамый. Юкса белер идем мин. Әхсәнә белән Сәлимәнең дә битләре нәкъ төче коймак инде, түм-түгәрәк. Закуанның да Төче коймак дигәннән гел көләсе килә. Законный малай ул Закуан! Бишенчегә җиттек инде, әле юри дә бер бозылышып караганыбыз юк. Анысы инде, гомер-гомергә күршеләр булып яшәгәч, төрле чаклар

булгандыр. Кечкенәрәк чакта сугышып та алгалаганбыздыр. Узган эшкә салават. Әмма хәзерге вакытта дус ул минем. Сер сыя аңа. Үзе тагы нәрсә кушсаң, шуны тыңлый, әрепләшеп тормый. Минем белән түгел, малайлар белән дә сугышырга яратмый. Ну башы шәп эшли аның. Арифметикадан мәсьәләләрне «эһ» дигәнче чишеп ташлый. Шулай булмый ни? Әнисе укытучы бит аның, башлангычларны укыта. Әтисе сельпода бухгалтер булып эшли. Әнисе безне укытмады укытуын. Без беренчедә чакта дүртенчеләрне укытты. Шулай булса ни, әллә бердәнбер малаена ярдәм итмәгәндер дисезме! Закуанның беркайчан дәрескә өйгә бирелгән эшен эшләмичә килгәне юк аның. Аннан үрнәк алырга дип, үз-үземә әллә ничә сүз бирдем. Булмагач булмый инде. Я дәфтәремне игезәк энеләрем Закир белән Шакир ертып куя. Я бозау чәйни шунда. Энекәшләрем бәләкәй шул әле минем. Яңа биш тулды үзләренә. Утырып еласаң да, берни аңламыйлар. Анысы тик торганда елаган юк инде минем. Елау дигәнне гомумән яратмыйм. Иң яхшысы — үзем елатам. Шуңа күрәдер инде, әбием кайчакта: «Кыз балага охшар идең, ичмасам, кызлар синең кебек чатыр чапмый, кыяфәтеңә кара, кыз бала чалбар кияме соң?»— дип үгетләп карый. Әбиемнең сүзен ишеткәч, әтием елмая гына. «Ярый-ярый,— ди ул, минем баштан сыйпап,— үзен обидага бирмәсен. Дөнья хәлен белеп булмый. Нык булып үссен. Өч малай арасында аның монысы да малай булып үсә инде»,— ди. Миңа ни, өйдә идән юарга, савыт-саба юарга гына кушмасыннар. Җенем сөйми шул эшләрне. Кызлар эше, имеш. Кыз булып туганга мин гаепleme әллә? Бәләкәй чактан ук малай буласым килә бит минем. Ярый әле малайлар читкә типмиләр. Хәер, миннән башка аларның үзләренә дә кызык түгел. Ни әйтсәң дә, кызык табарга Закуан белән минем баш шәбрәк эшли. Узган яз әнә Мөгәҗи тавы өчен Куак очы малайлары белән ярты җәй сугыштык. Сугышны кем башлады дисең, шул Закуан белән мин.

Безнең авылда иң элек Мөгәҗи тавы кардан әрчелә. Шуңа күрә язга сусаган бөтен бала-чага, яшь-җилкенчәк уенга шунда чыгалар. Шулай беркөнне Закуан белән без тауга иртәрәк мендек. Анда Куак очы малайлары гына иде. Бәйләнә бит болар. Имеш, тау безнеке, теге-бу! Яңавыл очы малайлары, ягъни без, үз очларында уйнасыннар, лә... лә-лә имеш! Шуннан ачу килде дә, Закуан белән икәү тауны кыл урталай бүләргә тәкъдим иттек. Таш алып тауның кыл уртасыннан сызык та

сыза башладык. Куак очының атаманы Зәкәрия безне җилтерәтеп ыргытты. Тау аларныкы гына, имеш! Ярый әле бәхеткә безнең оч малайлары килеп җитте. Шунда инде Салих Зәкәрия белән канга батканчы сугышты. Җиңде барыбер. Зәкәрия ачуыннан Салихка: «Килмешәк, син безнең авыл малае түгел!» — дип, шыңшый-шыңшый кизәнде. Ну соң иде инде. Безнең малайлар Куак очларына тын алырга да бирмәделәр. Үкчәләре генә ялтырады тегеләрнең. Шуннан башланып китте сугыш, китте сугыш. Туйганчы сугыштык. Укытучылар катнашып эшне бозмасалар, сугышның ни белән бетәсе мәгълүм түгел иде әле. Закуан белән без бакча башындагы үзебезнең уртак чокырны корал склады ясап, аңа тутырук итеп таш җыйган идек. Мөгәҗидәге таш кына җитми сугышка. Бөтен авылны бетереп җыярга кирәк ташны. Сугыш кабынмагач, ташларыбыз да кирәксез булып калды. Анысы, киләчәктә сугыш кызмый булмас әле, җыйган ташлар әрәм калмас. Лагерьга киткәндә «корал складын» чыбык-чабык белән капладык. Безнең бакча башына керергә чит малайларның йөрәге җитмәс җитүен, шулай да саграк булуың яхшы.

Тиле боярның хәзинәсе турында сөйләшкәндә ихтыярсыздан минем күз алдына әлеге шул таш чокыры килде. Тиле бояр да алтыннарын чокырга, без таш тутырган кебек, дыңгычлап тутыргандыр, мөгаен. Тик ул чокырын караңгы төндә казыгандыр.

— Я, нишлибез, хәзинәне эзләү группасына член булып керәсезме? — диде Салих һәм безгә төбәп карады.

— Керәбез, керәбез,— дидек без, дулкынланып.

Аннары Салих як-ягына каранды да кесәсеннән өч тиен акча зурлыгындагы ике калай чыгарды.

— Группаның исеме «Чакку» булыр. Хәтерегездә тотыгыз. Бу калайлар, шул группада членлык билгесе. Пароль — «Чакку».— Салихның тавышы бик горур яңгырый иде. Минем хәтта тәнем чемердәп китте.— Мин командирыгыз. Минем сүздән чыкмаска!

Без хәзинәне төннәрен эзләргә булдык. Бөтенесе йоклап беткәч, шыпырт кына чыгабыз да сызабыз дип сөйләштек. Көндез бөтен җиргә күз-колак булып йөрибез. Шикләнерлек урыннар булса, төнлә килеп актарып ташлыйбыз. Салих өеннән бәләкәй көрәкләргә хәтле ясап алып килгән. Ничек бу хәтле зур серне моңа хәтле беркемгә әйтмичә түзгән диген син. Мин булсам, минут та түзмәс идем. Берүзең генә белгән сер кызык буламыни ул?!

— Ну, «Чакку»! — диде Салих, — таралыштык. Мин операциянең планын төзим. Тәмам эшкәртеп бетергәч, сезгә җиткерермен...

Шулчак якында гына ниндидер аяк тавышлары ишетелде. Без утырган килеш җиргә сеңдек. Агачлар арасыннан военрук Талип абыйның яшел гимнастеркасы күренеп китте. «Чакку!» — дип пышылдады Салих. Без хәтта тын алудан туктадык. Военрук абый узып китүгә сикереп тордык та, җилдәй очып, лагерьга йөгердек.

* * *

Лагерьда көн быргы авазы белән башлана, быргы авазы белән тәмамлана. Бөтен нәрсә кызык, хикмәтле монда. Тик менә шул иртән торып зарядка ясыйсы да көндез йоклыйсы булмаса икән! Ул чагында лагерь түгел, оҗмах инде менә. Линейкага тезелеп, вожатыйга рапорт бирүләре, байрак күтәрүләре ни тора. Лагерь байрагын күтәрү хокукы иң актив, иң яхшы пионерга бирелә. Безгә чират җиткәне юк әле. Чөнки иң актив, иң яхшы булырга безнең җай юк. Истә гел шул Көл бояры хәзинәсе. Вожатый безгә бер нәрсә сөйли, ә без икенче нәрсә турында уйлыйбыз. Шул хәзинәне тапсак шаккатарлар иде, әй! Закуан әйтә, андый чакта газеталарга да язалар, ди. «Яшь ленинчы»га үзебез үк язып җибәрер идек әле.

Күзләребез ут уйный. Һәр түмгәкне, чокыр-чакырны күзәтәбез, киңәшләшәбез, хәтта линейкага тезелгәч тә бер-беребезгә әйтәсе сүзләребез була. Шунлыктан вожатыйлар безгә гел кисәтү ясап кына торалар. Анысы инде яхшы булыйк дисәк булабыз без. Әле бер генә түгел, әллә ничә күтәрербез байракны.

Ниһаять, көтә-көтә арып беткәч, беркөнне ашханәгә барганда Салих минем колакка: «Чакку!» — дип пышылдады. Тәнем буйлап ток уздымыни, дерт итеп киттем. Шатлыгымнан әз генә кычкырып җибәрмәдем. Шундук Закуанны куып җитеп, аңа да: «Чакку!» — дидем. Ул да дерт итеп куйды.

Ашыбыз аш булмады. Гомумән, мин бәләкәй чактан ук ашарга вакытны кызганам. Иптәшләрең дөнья бетереп уйныйлар, котыралар. Син авыз тутырып ашап утыр, имеш. Бу юлы менә безне таудай зур хәзинә көтә. Шундый чакта тамакка ничек аш барсын инде?! Җитмәсә тагы аштан соң вожатыебыз

Тәслимә апа туктатып, костер турында сөйләшеп тора. Имеш, концертка репетиция ясарга кирәк. Тәнзилә, сине шигырь сөйләргә оста диләр, теге-бу, имеш. Концерт кайгысымы соң безнең газиз башкайларда!

Көчкә котылдык вожатыйдан. Атылып-бәрелеп очрашу урынына чаптык. Һәм Салих янында Әхъяр белән Сәгыйтьне күреп туктап калдык. Салих безгә кул изәде: «Чакку! Чакку!» — диде. Димәк, серне боларга да тишкән. Әй, бу Салих дигәнең! Нигә инде әллә ниткән чит авыл малайлары белән бәйләнергә! Эзләү юк, сорау юк. Белмәгән — нитмәгән малайлар.

Салих, безнең сөмсерләр коелуын шундук сизсә дә, сизмәмешкә салынды. Яңа малайлар бер миңа, бер Салихка карадылар. Кызларның монда ник кирәкләре бар, имеш. Салих аларның карашына да игътибар итмәде.

— Я, булды, таныштыгызмы? — диде ул кырыс тавыш белән.— Эшкә керешәбез. Кемнең нинди әйтер сүзе бар? Эзләүне кайдан башлыйбыз?

Малайлар беравык эндәшми тордылар. Аннары, кулы белән такыр башын угалап, Әхъяр әйтеп куйды:

— Соң монда төптән уйлыйк. Әлеге сезнең Тиле бояр урынында булсак, хәзинәне без кая куяр идек икән?

Кара, акыллы сүз әйтте түгелме соң әле бу Әхъяр дигәнең? Башы чәчсез, бите сипкелле, буе тәбәнәк булса да, бу малайның тегермәне тарта, ахры.

— Кайда дип инде, аяк астына күммәгәндер, урман эченәрәк кергәндер...

— Шул шул. Урман эченнән эзләргә кирәк.

— Тик ничек? Көпә-көндез урманда казына да алмыйсың, аннары көндез вакыт та юк. Төннәрен караңгы. — Монысын Салих әйтте.

— Соң үзең әйтәсең бит, хәзинә өстендә убыр очып йөри икән, дисең. Без башта шул убырның кай төштәнрәк күтәрелүен сагалыйк, аннары шул турыдан казырбыз...

— Ну, малай, Закуан, баш бар да соң синдә...

— Чынлап менә, бер чыкмаса, бер чыгар ул убыр дигәнең...

— Чыгуын чыгар да бит...

— Бәреп егар димәкче буласыңмы?

— Һи, бүредән курыксаң, урманга бармыйлар аны...

Малайлар шулай кызып-кызып бәхәсләштеләр. Мин катышмый тыңлап кына тордым: яратмыйм бушка сүз көрәш-

тергәнне. Беренчедән, мин убырга ышанмыйм, икенчедән, убыр, чынлап та булып, хәзинә өстенә иялəшкән икән, анда барырга йөрәк җитми минем. Төптән уйлап карасаң, чынлап та башка юл юк инде анысы. Бу хәтле зур урманны ничек казып чыкмак кирәк.

Шундый карарга килдек: берничә төн рәттән урман өстен күзәтергә, шикләнерлек нәрсә күренсә, шундук «Чакку!» — хәбәр салырга.

Сораулар һәм биремнәр.

1. Повестьның бу бүлегенә ни өчен «Тиле бояр хәзинәсе» дигән исем биргәннәр? «Тиле бояр» кушаматының ничек туганлыгын аңлатып бирегез.
2. Туган якларындагы таулар әсәр геройлары өчен нинди мәгънәгә ия?
3. Тәнзилә ни өчен үз авылларына «Каргалы» исемен кушарга тәкъдим итә?
4. Тәнзилә нинди кыз ул? Аңа характеристика бирегез.

Ибраһим Салахов

(1911—1998)

Татарстаннан читтә яшәп иҗат иткән, катлаулы язмышка дучар булган Ибраһим Низами улы Салахов 1911 елның 30 августында хәзерге Казакъстан Республикасының Күкчәтау шәһәрендә эшче гаиләсендә туа. Туган ягында мәдрәсәдә һәм җидееллык мәктәптә белем алганнан соң, ул Казанга килә һәм 1928—1931 елларда педагогия техникумында укый. Студент елларында ук әдәби иҗат белән шөгыльләнә башлый. 1932—1935 елларда хәрби хезмәттә булганнан соң, И. Салахов, кабат Казанга кайтып, педагогия институтында белем ала һәм бер үк вакытта иҗат эшчәнлеген дә дәвам итә. Нәтиҗәдә аның «Ярату» пьесасы, «Дуэль», «Мәхәббәт һәм өмет» повестьлары, «Постта» дигән лирик шигырьләр җыентыгы дөнья күрә.

Шулай иҗат дәрте белән яшәгәндә, башка бик күпләр кебек, И. Салахов та сталинизм репрессияләре корбанына әверелә: нахакка «халык дошманы» дип игълан ителгән Галимҗан Ибраһимов белән бәйләнештә булуда гаепләнеп, 1937 елда кулга алына һәм Себергә сөрелә. Гәрчә 1940 еллар ахырында сөргеннән азат ителеп, сәламәтлеге нык какшаган хәлдә туган якларына әйләнеп кайтса да, аның «халык дошманы»на хас михнәтле тормышы, җәмгыять тарафыннан төрлечә кыерсытылып, кимсетелеп яшәве илленче еллар уртасына кадәр дәвам итә. Бары 1956 елда СССР Югары суды хәрби коллегиясе тарафыннан рәсми төстә акланганнан соң гына, аңа караш уңай якка үзгәрә башлый.

Узган гасырның алтмышынчы елларыннан илдә мәгълүм үзгәрешләр башлану нәтиҗәсендә, бөтен әдәби хәрәкәт кебек, И. Салаховның иҗат эшчәнлеге дә шактый активлашып китә. 1965 елда аның Казакъстанда чирәм җирләр үзләштерүне сурәтләгән «Күкчәтау далаларында» романы басылып чыга. Анда үзенең туган ягында яшәгән милләттәшләренең тормы-

шын һәм хезмәтен сурәтләү белән бергә, автор казакъ халкын, аның гореф-гадәтләрен тасвирлауга да киң урын бирә. Бер үк вакытта И. Салахов, Казандагы балалар матбугаты белән хезмәттәшлек итеп, балалар өчен дә хикәя-повестьлар яза.

Казакъстанда яшәгән милләттәшләренең үткәне белән тирән кызыксынган И. Салахов аларның XIX һәм XX йөзләр арасында революцион хәрәкәт шартларындагы язмышын сурәтләгән әсәр язарга алына. Байтак еллар дәвамында язылган бу күләмле әсәр, 1986 елда «Имәннәр тамыр җәйгәндә» дигән тарихи роман рәвешендә дөнья күрә. Ул, тарихи ватаннарыннан читтә яшәүче милләттәшләребезнең үткәнен чагылдырган беренче әсәрләрдән буларак, татар әдәбияты тарихында үзенә лаеклы урын алды.

Сөргеннән туган якларына әйләнеп кайткач, И. Салахов үзенең ничек «халык дошманы»на әверелдерелүе, сөргендә һәм аннан соң күргән-кичергәннәре турында әсәр яза башлый. Аны тиз арада язып бетерсә дә, кулъязманы шактый вакыт яшереп тотарга мәҗбүр була. Бары 1980 еллар ахырында, илдә сүз ирегенә юл ачылгач кына, әлеге әсәрне башта «Тайгак кичү», аннан «Колыма хикәяләре» исеме белән бастырып чыгаруга ирешә. Автобиографик характердагы бу романда, әдипнең сөргендә күргән-кичергәннәре белән беррәттән, сталинизм заманында нахакка «халык дошманы» дигән мөһер сугылып төрмәгә ябылган, сөргенгә озатылган башка күренекле татар зыялыларының да фаҗигале язмышы чагылыш таба. Шул нигездә «Колыма хикәяләре» әсәре татар һәм башка бик күп милләтләргә зур югалтулар китергән тоталитаризм системасының үзенә бер хөкем акты булып яңгырый.

И. Салихов 1990 елда «Колыма хикәяләре» романы өчен Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләгенә лаек булды.

КОЛЫМА ХИКӘЯЛӘРЕ

(Өзек)

АНА ТАВЫШЫ

Бу фаҗигале вакыйгадан соң инде кырык елга якын вакыт үтте. Әмма ул йөрәк өзгеч тавыш, чегән хатынының баласын эзләп, зарлап елавы әле хәзер дә колагымда чыңлый. Кайвакыт баласын кочаклап перронда аунаган шул чегән хатыны төшемә керә. Кара тиргә батып куркып уянам.

1938 елның июне. Уфа. Тимер юл вокзалы. Перрон. Ул шомлы кичтә безне, бер төркем «халык дошманнарын», күп газаплар күреп, ниһаять, Уфа төрмәсенә килеп эләккән тоткыннарны, тагын каядыр озатырга дип, вокзалга китерделәр. Билгеле инде, «кара козгын» читлекләрендә. Шуның өчен юлда кем белән килүебезне белмәдек. Безне перронда ниндидер, каядыр китәргә торган поезд янына китереп төшерделәр һәм шундук бер Столыпин вагоны алдында тезләндерделәр. Бу юлы төркем кечкенә, егермеләп кенә мәхбүс иде. Яңа гына яңгыр явып үткән, перрон пычрак. Җитмәсә, безне нәкъ пычракның күзенә тезләндерделәр. Чалбарлар шундук лычма су булды. Әмма аңа бер тоткын да игътибар итми. Уфаның тоткыннар белән шыгрым тулы, тынчу төрмәсеннән соң мондый саф һавада булу, иркенләп сулыш алу көтелмәгән рәхәт бит. Дөрес, вокзал-перрон һавасында төтен аралаш күмер, май исе сизелә. Әмма инде бу һаваны камеранықы белән чагыштырып булмый. Белмәгәнбез генә икән иректә вакытта: вокзалның һавасы да, тынгысыз ыгы-зыгысы да күңелгә ятышлы. Әнә ничек кайнап тора ул. Берәүләр, чемоданнарын, капчыкларын, әрҗәләрен күтәреп, водокачка ягына таба абына-сөртенә йөгерә, икенчеләре нәкъ шулай тирләп-пешеп аларга каршы чаба. Барысы да ашыга. Тик без генә — тоткыннар гына сүлпән. Әйтерсең лә теге дөнья кешеләре: пычрак суга тезләнеп, тынсыз утырабыз. Юк, бу тыштан гына шулай. Ә эчтә, менә бу пычрак суга тезләнгән ертык-керле киемле, ябык-сары, тутлы йөзле тоткыннар күңелендә — өермә. Алар үзләренең нәкъ шушы пассажирлар төсле теләсә кай якка бара алган чакларын хәтерли, туганнарын күз алдына китерә. Алай гына да түгел, күзләре белән интегеп якыннарын эзли, бәлкем... Бәлкем, менә шушы шашып йөгергән юлаучылар арасында атасы, хатыны, баласы бардыр... Бәлкем? Аһ, хәзер алар килеп чыкса...

Мин дә, тирә-ягымдагы иптәшләрем төсле үк, өзелеп вокзал ыгы-зыгысына карыйм. Көтәм. Кемне? Үзем дә белмим. Әмма ашыгып, ашкынып көтәм...

— Ә-ә, әү-әү...

Дерт итеп киттем. Якында гына бер яшь бала кычкырып елап җибәрде. Нинди нарасый? Кайда? Без инде һәрберебез елдан артык тоткында — гаиләдән аерылган. Шуның өчен бу тавыш, сабый бала тавышы, сәер дә, якын да, газаплы да.

Бала елый.

— Ә-әү... Ә-әү...

Кайда? Кем баласы? Мин башымны артка бордым. Гәүдә белән борылырга ярамый. Конвой һәр хәрәкәтне качарга әзерләнү дип исәпли һәм шундук ата. Артта, кырыйда, безнең кебек үк тезләнеп, бер чегән хатыны утыра — яланбаш, чәчләре тузгыган, яланаяк. Өстендә керле, ертылып беткән кат-кат күлмәк һәм инде төсе уңган зур шәл. Ул шәлен иңенә салып уранган. Шул шәл эчендә кечкенә сабый күзләр — шомырт күзләр елтырый. Хатын шәлен бераз бушатты да, якасын ачып җибәреп, сабыйга имчәген каптырды. Елау басылды. Сабый чүп-чүп итеп, тәмләп имә башлады. Күзләр йомылды.

Паровоз кычкыртты. Буферлар бер-берсенә сугылып чыңладылар.

— Торыгыз! — Конвой башлыгының ачулы тавышы колакны ертып китте. Ул үзе кечкенә, чандыр. Борыныннан кыссаң, җаны чыгар. Мондый ачы тавыш кай җиреннән чыгадыр? — Басыгыз! Тезелегез! Тикшерү!

Безне төрмә конвоеннан юлныкына тапшыру башланды. Төрмә конвое башлыгы — озын буйлы, тулы гәүдәле, җәенке битле, кысык күзле башкорт егете янәшәсендәге солдатка күтәреп килгән зур күн сумкасын җиргә куярга боерды. Куйдылар. Ачтылар. Аннан зур-зур папкалар чыгара башладылар. Тоткынның формулярын, гамәл дәфтәренә язылган хөкем карары һәм башка кәгазьләрен.

— Иванов, бер адымга алга чыгып бас!

Уң яктагы ак сакаллы карт профессор әмерне үтәде һәм исемен, туган елын, ничә елга, нинди статья белән хөкем ителгәнен әйтте.

Юл конвое башлыгы формулярны алып, тоткынның әйткәннәрен тикшереп, формулярдагы язмалар белән чагыштырып тора.

Без барыбыз да бу гадәти, инде ел буена бер төрмәдән икенчесенә йөри-йөри күнегеп беткән «сират күпере»ннән үтеп, Столыпин вагоны алдына бастык. Иң соңгы булып чегән хатыны калды. Бая борылып караганда абайламаганмын икән. Беренчедән, анда мин күбрәк игътибарны сабый балага биргән идем. Икенчедән, хатын бөгелеп баласын имезә иде. Менә ул хәзер торып баскан. Имәнеп киттем. Әллә инде Проспер Мерименың мәшһүр Кармены басып тора? Төз, зифа буй. Матур, килешле гәүдә. Чем-кара озын, калын толымнар тузып җилкәгә төшкән. Калын кыйгач кара кашлар. Карчыга борын.

Хәзер каты кысылган юка иреннәр һәм аз гына алга омтылган ияк. Дөрес, бит алмалары янып тормый, аксыл, суырылган. Бу инде аңлаешлы, ул да безнең кебек тынчу камерадан чыккан, туяр-туймас паекта торган, җитмәсә, бала имезә. Әгәр хәзер аны иркен таборга җибәрсәң, туйганчы ашарга бирсәң?.. Мине аеруча сокландырганы — зур шомырт кара күзләр. Алар ниндидер бер көч, ярсу белән бораулап карыйлар. Ә торышы — нәкъ таборда биергә чыгарга әзерләнгән төсле иркен, хәтта аз гына куштан да. «Карагыз, сокланыгыз, мин нинди чибәр!»

Ул бер адым алга атлады да, горур бер караш белән, башын аз гына артка чөеп, шәлгә урап күкрәгенә бәйләгән бәбиен тирбәтә-тирбәтә аз гына чайкала, борын астыннан гына ниндидер бер көй шыңшый. Күрәсең, беренче баласы — сөенеп туя алмый.

— Әй, син нәрсә, Земфира! — Юл конвое башлыгы аңа мыскыллап карап акырып җибәрде.— Нәрсә чайкаласың? Әллә камерада чәкеп алдыңмы? Сиңа аерым чакыру кирәкме, атла!— Ул төрмә конвое башлыгына борылды.— Кайда аның формуляры?

— Чегән хатынның формуляры юк. Ул әле тикшерелә генә. Озату кәгазе генә бар.

— Бир монда,— диде дә теге түрә чегән хатынына кадалды.— Ә нәрсә ул шәлгә уралган? Әллә багарга да өлгердеңме? Нәрсә ул?

— Ул — минем кошчыгым.

— Җүләр, нинди кош тагын?

— Иптәш начальник,— диде башкорт егете,— ул — балалы хатын.

— Нинди бала?!— Конвой башлыгы ачуыннан елан чаккандай сикереп китте: — Шул гына җитмәгән, юлга бала белән. Бир әле конвоирга, балалар бүлмәсенә тапшырсын.

— Миндә көчек юк!

— Молчать! — Түрә кеше акырып җибәрде.— Мин сиңа күрсәтермен тешләреңне. Иптәш Иващенко! — Ул чылбыр булып безне урап торган конвоирларның чегән хатынына якынрак торганына эндәште: — Ал баланы, вокзалдагы дежур милиционерга бир!

— Тыңлыйм! — Иващенко мылтыгын янындагы иптәшенә бирде дә чегән хатынына ташланды. Хатын, ялт, аркасы белән борылды. Солдат алга чыгып, хатынның күкрәгенә кул сузган иде, кинәт аның битенә шап итеп хатынның кулы төште.

— Аһ сөйрәлчек, син әле конвоирга сугасыңмы? — Гайрәтле түрә, чыпчык кебек сикерә-сикерә килеп, балалы чегәннең аркасына төртте. Хатын перронга барып капланды, бәбие акырып елап җибәрде. Конвой башлыгы хатынны тагын бер тибеп әйләндерде дә баланы тартып алырга иелде һәм шундук, «А!..» дип яман тавыш белән акырып, артка чигенде. Аның уң кулыннан кан тамчылый иде.

Ике тапкыр кыңгырау чыңлады. Начальник кесәсеннән яулык алып, уң кулын урады да вагонга йөгерде, тамбурда басып торган проводницаны чакырып, колагына нидер пышылдады. Проводница, ризалык белдереп, башын иде.

— Әйдә, үләксә, йөгер теге вагонга! — Түрә кеше чегән хатынын куа, ашыктыра башлады.— Тиз, тиз, падла!

Хатын, баласын кочаклаган килеш мүкәләп, егылган җиреннән торды. Үзе һаман «ә-ә-ә» дип баласын тынычландыра. Аның әле бала имезеп утырган җирендә зур гына капчыгы да бар икән. Бер кулы белән баласын күкрәгенә кысып, икенчесе белән биштәрен өстерәп, яшел вагонга, конвой күрсәткән, проводница басып торган ишеккә таба ашыгып атлады. Начальник арттан аның саен кызулады.

— Тизрәк, тизрәк, үләксә! Поезд кузгала. Синең аркада әнә составны тотып торам, адәм актыгы!

Чегән хатыны абына-сөртенә капчыгын өстерәп баскыч төбенә килеп җитте. Үзе мышный, баласы елый.

— Әйдә, әйдә, мен вагонга.

Хатын бер кулы белән баласын кысып, икенчесе белән капчыгын өстерәп, вагонга күтәрелмәкче иде, баскыч биек, аягы җитми. Ул арада өстә басып торган проводница, елмаеп:

— Бирегез балагызны, мин тотып торыйм,— диде.

— Рәхмәт.

Чегән хатыны баласын проводницага биреп, үзе ике куллап капчыгын күтәрде — вагонга менәргә азапланды. Шундук шап итеп эчке ишек ябылды. Хатын акырып җибәрде:

— Мишут-ка-а...

Ул арада күрше вагонның ишеге ачылды һәм аннан теге проводница кызыл чүпрәккә төрелгән баланы конвой башлыгына сузды.

— Иващенко! — Начальник конвоир солдатны чакырып алды да акырып елаган баланы сузды:— Мә, тизрәк вокзалга, детприемникка илт.

Иващенко бик шыксыз-унайсыз рәвештә төргәкне алып култык астына кыстырды да вокзалга таба йөгерде. Бала буылып, үксеп елый иде:

— Ә-әү... Әү...

Паровоз соңгы гудогын бирде.

Безне тиз генә этеп-төртеп вагонга керттеләр. Поезд кузгалды.

Столыпин вагонында тоткыннар өчен дә комфорт җитәрлек — купелы вагоннардагы кебек аерым-аерым бүлмәләр. Бары тик тәрәзәләре, көзгеләре, радиосы, вентиляциясе генә юк. Аның каравы ашау-эчү өчен ресторанга барып йөрисе юк — китереп торалар. Бу купе-камераның истәлекле, күзгә ташланып торган җиһазы — ишек. Ул тимер белән тышланган. Югары өлешендә ачыла-ябыла торган тимер рәшәткәле форточкасы бар. Ә форточкада сәгать телендәге сыман түгәрәк тимер кисәге — «медаль» асылынып тора. Бу — «күз». Коридорда кизүдә торучы конвоир һәрвакыт «күз» янында. Ул аны түргә үткәндә дә, ишеккә атлаганда да ачып карый — сыңар күз белән, әмма җентекләп. Башкача мөмкин дә түгел — устав куша. Купе-камерага бикләнгән җинаятьчеләрдән теләсә нинди «баш китәрлек» эшләр көтәргә була. Мәсәлән, идәнне, түшәмне, стенаны тишеп качу яки хат-мазар төшереп калдыру, яки асылыну... Шуның өчен «күз» һәр минут ачылып-ябылып тора.

Менә шушындый купе-камераның берсендә без — сигезәү. Яныбыздагы кырый камерага теге чегән хатынын япкан булганнар икән. Ул бертуктаусыз ишеккә суга, тибә, кычкыра.

— Ачыгыз! Ачыгыз дим, җен-пәриләр. Кайда минем улым? Кайда минем Мишуткам! Ачы-гыз! А-чы-гыз! Ишетәсезме, ерткычлар, ишетәсезме?

— Җүләр, кычкырма! Уфа инде әллә кайда калды,— ди кизүдәге Иващенко, форточканы шарт-шорт ачып-ябып.

— Улымны... Улымны кая куйдыгыз? — Йөрәк өзгеч тавыш һәм акырып елау.

Бөтен вагон бу зардан, елау-каргаудан тетрәнә, йөрәк әрни, ташый, түгелә. Ә чегән хатыны һаман ишекне шакый, тырный, суга, тибә һәм яман тавыш белән кычкыра:

— Улымны... Мишуткамны... Кошчыгымны кая куйдыгыз?! Бирегез, бирегез...

Берәр сәгатьтән соң күрше вагонда баручы конвой башлыгының тавышы ишетелде. Ниндидер боерыклар бирде һәм

кизү торучы солдатның чегән хатыны турындагы рапортына тыныч кына:

— Еласын, тамагы карлыккач туктар әле,— диде.

Түрә чыгып китте. Форточка ачылды. Безгә бирәр селедка, өч йөз грамм ипи бирделәр — кичке аш. Тамак ялгарга утырдык. Әмма нихәтле ач булмыйк, ризык бугаздан үтми, тыгыла. Чөнки колакта чегән хатынының зарлы тавышы, ләгънәте, ялваруы. Өч-дүрт сәгатьтән ишеккә сугу, тибү тукталды, тавыш та акрынланды. Хәзер шыңшып елау, үксү һәм зар...

— Мишутка, бәгърем... җаным... кошчыгым. Инде карының ачкандыр, имәсең киләдер. Менә имиләремә сөт төште, сызлый. Ми... шут... ка... Аһ...

Буферлар бер-берсенә сугылып шыңшый. Тәгәрмәчләр, рельслар башына сугылып, бертуктаусыз шак-шок, шак-шок итә. Анда-санда паровоз кычкыртып куя. Туктый. Перронда шау-шу, кыңгырау. Буферлар сугыла. Тагын шак-шок, шак-шок. Поезд каядыр ашыга. Кая? Безгә билгесез. Нинди язмыш, нинди яңа михнәтләр, газаплар көтә безне?

— Шак-шок, шак-шок.

Керфекләр эленә.

Яман бер тавышка сискәнеп уяндым.

— Мишутка, у-лым, син кай-да-а?

Әйтерсең лә йөрәкне телгәләп, тоз сибәләр, ул әрни, сызлый, сыгыла.

— Ми-шут-ка-а-а-а!

Карлыккан тавыш тагын тозлы күз яшенә тыгылып ялварды.

Төн. Шак-шок, шак-шок һәм кизүдәге конвойчының аяк адымнары. Аннан тагын күрше купеның ишегендә акыру, елау, шаку, тибү, теш шыгырдату һәм ләгънәтләү. Паровоз бөтен даланы шыңлатып кычкырта-кычкырта да чаба бирә.

— Җеннәр, пәриләр, кая куйдыгыз минем газиз улымны, бирегез! — Инде тавыш акрын, гырылдап чыга.

Ниһаять, таң алдыннан күрше камерадагы тавыш тынды.

— Бичара хатын. Йоклап китте, ахрысы,— диде авыр сулап күршем Мәхмүт Әбҗәлимов.

— Арыгандыр инде мескен. Әйдә, без дә йоклап алыйк ул уянганчы,— дидем дә борылып яттым, күзләремне йомдым.

Коридорда пыш-пыш сөйләшү, арлы-бирле йөгерүгә уянып торып утырдык. Бар игътибарыбыз — коридорда. Нәрсә?

Менә вагонның тышкы ишеге шарт итеп ябылды. Конвой башлыгының ачулы тавышы яңгырады:

— Ни булды?

— Иптәш... начальник... үлгән.

— Кем үлгән?

Тагын кизүдәге конвоирның хәвефле һәм пышылдау тавышы:

— Чегән хатыны, иптәш начальник. Асылынган...

Сораулар һәм биремнәр.

1. Автор чегән хатынының тышкы кыяфәтен ничек сурәтли?
2. Бу хатынның кыюлыгы нәрсәдә чагыла?
3. Конвоирлар хатынны баласыннан ничек мәхрүм итәләр?
4. Чегән хатынының язмышы ни белән тәмамлана? Бу фаҗигале язмышның сәбәпләрен аңлатыгыз.

Зыя Мансур
(1916—1965)

Зыя Мансур 1916 елның 17 декабрендә хәзерге Башкортстанның Дүртөйле районы Җитембәк авылында крестьян гаиләсендә туа. 1937 елдан аның мөстәкыйль хезмәт юлы башлана. Ул Дүртөйле район газетасы редакциясенә эшкә урнаша, башта корректор, аннан әдәби хезмәткәр вазифаларын башкара. 1939 елда армиягә алынып, ул сугышның башыннан ахырына кадәр фронтта була, берничә мәртәбә яралана, сугыштагы батырлыклары өчен орден һәм медальләр белән бүләкләнә.

Сугыш беткәч, Зыя Мансур туган якларына әйләнеп кайта, Дүртөйле район үзәгендә радиотапшырулар дикторы һәм Илеш район Мәдәният йорты директоры булып эшли. 1949 елда Казан дәүләт университетының филология факультетына укырга керә, әмма сугышта алган яралары аңа укуын тәмамларга мөмкинлек бирми. Соңрак ул Татарстан радиокомитетына эшкә урнаша, аннары «Чаян» журналы редакциясендә әдәби хезмәткәр була, ә 1956 елдан профессиональ язучылык эшенә күчә.

Әдәби иҗат белән Зыя Мансур сугыш елларында ук шөгыльләнә башлый. Бу эшкә аны фронтта күргән-кичергәннәре, чорның һәм үзенең патриотик хисләрен шигырь белән чагылдыру теләге этәрә.

Сугыштан кайткач, аның иҗат итү теләге бермә-бер көчәя, һәм ул үзен бөтен барлыгы белән шушы эшкә багышлый. Матбугат битләрендә актив чыгыш ясау белән бергә, 1950 елда аның «Язгы ташкыннар» исемле беренче җыентыгы дөнья күрә.

Аннары укучылар бер-бер артлы Зыя Мансурның «Казан җыры», «Ләйсән», «Уйланулар», «Озын Колак баласы Елак-Мылак», «Май җыры», «Кырлар сулышы», «Ак розалар», «Этаплар китабы», «Үрләргә күңелем гашыйк» һәм башка шигырь китаплары белән танышалар.

Лирика белән беррәттән, Зыя Мансур юмор-сатира һәм балалар поэзиясе өлкәсендә дә актив эшләде. Әмма сәламәтлегенең елдан-ел начарлана баруы аңа иҗат планнарын тулысы белән тормышка ашырырга мөмкинлек бирмәде. Ул әле җиң сызганып иҗат итәр вакытында, 49 яшендә, 1965 елның 11 ноябрендә дөньядан китеп барды. Иҗат гомере кыска булса да, ул татар поэзиясендә якты эз калдырып китте.

ТАҢСЫЛУ ӘКИЯТЕ

Айда түгел, без яшәгән җир өстендә,
Элек түгел, хәзерге бер тыныч көндә,
Сирәк очрый торган матур бер кыз туа.
Хәйран кала хәтта Зөһрә йолдыз моңа.
Көнләшәләр чәчәкләр дә бу кыз тугач,
Бигрәк сылу дип соклана ай һәм кояш.
Чыннан да, кыз асылларның асылы бит,
Исемен дә тиң кушканнар Таңсылу дип.
Бала түгел, курчактыр бу, диләр аны.
Чибәрлектә ерак китә кызның даны.
Ләкин ничек аңларга соң, нәрсә булган?
Тавыклар да кыт-кыт көлә чибәр кыздан.
Юк, юк, диләр, булмый мондый кызны мактап.
Кирәк булса мактый бирсен әнә ахмак.
Апалар да, абыйлар да мактамыйлар,
Әбиләр дә аңа карап шатланмыйлар.
Ямьсез, диләр. Нәрсәдә соң сере моның?
Гадәт ягы начар икән сылу кызның.
Уйнамый ул дус-ишләре белән бергә,
Теләми дә кеше белән сөйләшергә.
Бөтенесен эшли алам берүзем, ди,
Ни әйтсәң дә: мин беләм, син белмисең, ди.
Тыңламый ул олыны да, кечене дә.
Кирәге юк миңа, ди ул, һичкемнең дә.
Шуңа бит ул, кеше-фәлән күреп калса,
Я абзарга, я мунчага кереп кача.

* * *

Көннәрдән бер көнне кызның дус-ишләре,
Язгы гөлләр сипкән чакта хуш исләрен,
Җыелалар олы урман аланында,
Бергәләшеп уйный-көлә алар монда.
Яшел урман матур итеп шаулап тора,
Куакларда мең төрле кош сайрап тора.
Кай төштәдер чишмә ага чылтыр-чылтыр,
Ә чәчәкнең бу аланда чуты юктыр.
Күбәләкләр уйный-уйный оча монда,
Рәхәт тә соң язгы урман кочагында!
Куелыкта мыштым гына йөри аю,
Уе аның берәр кызны алып таю.
Курка ләкин: кызлар күмәк икәннәр, ди,
Минем хакта ахры белеп килгәннәр, ди.
Уңнан карый, сулдан карый киң аланга,
Эче поша эше уңай булмаганга.
Нәкъ шулвакыт ишетә ул үз алдында,
Ерак түгел, ике адым, өч адымда,
Ләкин теге дус кызлардан бер як читтә
Кемдер йөри, аю бар дип белми һич тә.
Кемдер йөри, мыгырдана «мин» дә «мин» ди,
Куян килеп чыкса алыр кирәген, ди.
Төлкене дә көлке итәм куркытып, ди,
Аюлар да кача миннән шыр итеп, ди.
Очыну да, масаю да чиктән ашкан,
Борын дисәң, күтәрелеп күктән ашкан.
Сиздермәскә тели куркып калтыравын,
Ни кирәге бардыр тыштан ялтырауның?!
Дусларының шат уйнавын күрә, көнли,
Кушылыр иде, тәкәбберлек ирек бирми.
Ялынсалар кушылам, ди һәм шулвакыт
Аю алып кача аны җил уйнатып.
Дус-ишләре ишетеп кала чырылдавын,
Аңлый алар куелыкта ни булганын.
Таңсылуны аю алды, диләр алар,
Тизрәк ярдәм итү өчен кузгалалар.
— Туктагыз,— ди, берсе әйтә,— уйлап карыйк,
Ул юньсезне ни өчен без юллап барыйк?
Без бит кирәк түгел идек аның өчен,

Аю белән үз көнен үзе күрсен.
— Юк,— ди кызлар,— әгәр аны коткармасак,
Мондый хәлдә «начар кыз» дип туктап калсак,
Без үзебез начар булган булыр идек,
Әйдә, тизрәк аңа ярдәм кулы бирик!
Әйе, кызлар дөрес әйтә: кырдамы син,
Таулар-ташлар арасында, судамы син,
Уттай чүлдә авыр юллар үтәсеңме,
Беркайчан да истән җуйма иптәшеңне.
Хәтта үзең авыр хәлдә калганда да,
Көч кызганмый күрсәтә бел ярдәм аңа.
Начар иптәш дип карама, була бирсен,
Авыр чакта үзең яхшы була бел син!

* * *

Менә аю сараенда, таш идәндә,
Караңгыда һәм салкында баш игән дә
Газаплана богаулы кыз көннәр буе,
Күз яшьләре ага озын төннәр буе.
Үкенә кыз: «Ник дуслардан читтә йөрдем,
Минем өчен һичкем кирәк түгел, дидем.
Аерылганны аю ашый, диләр иде,
Нигә мин гел сөйләдем үз сүзләремне?!
Кызлар бар да көләләрдер миннән хәзер,
Әйбәт булды акылсызга, дигәннәрдер...»
Төгәл җитмеш җиде көн дигән көнне
Әйтә аю: мин бу кызны буам инде.
Чибәрлеккә чибәр, ләкин җитте чират,
Ашыйм инде бу кызны мин, ди ул, ырлап.
Тәмләнгәндер, инде озак сакладым, ди,
Эсседә дә, салкында да какладым, ди.
Уйлый-уйлый кызны йоту шатлыкларын,
Эзли аю таш сарайның ачкычларын.
Куе урман талгын гына шаулап тора,
Куакларда мең төрле кош сайрап тора.
Кай төштәдер чылтыр-чылтыр чишмә ага,
Билгесез шул кыз язмышы һич тә аңа.
Туктагыз сез, сандугачлар, сайрамагыз,
Мең яшәгән карт агачлар, шауламагыз.

Аюның теш шакыганы ишетелсен,
Шуны ишетеп, яклаучылар бире килсен.
Юк, шаулагыз! Әнә, авыр юллар үтеп,
Дустыбызны коткарырга кирәк бит дип,
Иксез-чиксез газап чигеп йөри торгач,
Арып-талып җан-фәрманга әзли торгач,
Аю өен табып алган инде кызлар,
Ерткыч белән хисаплаша кыю кызлар.
— Даешь,— диләр,— даешь безнең Таңсылуны!
Ләкин аю һич көтмәгән иде моны.
Белми кая керергә дә, аптырый ул,
Көчле бизгәк тоткан кебек калтырый ул.
Алда торган кыз өстенә ыргыйм дисә,
Күтәлмәстән җилкәсенә кусәк төшә.
Уңга ыргый, кундыралар сул ягыннан,
Сулга карый, тондыралар уң ягыннан.
Йөз дә түгел, мең дә түгел кызлар монда,
Искитәрлек корал да юк кулларында.
Берсенең дә мылтыгы һәм кылычы юк,
Җиңә монда бердәмлек һәм куркусызлык.
Таңсылуның салдыралар богауларын.
— Рәхмәт,— ди кыз,— коткардыгыз, туганнарым.
Сабак булсын,—ди ул,—монда тилмергәнем,
Аерылмам сездән гомер-гомергә мин!
Иптәшләрен кочаклый кыз: — Рәхмәт! Рәхмәт!
Аю кача, күз дә ача алмый рәтләп.
Утта янган кебек сизә бөтен тәнен,
Үзе генә белә аю үзе хәлен.
Теле булса, ул да әйтер иде бүген
Иң зур көчнең бердәмлектә икәнлеген.

* * *

Шул көннән соң Таңсылуны күргән халык
Карап тора шатланып һәм хәйран калып.
Дусларыннан аерылмый икән, диләр,
Йөзе моның нурдай балкып киткән, диләр.
Куаналар чәчәкләр дә бу хәл тугач,
Сылу кыз дип сокланалар ай һәм кояш.

Зөһрә йолдыз — Венера планетасының безнең халык арасында таралган поэтик исеме
сылу — чибәр, гүзәл
алан — болын
шыр итеп — куркып
истән җуйма — онытма
каклау — тозлап киптерү (итне, балыкны)
җан-фәрманга — бөтен көчкә, бар көче белән; тырышып

Сораулар һәм биремнәр.

1. Зыя Мансурның тормышы һәм иҗаты турында сөйләгез.
2. Автор әкияттәге кызга ни өчен Таңсылу дип исем биргән?
3. Ни өчен Таңсылуны башта беркем дә яратмый?
4. Урманда нишләп аны аю урлап китә?
5. Моннан соң иптәш кызлары Таңсылу язмышына ничек карыйлар?
6. Таңсылуны аюдан коткаруда иптәш кызларына нәрсә ярдәм итә?
7. Бу шигыре белән автор укучыларга нәрсә әйтергә тели?
8. *Аерылганны аю ашар, бүленгәнне бүре ашар* дигән әйтемне ничек аңлыйсыз?
9. Әкиятне укыганнан соң, үз арагыздагы дуслык, иптәшлек турында әңгәмә уздырыгыз.

Әмирхан Еники
(1909—2000)

Әмирхан Еники 1909 елның 2 мартында Башкортстанның Благовар районы Яңа Каргалы авылында морзалар нәселеннән булган таза тормышлы крестьян гаиләсендә дөньяга килә. 1911 елда әтисе гаиләсе белән Дәүләкән авылына күченә һәм анда сәүдә эше белән шөгыльләнә башлый. Кечкенә Әмирхан үзенең балалык һәм мәктәп елларын шушы авылда уздыра.

Әмирхан Еники, балачак хыялларын тормышка ашыру нияте белән 1925 елда Казанга килә һәм, азрак китап кибетендә эшләгәннән соң, Казан университеты каршындагы рабфакка укырга керә. Шушы вакыттан ул кулына каләм ала, иҗат эше белән шөгыльләнә башлый. Нәтиҗәдә матбугат битләрендә аның беренче әдәби парчалары һәм хикәяләре дөнья күрә.

1927 елдан алып сугыш башланганчыга кадәр төрле җирләрдә булып һәм күп эшләрдә эшләп, Әмирхан Еники бай тормыш мәктәбе уза. 1941—1945 елларда Бөек Ватан сугышында катнаша. Аннан кайткач, «Совет әдәбияты» журналы редакциясендә, Татарстан радиокомитетында, Казан авиация техникумында эшли, ә 1953 елдан профессиональ язучы булып китә.

Әдәби иҗат белән егерменче еллардан ук шөгыльләнеп килсә дә, Ә. Еникинең язучылык йөзе сугыш елларыннан ачыграк күзаллана башлый. «Бала», «Ана һәм кыз», «Бер генә сәгатькә», «Ялгыз каз», «Мәк чәчәге», «Кунакчыл дошман», «Тауларга карап» кебек хикәяләрендә ул үзен тормышка үз карашы булган үзенчәлекле автор итеп күрсәтә.

Әмирхан Еникинең тормышка һәм язучы хезмәтенә мөнәсәбәте илленче еллардан соң тагын да ачыграк күзаллана. Алга таба аның иҗат мөмкинлекләрен тулысынча ачып биргән әсәрләре — «Саз чәчәге», «Йөрәк сере», «Рәшә», «Вөҗдан», «Без дә солдатлар идек», «Гөләндәм туташ хатирәсе» повестьлары, «Ялгызлык», «Туган туфрак», «Матурлык», «Төнге тамчылар», «Коръәнхафиз», «Әйтелмәгән васыять», «Тынычлану» шикелле хикәяләре дөнья күрә. Бу әсәрләрендә Әмирхан Еникинең агымдагы сәясәттән өстен булып кала алуы күренә. Аны күбрәк кешеләрнең әхлакый йөзе, уй-кичерешләре, эчке дөньясы, көндәлек тормыштагы борчулы күренешләр кызыксындыра, укучының игътибары да шуларга юнәлтелә. Нәтиҗәдә Ә. Еникинең һәр әсәре диярлек, басылып чыгу белән, киң җәмәгатьчелекнең дикъкатен җәлеп итә, әдәбият дөньясында үзенә бер вакыйгага әверелә.

Үзенең күпьеллык тынгысыз һәм үзенчәлекле иҗат эшчәнлеге өчен Әмирхан Еники Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләгенә һәм «Татарстанның халык язучысы» дигән мактаулы исемгә лаек булды.

КЕМ ҖЫРЛАДЫ?

Ватан сугышының дәһшәтле көннәреннән берсе иде. Күзгә караңгы төндә җимерек бер кечкенә генә станциядә ике эшелон очрашып, янәшә туктадылар. Боларның берсе тылдан фронтка яңа хәрби часть алып баручы эшелон, икенчесе фронттан тылга яралылар төяп кайтучы санитар поезды иде. Эшелоннар икесе дә бик озын булып, гел кызыл вагоннардан торалар. Тик санитар поездының гына паровозга якын очында бер-ике классный вагоны бар, ә калганнары исә кечкенә чуен мичләр куеп җылытылган теплушкалар иде.

Станция дигән нәрсәнең үзе дә, бер генә бер каралтысы да юк — бар да җимерелеп беткән. Юллар буенда берничә кат юан бүрәнәләр түшәп һәм балчык өеп эшләнгән ярым землянка ялгызы калкып тора — бары шул гына. Бөтен станциясендә ник бер генә тычкан уты җемелдәсен, әйләнә-юнь морҗа эчедәй кап-кара. Ләкин еракка күз ташласаң, сугыш барган якта, кайдадыр офык артында ук, күк чите буйлап сузылган кандай кызыл шәүлә тирбәлә. Янамы анда берәр зур авыл, туплар атышы шулай чагыламы,— моннан карап белеп булырлык түгел.

Бөтен әйләнәдә фронтка якын җирләрдә генә була торган үле бер тынлык хөкем сөрә. Хәтта эшелоннар башындагы ике кап-кара паровоз да тып-тын торалар, әйтерсең казаннарын сүндереп, аларны ташлап киткәннәр... Эшелоннарны томалап куйганнар диярсең, берсеннән-бер көлгән, сөйләшкән тавыш ишетелми, төшеп-менеп йөрүче дә күренми. Тик араларыннан узганда, туктала биреп колак салсаң, бер яктагы кызыл вагоннардан ара-тирә каты хырылдау, икенче яктагы теплушкалардан авыр ыңгырашу ишетелеп кала. Берәүләр соңгы тапкыр йокы туйдыралар, икенчеләр бер күз йомарга гаҗиз булып яталар, күрәсең.

...Теплушкаларның берсендә, түбәндәге сәкедә каты яралы яшь лейтенант татар егете ята. Егетнең хәле авыр, уң аягы аның тездән югары киселгән, ә санитар поезды юлга чыккач, аңарда гангрена башланды. Менә бер тәүлек инде ул ни йоклый, ни уяна алмыйча, яртылаш һушын югалткан хәлдә ята. Вакыт-вакыт ул аңына килә, шул чакта авыр газаптан талган күзләрен ача, янында басып торган ак халатлы шәфкать туташын күрә, аның салкын кулын маңгаенда тоя. Бер мәлгә егет үзен җиңеләеп киткәндәй хис итә, хәтта уң аягы бар, ул кычыта кебек тоела аңа... Ләкин бу хәл озакка бармый, тагын бөтен тәне буйлап ут тарала, күзләрендә бизгәк чаткысы кабына. Бераздан егет күз кабакларын акрын гына йома һәм, һушын югалтып, яңадан эссе томан эчендә йөзә башлый. Яткан урынын да, туташның кагылуын да, хәтта шприцның очлы инәсен дә ул инде тоймый...

Шулай үлем тырнагыннан ычкына алмыйча газапланып ята егет. Врачларның өметләре аз, гангренаның никадәр хәтәр нәрсә икәнен алар яхшы беләләр. Бигрәк тә юл шартларында авыруның хәлен җиңеләйтү бик читен эш иде.

Бу кечкенә станциягә килеп туктагач, күпмедер вакыттан соң егет тагын бер мәлгә һушына килде. Талган, инде бу дөньядан китә башлаган күзләрен ачты, вагон эченә сибелгән зәгыйфь сары яктылыкны, шул тонык яктылыкта басып торган ак халатлы шәфкать туташын күрде. Тышта, вагон стенасына ышкылып кына яуган көзге вак яңгырның әкрен генә кыштырдавын ишетеп калды. Кара янып кипкән иреннәрен хәлсез ялап куйды,— әчәсе, бик әчәсе килә иде аның...

Шәфкать туташы моны аңлады, алюмин кружкадан аңа бер йотым су эчерде. Егетнең рәхмәт әйтерлек хәле юк иде,

ул бары аз гына җылына төшкән күзләрен туташка күтәреп, кара керфеген генә сирпеп куйды.

...Әллә шул чакта, әллә чак кына соңрак егетнең колагына каяндыр җыр ишетелде. Татарча җыр!.. Егет өне катып, тынып калды. Нәрсә ишетә ул, кемне ишетә? Я Хода, аның Таһирәсе җырлый түгелме соң? Шул ич, шул, Таһирә тавышы! Кайда ул?.. Егет, үзен белештермичә, яткан җиреннән бер омтылып куйды. Шунда ук аның күз аллары караңгыланып китте, башы хәлсезләнеп мендәр читенә авып төште. Шәфкать туташы куркынып тизрәк аның кулын алды, пульсын капшады. Әмма егет һушыннан язмады, дөресрәге, һичнәрсәне, һичкемне сизмәс булса да, җырны ишетүдән туктамады. Яңадан бөтен дөньясы эссе томанга йотылса да, җыр... җыр калды.

Ә бу җыр чынлыкта бар иде, ул янәшәдәге эшелонның бер вагоныннан килә иде. Әгәр теплушка белән кызыл вагонның ишекләре бер-берсенә капма-каршы туры килгән булсалар, ишек яңагына сөялеп, кулларын шинель җиңнәренә тыгып җырлап торучы кыз, ихтимал, үзе дә күренгән булыр иде. Ләкин теплушканың аз гына ачык ишегеннән ут яктысы кыздан читкәрәк, кызыл стенага тар гына сары юл булып төшкән иде.

Күзгә күренмичә, берничә адымнан гына торып җырлаган кыз ялгызы гына булса кирәк, чөнки бүтән беркемнең дә тавышы ишетелми. Ихтимал, ул төнге дежурда торадыр, шунлыктан, ахрысы, иптәшләренең татлы йокысын бозарга теләмәгәндәй, ничектер тыелып, әкрен җырларга тырыша кебек... Әмма аның иркен, матур, аз гына калынрак күкрәк тавышы төнге тирән тынлыкта бик ачык булып ишетелә иде.

Кыз, үзенең ниндидер яраткан көен эзлиме, бер җырны башлый да, бетермичә, икенчесенә күчә, бераз җырлагач, туктап тынып тора, аннан тагын акрын гына башлап китә. Үзен тирәнрәк тәэсирләндергән кайбер көйләрне озаграк та җырлап куя, әмма ул кем дә булса мине ишетәдер дигән уйны күңеленә дә китерми иде, әлбәттә.

Искиткеч таныш, якын тавышны ишетеп беренче тирән тетрәнүдән соң, егетнең рухи хәлендә гаҗәеп бер үзгәреш туды: ул җырлаучының кем булуы белән кызыксынмас булды. Күрәсең, аның сүнеп бетмәгән аңы могҗиза булуына — Таһирәнең кул сузымы гына җирдә җырлап торуына ышана алмады. Хәер, кем җырласа да барыбер түгелмени, тик җыр булсын, җыр туктамасын. Татар җыры, Таһирә җыры, туган

як җыры... Аһ, моңардан да ләззәтле нәрсә булырга мөмкинме?!

...Һәм вагон стенасына ышкылып кына яуган вак яңгыр аша әкрен-ачык ишетелгән җыр, күктән иңгән ак канатлы фәрештәдәй, егетне, ут эчендә яткан җиреннән сак кына күтәреп, каядыр еракка, татлы хыял дөньясына алып китте. Аның хәтта тәне һавада йөзгәндәй җиңеләеп калды, акылы ничектер бердән яктырып китте, сизгерлеге искиткеч үткенләште. Җырны инде ул хәзер моң итеп кенә ишетмичә, гаҗәеп ачык сурәтләр тезмәсе итеп тә күрә иде.

...Менә кыз әкрен генә башлап, аннан тавышын күтәрә төшеп, сузып кына җырлый:

Сарман буйлары киң ялан,
Печәннәре җитәр берзаман шул,
Печәннәре җитәр берзаман...

Һәм егетнең күз алдына үтә ачык булып, әллә кайларга кадәр җәелеп яткан чуп-чуар чәчәкле болын килә. Үлән башларын, чәчәкләрне селкетеп, йомшак кына җил исә, имеш. Каяндыр, тургай сайрауларына кушылып, чалгы янаган тавышлар ишетелә кебек, йомшак җил кибеп яткан покосларның хуш исен китерә кебек, тик егет печән чабучылар ягына нигәдер борылып карый алмый, имеш. Ул да булмый, аның күз алдына бормаланып киткән тар гына болын юлы килә. Хәтта бер мәлгә егет үзе дә ике рәт үлән арасындагы тәгәрмәч эзеннән җылы туфракка яланаяк баса-баса китеп бара кебек, ә каршысына киез эшләпә кигән, таякка таянган, ак сакаллы бер карт килә кебек...

Күпмедер вакыт узгач, кызның тагын моңлы җыры ишетелә:

Кояш бата, айлар калка,
Бик ямансу шул чакта...

Һәм егетнең күз алдына үзләренең шәһәрдәге кечкенә өйләре килеп баса. Эңгер-меңгер вакыты, имеш. Өйдә әнисе ялгызы гына икән. Менә ул, ак яулык бәйләгән кечкенә карчык, ут кабызып, бисмилласын әйтә-әйтә, тәрәзә пәрдәләрен төшереп йөри, тәрәзә төбендәге гөлләрнең кипкән яфракларын чүпләп-чүпләп ала, имеш. Өстәлдә яңа гына кайнап чыккан самавыр тора икән. Әнисе аның институттан кайтканын шулай чәй әзерләп көтә, имеш.

— Әнием, әнием!— ди егет, эченнән үксеп, һәм аның йомык күзләреннән сыгылып, терекөмештәй кайнар яшь бөртекләре кипкән иреннәренә акрын гына тәгәрәп төшәләр. Шәфкать туташы кулын аның маңгаена куеп, иелеп, нидер сорый шикелле, ләкин егеткә гүя Таһирәсе дәшкән кебек тоела.

Шул чакта кыз тирән бер сагыш белән:

Инде кемнәргә карармын
Өзелеп сагынганда...—

ди.

Һәм егет ике куллап Таһирәсенең башын күкрәгенә кыса, имеш, йөзен аның күперенке чәчләренә куя, имеш, иреннәрен аның җылы, йомшак муенына тидерә, имеш: «Бәгърем, бәгърем, күз нурым! Нигә алай дисең, нигә елыйсың? Без мәңге, мәңге бергә ич!»

Һәм кыз, башын аның күкрәгеннән алмыйча, назланып зарын әйтә кебек:

Сагынам үзем, юлда күзем,
Саргайды нурлы йөзем...

* * *

Юк, юк, бүтән аерылу юк. Инде без бергә, дустым, мәңге бергә!.. Менә алар җитәкләшеп, ашыга-ашыга Идел тавына менәләр, имеш. Тау бик биек икән, туктап-туктап тын алалар, кулларын җибәрмичә, сүзсез генә бер-берсенең күзләренә карап, бәхетле елмаялар, тагын кузгалып китәләр... Ниһаять, менеп җитәләр. Я Хода, нинди киңлек, нинди чиксез нур һәм ямь дөньясы бу туган җир! Шундый җиңел, шундый рәхәт аларга! Менә алар, тотынышкан хәлдә кулларын киң җәеп, таудан күтәреләләр һәм, пар аккоштай, үз гәүдәләренең авырлыгын да тоймыйча, шул чиксез нур дөньясына очалар, очалар...

* * *

Кыз җырлавыннан кайчан туктады, каршыдагы эшелон кайчан тавыш-тынсыз гына кузгалып китте,— егет моны сизмәде. Ул инде яңадан аңына килә алмады. Ә икенче көнне санитар поезды тагын бер җимерек разъездга җитеп туктады. Кызыл теплушкадан егетнең үле гәүдәсен носилкага салып чыгардылар да юлдан ерак түгел бер калкулык өстендәге ялгыз

нарат төбенә илтеп күмделәр. Күмеп беткәч, туфрак өеменең башына кечкенә фанера кадакланган казык утыртып куйдылар. Фанерага кара буяу белән егетнең исеме, фамилиясе, туган һәм үлгән еллары язылган иде. Речь-фәлән сөйләү булмады. Күмүчеләр башларыннан салып, кабер әйләнәсендә бераз тынып тордылар да аннан барысы берьюлы вагоннарына таралдылар.

Поезд китте, ялгыз кабер торып калды.

Кинәт җил исте, биек нарат, эре яңгыр тамчыларын җиргә коеп, салмак кына башын чайкады. Күктәге салынкы соры болытлар, кемгәдер юл ачкандай, икегә аерылдылар. Шунда ук зәңгәр яктылыктан, күмү мәрасименә соңга калгандай, ашыгып кояш карады. Нарат төбендәге кабер өсте әйтерсең егетнең җирдә калган, үлмәгән һәм мәңге үлмәячәк якты хыяллары белән кинәт нурланып балкыды.

Караңгы төндә каршы очраган эшелонның вагон ишегенә сөялеп, ялгызы гына моңаеп җырлаган кыз исә, чыннан да, бу егетнең сөйгәне Таһирә иде.

аксакал — ихтирамга лаеклы өлкән яшьтәге кеше
дикъкать — игътибар
сәясәт — политика
иҗтимагый — җәмгыятькә караган
мөһим — әһәмиятле
дәһшәтле — зур бәла-каза китерә торган, афәтле
офык — горизонт
гаҗиз булу — аптырап калу
ләззәт — рәхәт
эңгер-меңгер — караңгы төшәр-төшмәс вакыт
мәңгегә — гомергә, бөтенләйгә

Сораулар һәм биремнәр.

1. Ә. Еникинең тормышы һәм иҗат юлы турында сөйләгез.
2. Язучының нинди әсәрләрен беләсез?
3. «Кем җырлады?» хикәясендә вакыйга кайчан һәм кайда бара?
4. Яралы лейтенантның авыр хәлен тасвирлагыз.
5. Татар җыры яралы егеткә ничек тәэсир итә? Аның уй-кичерешләре турында сөйләгез.
6. Хикәяне укып, сез үзегез өчен нинди дә булса яңалык ачтыгызмы? Җыр ни өчен кеше күңелен шулай тирән дулкынландыра ала?
7. Җырлаучы кыз кем була?

МАТУРЛЫК

(Бер карт әдип авызыннан)

Күптән, бик күптән булган вакыйга, әмма бүгенгедәй күз алдымда: без, өч шәкерт, бер атка утырып, өяз мәдрәсәсеннән авылыбызга кайтырга чыктык. Дөресрәге, Гыйлемдар белән без икәү бер авылга — Чуар-күлгә кайтабыз, ә Бәдретдинне юл өстендәге Ишле авылында калдырып китәргә тиешбез. Тагын шуны да әйтим: безне ялкау гына юртып алып кайткан күк алаша Гыйлемдарларныкы иде. Без авылда алар белән күрше генә торабыз. Шул сәбәпле Гыйлемдар белән мине алырга бер язын безнең ат килсә, икенче язда алар аты килә торган иде.

Ә Бәдретдин — безнең очраклы юлдашыбыз. Дөрес, без мәдрәсәгә бер вакытта җыелабыз, бер вакытта таралабыз, ләкин моңарчы аның белән бергә кайтырга туры килгәне юк иде әле. Бәдретдин кешегә бер дә йөк булырга яратмый иде. Укулар беткәч тә, ул базарга килгән авылдашларының берсенә ияреп китә дә бара, яки ялгыз үзе генә утыз чакрымдагы авылына җәяүләп сыптыра торган иде. Бу юлы инде без аны, үзебез сорап дигәндәй, бергәләп кайтырга күндердек.

Бәдретдин безнең мәдрәсәдә иң ярлы шәкерт иде. Аңа авылыннан берниндн дә ярдәм килми иде. Тик Ишледән базарга килүче берәрсе бик сирәк кенә аңа әнисенең киндер чүпрәккә төреп җибәргән тары ипиен яки берәр йомарлам маен кертеп чыга торган иде. Бәдретдин шуны да бик кыенсынып: «Нигә инде бу? Әнкәйгә әйтегез, мин ач түгел, үзеннән өзеп җибәрмәсен!» — дип алып кала иде. Һәм шул майны ул, ни өчендер, без белән чәнчеп ашый иде. Шәкертләр аңардан: «Нигә алай итәсең?» — дип сорасалар, Бәдретдин, көлгән булып кына: «Без белән ашагач, озакка җитә ул!» — дип җавап бирә торган иде.

Илдә чыпчык үлми дигәндәй, безнең Бәдретдин дә, бик интегеп, ачка киселеп булса да, укуын әнә шулай алып бара иде. Һәм бик яхшы укый иде ул. Хәер, бу күп сыналган нәрсә: рәхимсез нужада торып укыган ярлы шәкерт гадәттә бик сәләтле булып чыга. Башкача аңа мөмкин дә түгел. Бай шәкерт, әйтик, туң күчән булса да, мәдрәсәдә теләсә күпме ята ала, ә ярлы шәкерт, начар укыдымы, беренче кыштан ук мәдрәсәдән очарга мәҗбүр була... Аннары, ярлы шәкерт бик яхшы укыса гына үзенең матди хәлен дә беркадәр җиңеләйтә ала.

Менә безнең Бәдретдингә дә, ул замандагы тел белән әйтсәк, истикамәтле вә иҗтиһатлы шәкерт булганга күрә, байлар иганәсеннән ара-тирә ярдәм тия иде; начар укучыларның дәресләрен хәзерләшкән өчен дә аңа аз-маз тама иде, хәлфәләргә дә ул булышкалый иде, аннары авыру-сырхауларга догалыклар, аятелкөрсиләр күчереп тә азрак бакырлар төшергәли иде. Кыскасы, эшсез тормый иде шәкерт. Ләкин эшне дә, ярдәмне дә ул үзе бервакытта да сорап алмый иде. «Мин бит ярлы, миңа ярдәм итү сезнең вазифагыз» дигән әрсез мескенлекне без аның йөзендә беркайчан да күрмәдек.

Табигате белән үк ул, ничек дим, шундый тигез, сабыр холыклы бер егет иде. Ялагайлана да белмәс, масая да белмәс, яхшы белән яхшы, ә яман белән алыш-биреше юк,— андыйлардан үзен ничектер бөтенләй читтә тота белә иде. Тагын шунысы кызык: никадәр генә ярлы булмасын, ул берәүдән дә бернәрсә дә сорарга яратмый иде. Гадәттә шәкертләр аңардан гел анысын-монысын сорап торалар, чөнки аның үз кулы белән ясаган каеш тупсалы, әрҗә сыман сандыгында мәдрәсә тормышы өчен кирәк бөтен нәрсәсе — энәсе дә, җебе дә, уймагы да, безе дә, пәкесе дә, эскәге дә, күзгесе дә, төрле каләмнәре дә, кәгазь-дәфтәрләре дә, хәтта җилем белән балавызы да саклана торган иде. Ничек җыйгандыр ул аларны, ләкин һаман шул ярлылыгым кешегә йөк булмасын дип, тамагыннан өзеп булса да тырышкан күрәсең инде. Дөрес, ул калын-калын дәрес китапларына бик мохтаҗ иде. Ләкин булган кадәресен бик пөхтә тышлап, битләре керләнмәсен өчен көмеш кәгазьдән тоткыч ясап, кадерләп кенә саклый иде.

Ул заманда, ягъни революция алды елларында, шәкертләрнең яңа әдәбият белән мавыгуы искиткеч көчәйгән иде. Икмәк шикелле үк зарури бернәрсәгә әйләнеп киткән иде безнең өчен әдәбият!.. Һәрбер шәкерт төпләп алган калын дәфтәренә җыр күчерә, шигырь күчерә, хәтта романнардан өзекләр дә күчерә. Ике шәкертнең берсе шигырь яза. Бик күпләр Сәгыйть Рәми белән тилерә. Аңа иярәләр, аңа охшарга тырышалар, аны яттан сөйләп йөриләр... Дөрес, безнең барыбыз өчен дә бөтенесеннән өстен, бөтенесеннән якын — Тукай иде, иң күп күчерелгән, иң сөеп укылган да Тукай иде.

Шигырь чире безнең Бәдретдингә дә йоккан иде, ул да яза иде, ләкин язганын бервакытта да күтәреп, очраган берәүгә укып йөрми иде. Аны сорап та укырга күндерүе читен иде. Инде укый калса, аның әйберсе башкаларныкы төсле зар

еламыйча гына язылган, күбрәк табигать күренешен гади генә сурәтләгән яки үзенчә бирер тормыш фәлсәфәсе әйтергә тырышкан кыска гына шигъри парча булып чыга торган иде.

Әнә шундый сәер генә, серле генә һәм сөйкемле генә бер егет иде безнең Бәдретдин шәриктәшебез!

Ярый, сүз озынга китте, без бит әле өчәүләшеп читән тарантаста хозур гына авылыбызга кайтып барабыз. Юл такыр, тузан юк, күк алаша, эченә кату төшүдән «горт-горт» иткән тавыш чыгарып, үз көенә салмак кына юырта... Күптән түгел, май урталарында, беренче җылы яңгырлар явып узган иде. Хәзер бөтен нәрсә дәррәү кузгалып, күтәрелеп, үсеп бара: арышлар сабакка сузыла башлаган, бодайлар куе булып, кучкыл-яшел булып, егетләр мыегыдай сызылып кына чыгып килә, сөрелмәгән чирәмнәрдә яшь үлән былтыргы корыган үләнне басып, каплап та киткән, кайберләре инде чәчәкләрен дә ачарга өлгергән... Юл буенда әнә эт эчәгесенең беренче ал «кыңгыраулары»... Әйтәсе дә юк, табигатьнең иң саф, иң садә, иң ямьле чагы!..

Безгә, кыш буе мәдрәсәдә кибеп яткан шәкертләргә бу чиксез иркен, якты, жылыкай дөнья искиткеч тансык иде, шифалы-рәхәт иде, без аны иснәп тә, сулап та, күзләребез белән күреп тә туя алмый идек. Баштарак без әледән-әле тарантастан төшеп, аякларыбыз җирнең йомшаклыгын бер рәхәтләнеп татысын дигәндәй, чирәмгә кереп киттек, йөгерештек-куыштык, иелеп чәчәкләр өздек. Бәдретдин тау юасы тапты, аны өзеп чәйнәдек. Мин безнең авылда «тәмлекәй» дип йөртелә торган, сабагы дүрт кырлы озын гына бер үсемлекне җыеп алдым. Аны да тиресен суеп ашап карадык. Бәдретдин әйтә, моны башкортларда «кияү камчысы» дип йөртәләр, ди, чөнки очындагы менә шушы бөреләре зәңгәр чәчәк булып ачылгач, ул чынлап та чуклы камчыга охшап китә, ди.

Ә безнең Гыйлемдар, озын сыйрак, гел йомран эзләп чапты, туктап, ике учын кушлап сызгырып та карады, ләкин хәйләкәр җәнлек шәкерт сызгырганын сизә иде, ахрысы, оясыннан чыгып, колакларын торгызып, арт тәпиләренә утырмады.

...Юл буе безне тургайлар сайравы озатып барды. Гүя менә төпсез нурлы күктән өстебезгә сихри бер моң тибрәнепчыңлап, өзлексез явып торды. Ә беләсезме, тургай сайравының сихере нәрсәдә?.. Иң элек, сынаганыгыз бардыр, тургай сайраганда җир өстенә җиңелчә генә уйчан-моңсу бер тынлык

җәелә. Әйтерсең барлык табигать, барлык җан иясе, әдипләр әйткәнчә, сөкүт калып, тәмам мөкиббән китеп, бары аны гына тыңлый, аны тыңлап сөенечле, сагышлы, ләззәтле бер рәхәткә чума... Икенче сихере шунда ки, тургай сайраганда дөнья ничектер искиткеч җәелеп, киңәеп, яктырып киткәндәй була. Әнә шул югарыда кечкенә кошчык талпынган күкнең үзе шикелле үк, җир йөзе дә иксез-чиксез булып, гаҗәеп тын, нурлы булып тоела башлый...

Белмим, бу вакытта бүтән кошлар сайрый торгандырмы,— игътибар иткәнем юк, әмма бер кошның тавышы, бөтен җир өсте тургайлар сайравыннан өзлексез чыңлап торса да, безне сискәндереп, колагыбызга килеп керә. Бу — кәккүк! Табигать тарафыннан кешеләрнең исләренә ниндидер бик мөһим бернәрсәне төшерер өчен яратылган күзгә күренмәс сәер кош!.. Юлдан шактый читтә торган күксел урман яныннан узганда, без аның да тынып калырга мәҗбүр иткән кисәтүле тавышын ишеттек.

Шулай кәефләнеп, күңелле генә кайта торгач, без, ниһаять, кызыл ярлы тауларга каршы тигез үзәнлектә сузылып утырган Ишле авылына да якынлаштык. Юлга чыккач та, Бәдретдин безне, Ишледә туктап, чәй эчеп чыгарга чакырган иде. Без, билгеле, кыстатып тормадык, шәриктәшенә кереп, чәй эчеп, күңел ачып чыгу — шәкертләр өчен табигый бер низам инде ул.

Авылга җиткәндә генә Бәдретдин дилбегәне үзенә алып, атны олы юлдан уңга каерды да бәбкә үләне түшәлгән җир өстеннән генә иң арткы урамга таба алып китте, һәм озак та үтми, шул урамның иң читендәге, бүтән йортлардан аерылыбрак, ялгызы гына торган бер өйнең каршысына безне китереп тә туктатты.

Без фәкыйрь кешеләргә керәсебезне белеп килә идек, әмма бу кадәр ярлы хуҗалыкны күрербез дип һич тә көтмәгән идек. Хәер, моның хуҗалык дип атар җире дә юк иде. Шыр кырда утырган бәләкәй генә ялгыз өй үзе искереп-тузып, яртылаш җиргә кереп беткән. Салам түбәсе череп, каралып, тирескә әйләнә башлаган. Әйтерсең шуның авырлыгыннан өйнең кайбер бүрәнәләре бүселеп чыккан, ишек-тәрәзәләре кыйшайган, ә тәрәзә пыялалары тора-тора инде яшькелт-зәңгәр төскә кергән... Капка юк, койма юк, тик урам яклап та кыр яклап кына ике рәт киртә сузылган... Ишегалдын кыр үләне басып киткән. Анда чикерткәләр тыз-быз сикерешәләр. Димәк, бернинди аяклы мал да юк.

Без инде хәйран булып, гаҗәпләнеп калуыбызны Бәдретдиннең үзенә ничек тә сиздермәскә тырыштык. Арба эзе төшмәгән ачык ишегалдына узып, түбәсе чыбык-чабыклар белән ябылган иске генә бер читән абзар алдында атыбызны туктаттык. Өйдән кечерәк буйлы, ак чырайлы, җирән сакаллы, арык-өшән генә бер абзый чыкты. Аның өстендә киндер күлмәк, тез башларына зур ямаулар салынган киҗеле ыштан, башында мескен бүрек, аякларында тула оек белән тузган чабаталар иде. Ул тарантас янына килеп, бары: «Улым!»—дип кенә Бәдретдин белән күреште, аннары безгә дә шулай сүзсез генә ике кулын сузды һәм шунда ук ат башына барып, аны тугара да башлады...

Бәдретдин, сандыгын күтәреп, өйгә ашыкты. Өй ишегендә бер хатын күренде, ләкин ул ни өчендер тиз генә кире борылды. Бу Бәдретдиннең әнисе булгандыр инде, тик менә аның ишектән чыгар-чыкмас кире чигенүе безне бераз гаҗәпләндерде.

Атны тугарып бетүгә, Бәдретдин өйдән чиләк белән су, чүмеч һәм тастымал күтәреп чыкты. Чирәм өстендә генә чиләктән бер-беребезгә су коеп юынып алдык. Күңелгә: «Комганнары да юк, күрәсең» дигән уй килде. Һәм без бернәрсә күрмәгән, белмәгән булып кыланырга яки ваемсыз гына сөйләнергә ничектер сүз дә, сәләт тә таба алмый идек. Ләкин Бәдретдин үзе тыныч иде, һәрхәлдә, оялу-уңайсызлану кебек бернәрсә дә сиздерми иде.

Юынып беткәч, сәлам биреп, өйгә кердек. Бәдретдиннең әтисе, бер читтәрәк торган килеш, безне бик гади генә: «Әйдәгез, шәкертләр!» — дип каршы алды.

Караңгырак кына өй эче дә тышкы ягы кебек үк искереп, тузып беткән икән инде. Ләкин күпме генә искереп-тузып бетмәсен, аның бүрәнәләре тома балавыздай сары-көрән иде әле, тапталып, кырылып ашалган идәне дә чип-чиста иде... Өйнең бөтен түрен иңләп, өстенә киез җәелгән зур сәке тора, ике урындык, бер эскәмия, мич буенда тагын бер бүкән тора,— менә җиһаз дигәне бары шул гына. Мич алды иске генә чүпрәк чаршау белән бүленгән, анда кемнеңдер озын гына итеп чыра телүе ишетелә.

Өйгә кергәч тә безнең иң элек күргән кешебез сәке түрендә, стенага терәлеп, текә генә утырган бер бабай булды. Бабай Хозыр Ильяс төсле ап-ак сакаллы, ап-ак күлмәк-ыштаннан иде. Бары тик башындагы беленгә әйләнгән түбәтәе генә аның күксел-кара иде.

Без бабайга күрешер өчен кулларыбызны суздык. Бабай селкенмәде. Бәдретдин ашыгып әйтеп куйды:

— Бабакай, шәкертләр синең белән күрешергә телиләр.

— Ә, шулаймыни, бәрәкалла!— диде бабай аз гына җанланып һәм безгә кипкән, зур, каты кулларын сузды. Күзләре ачык булса да, ул дөм-сукыр иде.

Без утырышып дога кылдык һәм, шәкертләрчә кулларыбызны тез өстенә куеп, бермәлгә тынып калдык. Безнең үзебезгә сүз башлавы, билгеле, кыенрак иде, аннары нидер менә телебезне һаман бәйләп тора иде. Ләкин, гаҗәп хәл, хуҗалар үзләре дә сүзсезләр иде. Гомумән, бу өйдә сүз бик аз сөйләнә булса кирәк,— ничектер бик тиз без шуны сизгәндәй булдык. Бабай, үзенең эчке дөньясына киткәндәй, текә каткан килеш, тып-тын утыра. Бәдретдин әрле-бирле йөренә, нидер әйтмәкче дә шикелле, ләкин сүз таба алмый кебек... Әтисе башта мич буендагы бүкәндә безгә бераз шаккатып утырды да, аннары торып, сәке кырыена чәй урыны әзерли башлады. Иске генә киҗеле ашъяулык китереп җәйде, мич кашагасыннан кайсы замазка белән ябыштырылган, кайсының сабы кителеп төшкән өч кенә чынаяк алып куйды, кыска гына чалгы пычагы, чүпрәккә төргән ярты ипи, тустаган белән сөт китереп куйды. Шуннан соң тагын бүкәненә барып утырды. Бәдретдин үзенең сандыгыннан бер-ике уч шикәр алып, шуны ашъяулык уртасына салды.

Бераздан чаршау эченнән әкрен генә: «Булды, улым!» дигән сүз ишетелде. Бәдретдин, кереп, самоварны алып чыкты. Бу самоварның да борын һәм колак төпләре кургашын белән ямалып беткән иде.

Бәдретдин безгә сәкегә менеп утырырга кушты. Без, менеп, аякларны бөкләп утырдык. Шуннан соң алдыбызга өчаяк белән йомырка тәбәсе килде. Без әле, ашка сузылмыйча, хуҗаларның утырганын көтә идек. Ләкин бабай да урыныннан кузгалмады, абзый кеше дә бүкәненнән тормады. Шул чагында Бәдретдин йомшак кына чаршау эченә дәште:

— Әнкәй, чәй ясарга үзең чык инде.

— Әткәң соң?— диде чаршау эченнән әнисе акрын гына.

— Әткәйме?.. Юк, син үзең яса инде безгә,— диде Бәдретдин, ничектер бик ихластан үтенгәндәй итеп.

Чаршау эче бераз тынып торды, аннары киндер күлмәк өстеннән шундый ук киндер алъяпкыч бугаң, оек-чабаталы хатын, ситсы яулыгының читләрен битенә тартып һәм башын иеп кенә чыкты да самовар артынарак килеп утырды.

Аңа күтәрелеп карагач та, минем йөрәк әллә нишләп китте. Дөресрәге, яшермичә әйтим, бер чиркану тойгысы йөрәкне өшетеп җибәргәндәй булды: бичара хатынның бөтен битенкүзен кайчандыр кичергән рәхимсез чәчәк зәхмәте тәмам бозып бетергән иде. Өстенә карап, моны сурәтләп торуы авыр, ничектер тел бармый, ләкин шулай да сул күзенең бөтенләй кысылып, ә уң күзенең иләмсез зураеп калуын әйтмичә булдыра алмыйм, чөнки шушы яшь пәрдәсе аша караган кашсыз-керфексез күзендә бичараның бөтен эчке җаны чагылырга гына тора кебек иде. Әйтерсең бу һич йомылмас яшьле-моңсу күз — аның шәрәләнеп калган бердәнбер күңел көзгесе!

Аны күреп беренче чиркану һәм кызгану тойгысын кичергәч тә, күңелгә иң башлап шундый уй килде: ничек итеп Бәдретдин бу бәхетсез әнисен чакырып алырга һәм безгә күрсәтергә җөрьәт итте икән?.. Без бит гадәттә кешене куркытырлык ямьсез яки гарип туганнарыбызны ятлар күзенә күрсәтмәскә тырышабыз. Хәтта әниебезне дә, әгәр ул менә шушындый булса, үзебез чакырып алып күрсәтергә кыймас идек, уңайсызланыр идек, оялыр идек. Бәдретдин бу кыен хәлне бөтенләй күрми, аңламый микәнни? Әллә күрсә, аңласа да, бик тирән яшерә беләме?

Ә җиңги шул арада чынаякларга чәй ясап, йөзен самовар артына яшерә төшеп, безгә сузды. Без башларны күтәрмичә генә, сүзсез генә чәебезне эчәргә тотындык. Бәдретдин, безне кыстап:

— Ягез әле, шәрикләр, ни бары белән ашап кына эчегез, ашап кына! — диде, һәм аның тавышында мин көткән уңайсызлану яки оялу ник кенә бер ишетелсә иде!

Йомырка тәбәсен капкалап, икешәр чынаяк чәй эчкәч, без чәшкеләребезне каплдык. Бәдретдин, сыеның ярлылыгыннан булса кирәк, үз алдына, сиздермәскә тырышып кына, бер сулап куйды. Аннары кисәк кенә аягүрә басты да:

— Булмаса, мин сезгә үземнең китапларымны күрсәтим әле,— диде һәм тәрәзә башына ясаган кечкенә шүрлектән бер өем китапларын алып безгә бирде. Без, бер эш чыкканга куанып, шуларны карый башладык. Монда яңа әдәбияттан ике-өч роман, дүрт-биш шигырьләр мәҗмугасы, иске әдәбияттан шактый тузган «Бүз егет», «Тутыйнамә», «Ләйлә вә Мәҗнүн», «Каһарман Катыйль» кебек китаплар һәм гарәп, фарсы телендә берничә дәреслекләр бар иде. Без күбрәк вакыт үтсен

Л. Ә. Фәттахов. Бәләкәй Тукай.



Габдулла Тукайның «Исемдә калганнар» әсәренә иллюстрация. Авторы — рәссам *Байназар Әлменов.*



Габдулла Тукайның «Шүрәле» шигыренә иллюстрация. Авторы — рәссам *Байназар Әлменов.*

Әмирхан Еникинең «Кем жырлады?» әсәренә иллюстрация.
Авторы — рәссам *Максим Покалев.*

өченгә бу китапларның кайсы укылган, кайсысы укылмаган, кызыкмы-түгелме,— шул турыда сөйләшкәләп карап чыктык.

— Минем бит әле сезгә, шәрикләр, тагын бер күрсәтәсе нәрсәм бар,— диде Бәдретдин һәм, яңадан торып, шүрлектән кечкенә генә скрипка алды. Бу кулдан гына ясалган, буялмаган, хөрти генә бер скрипка иде. Без гаҗәпләнеп сорадык:

— Кайдан бу синдә?

— Үзем мәтәштергән булдым инде,— диде Бәдретдин һәм скрипкәнең тоныкына тавыш чыгарган кылларын көйләргә тотынды. Аның кубыз уйнавын, мандолина чиртеләвен без белә идек. Әмма скрипкә!..

— Әй Бәдри, нигә моңарчы яшердең? — дидек без.— Мәдрәсәдә Сәгыйть скрипкәсен алып, үзеңнән уйнаткан булыр идек бит!

— Оста барда кулың тый! — диде Бәдретдин, тыйнак кына елмаеп. Ул айлар буе кул тимичә яткан скрипкәсен шактый озак азапланып көйләде. Шул чакта мин аның әнисенә күтәрелеп карадым: ана үзенең шәкерт улына шундый бер бәгырьгә төшәрлек тирән мәхәббәт белән, бәхет-сөенеч белән сихерләнеп, эреп, мөкиббән китеп карап утыра иде ки, мин хәтта йөрәгем-тәнем белән әллә ничек тетрәнеп куйгандай булдым. Аңлыйсызмы, күз алдыгызга китерә аласызмы,— гүя бу зураеп ачылган сыңар күздәге сихри карашта бер адәм затына гына түгел, бөтен җан иясенә хас ниндидер менә үзе эшләгән могҗизага таң калу һәм шуңа чиксез куану, шуның белән әйтеп бетергесез горурлану ап-ачык чагылып тора иде: ул тапкан бит бу баланы! Ул имезгән бит аңа күкрәк сөтен! Ул шушы сөлек кебек егетнең әнисе бит! Шәкерт әнисе, гыйлем иясе булачак кешенең әнисе... Ихтыярсыздан йөрәгем үксi башлап, мин тизрәк башымны түбән идем.

Бәдретдин, маташа торгач, ахырда скрипкәсен көйләде, иңбашына терәде, җәя сыман смычогы белән сызгаларга тотынды. Скрипкәнең тавышы бик зәгыйфь иде, чеби тавышыдай көчсез-нечкә иде, ләкин бу минутта безнең күңелләргә ул да бик ягымлы, бик тансык иде. Бәдретдиннең уйнавын барыбыз да шылт та итмичә, тып-тын калып тыңлап утырдык. Бу ярлы өйнең һавасында ук ниндидер бер авыр сагышлы моң — мәңгелек моң йөзә кебек иде. Текә генә катып утырган ап-ак бабай ни уйлый, бүкәне өстеннән бер генә дә кузгалмаган абзый кеше ни кичерә,— моны белүе һич мөмкин түгел иде. Тик шушы моң эчендә, томан аша караган тулы ай төсле,

Бәдретдиннең әнисе үзенең сүзсез шатлыгы белән яктырып утыра. Нинди язмышлар бәйләгән бу кешеләрне, нинди серләр саклана алар арасында?

Бер-ике көй уйнагач, Бәдретдин, ниһаять, әнисенә дәште:

— Әнкәй, сиңа нәрсә уйныйм?

Әнисе бер мәлгә балаларча кызарып, шул ук вакытта куанычыннан тагы да балкыбрак китте, ләкин кайтарып сүз әйтә алмады.

— Әнкәй, син шушы көйне ярата идең бит! — диде Бәдретдин һәм «Салкын чишмә» көен уйный башлады. Аның сүзләре, сүзләреннән дә бигрәк, шулкадәр гади, табигый, җылы-якын итеп дәшүе минем соңгы шикләремне дә чәлпәрәмә китерде. Әнисе өчен уңайсызлану дигән нәрсәнең әсәре дә юк икән Бәдретдиндә!.. Кайда ул уңайсызлану! Берәүне дә күрмичә, бары әнисенә, әнисенең әнә шул башта безне чирканырга мәҗбүр иткән шадра, чалыш, акайган күзле йөзенә генә карап, ул скрипкәсен уйнады. Аның бу аз гына моңсу уйчанлык, яшерен генә кызгану белән өртелгән җитди-җылы карашында әнисен өзелеп ярату гына түгел, аны беткәнче аңлау, кадерләү, юату сизелеп тора кебек иде. Белмим, болай карый алыр өчен күңелләрдә нинди генә тирән мәхәббәт дәрьясы ятарга тиештер инде?! Әллә бу шулай бик ямьсез ана белән бик матур бала яки, киресенчә, бик матур ана белән бик ямьсез бала арасында гына буламы икән? Соңгысы, ихтимал, еш очрый торгандыр, әмма беренчесен ишеткән дә, күргән дә юк иде.

Шулай да безгә кузгалырга вакыт иде инде. Бәдретдин уйнап туктагач, без хуҗалардан дога кылырга рөхсәт сорадык. Абзый кеше ямаулы тез башларын ышкып куйды, ә Бәдретдин, бабасына үрелеп:

— Бабакай, шәкертләр бездән фатиха бирүебезне сорыйлар,— диде. Бабай башын какты, һәм без кулларны күтәрдек.

...Күк алашаны җигеп, капкасыз-коймасыз, кыр үләне басып киткән «ишегалды»ннан урам уртасындагы тигез юлга чыктык. Бәдретдин һәм әтисе безне озатып, киртә буенда янәшә басып калдылар. Юк, алай гына түгел, алар белән бергә безнең артта авыл читендәге иң фәкыйрь йорт, бу йортның безгә билгесез нindидер тирән сере,— бәхетсезлегеме, фаҗигасеме, әллә без аңлаудан гаҗиз бөек бер өмете-бәхетеме,— торып калды.

Кояш баюга таба борылган иде инде. Ә шулай да тургайлар, көн яктысыннан туя белмәгәндәй, тагын да биеккәрәк менеп,

тагын да сузыбрак, ярсыбрак берөзлексез сайрыйлар да сайрыйлар. Дөнья киң, киң, киң, әләләләләүү! Җире-күге тын, буш, моңсу... бик моңсу миңа!.. Берни эшли алмыйм үзем белән: самовар артыннан гына улына карап утырган ана күз алдыма килә дә эчемнән тагын үкси башлыйм... Кемгәдер йодрык селкеп кычкырасым килә: ямьсез түгел бит ул, матур бит ул, матур, матур Бәдретдиннең әнисе!

Сораулар һәм биремнәр.

1. Хикәядә вакыйга кайсы чорда бара, һәм автор ул дәверне ничек бәяли?
2. Әсәрдә Бәдретдингә нинди характеристика бирелә?
3. Үзәк геройның авылдагы йорт-хуҗалыгын тасвирлап бирегез.
4. Ананың тышкы кыяфәте беренче күрүдә ничек сурәтләнә һәм нинди тәэсир калдыра?
5. Бәдретдиннең скрипкада уйнавы тыңлаучыларга ничек тәэсир итә?
6. Бәдретдиннең әнисенә мөнәсәбәтен үз сүзләрегез белән сөйләп бирегез.
7. Хикәядә нинди матурлык турында сүз бара? Шул хакта әңгәмә корыгыз.

Рафаил Төхфәтуллин
(1924—1994)

Рафаил Төхфәтуллин 1924 елның 1 гыйнварында Татарстанның Арча районы Яңа Иябаш авылында туа. Шул ук районның Яңа Кенәр мәктәбендә укыганнан соң, Донбасска китеп, шахтер һөнәрен үзләштерә һәм бераз вакыт шахтада эшли.

1942 елның август аенда сугышка китә һәм 1945 елның гыйнварына кадәр фронтта була. Берничә тапкыр авыр яралана, контузия ала. Сугыштан кайткач, Яңа Кенәрдә чыккан «Кызыл юл» район газетасында эшли, 1957—1959 елларда Мәскәүдә Югары әдәби курсларда укый.

1948 елда «Кызыл Татарстан» газетасында Рафаил Төхфәтуллинның «Сабакташлар» исемле беренче хикәясе басыла. Шул вакыттан башлап ул иҗат эшенә керешә.

Үзе авылда туып үскәнгәдер, Р. Төхфәтуллин иҗатының шактый өлеше авыл темасына багышланган. Язучыны күбрәк сугыш һәм аннан соңгы чордагы авылның яшәеше кызыксындыра. Әсәрләрендә ул авыл тормышының төрле якларына игътибар итеп, аларны белеп, нечкәләп тасвирлавы белән аерылып тора. «Авылдашым Нәби», «Йолдызым», «Тамчылар ни сөйли» повестьлары әдип иҗатының гына түгел, гомумән шул еллар татар прозасының, алсу төсләрдән арынып, тормыш чынбарлыгын ачу юнәлешендә үсүен күрсәткән әсәрләр булдылар.

1959 елда Рафаил Төхфәтуллин Әлмәт шәһәренә күчеп килә һәм илһамланып иҗат эшенә керешә, нефтьчеләр тормышы һәм хезмәтенә багышланган әсәрләр яза, шулай ук авыл

турында язуын дәвам итә. Алар арасында «Җиләкле аланнар», «Китә казлар», «Акбүз ат» һ.б. авыл дөньясын лирик-фәлсәфи планда яктырткан повестьлары бар.

БАЛАМ КӨЛҮЕ

(Нәсер)

Саф-саф агачлы, мул чәчәкле бульвар. Бульварда бала-чага. Уйныйлар, көләләр, шаяралар.

Әнә чем-кара күзле, түп-түгәрәк йөзле бер малай бабасы белән куышып уйный. Томырылып та чаба малай, дөп-дөп итеп, җир селкетеп чаба. Үзе чырык-чырык көлә, көлгәндә күзләреннән чын-чын шатлык нурлары, эчкерсез куаныч очкыннары сибелә аның.

Их шаян дустым, шулкадәр дә минем улыма охшатып көләрсең икән! Минем дә бит менә нәкъ синең күк шук, синдәй җитез улым бар. Каячы, тотып алып, улым кебек итеп тупылдатып бер сөйим әле үзеңне! Тоттырмыйсың, чабасың? Улымны никадәр дә сагынганлыгымны белмисеңдер шул син... Рәхмәт инде, әнә шулай улымның шат көлүен ишеттергәнең өчен дә бик зур рәхмәт!

Чү, әнә арырак бер бала елый түгелме? Елый... Әнисе кызчыгын кулында тирбәтә-тирбәтә йөренә, бик ягымлы юату сүзләре дә сөйли, ә бала һаман елый. Әй, кара инде, шулкадәр дә минем кызыма охшатып елый бит. Кызымның әнә шундый да матур итеп елаганын моңа тикле белми йөргәнмен ләбаса...

— И үскәнем, шулай елап торалармыни... Карале, менә минем нинди тәтием бар, үзе келт-келт итә. Тыңлале. Менә шулай. И-и-и, еламый ич ул, көлә генә. Әнә көлә, әнә...

Кызчыкка ят абыйның сүзләре, аннан да бигрәк кулына бәйләгән келт-келт итә торган ялтыравыклы тәтие ошап китте булса кирәк, ул акрынлап елавыннан туктады. Нәни кулларын келт-келт итә торган ялтыравыклы тәтигә сузды.

— Һай син, усал кыз!

Усал кыз яшь аралаш көлеп җибәрде.

Әнисе дә шатланып көлде.

Мин дә рәхәтләнеп бер көлдем.

Көл син, кызчыгым, көл! Шулай үз дигәнеңне даулап матур итеп кенә елап ал да, май яңгыры артыннан ук балкыган кояш күк саф, нурлы итеп көл!

Син дә, шаян малай, шулай җир селкетеп йөгер, шаяр, көл!

Менә хезмәт командировкам бетәр дә, мин дә улым, кызым янына кайтырмын. Аерылышулар булмаса, шатлыклы очрашулар да булмас иде, диләр бит шагыйрьләр. Шулай икән шул. Мин улымны бер теземә, кызымны икенче теземә утыртып сөярмен, алар тагын да матуррак, тагын да нурлырак, тагын да сөйкемлерәк итеп көләрләр.

Булсын, хезмәтебез таләп итә икән, әйдә, була бирсен мондый аерылышулар. Алар улымның шат көлүен, кызымның саф нурлы елмаюын тагын да тансыграк, тагын да якынрак кына итә бит миңа.

Булсын, әйдә була бирсен мондый шатлыклы очрашулар көтә торган аерылышулар!

Әмма...

Без башка төрле аерылышуларны да яхшы хәтерлибез.

Минем абыем да Мәскәү яны окопларында ятканда үзенең кечкенә улын, нәни кызын өзелеп сагынгандыр. Үлемнең күзенә туры карап атакага күтәрелгәндә, улының шат көлүен, кызының ягымлы елмаюын хәтереннән кичергәндер.

Мин яшь солдат идем әле.

Өйләр урынына җимерек морҗалар гына тырпаеп утырган кара сөремле украин авыллары аша узганда күргән кайнар көлне актарып, нәрсәдер эзләп йөрүче балаларны мәңге онытасым юк.

Алар көлмиләр иде.

Сугышлар бетте. Абыемның улы белән кызы мине шатланып каршыладылар.

Ләкин... Көлмәделәр.

Абыем Берлин урамнарында, Рейхстаг башына кызыл әләм кадаудан ике генә сәгать элек, мәңгегә күзләрен йомды...

...Әйе, хезмәтебез таләп итә икән, әйдә, була бирсен алар, алда шатлыклы очрашулар көтә торган аерылышулар!

Әмма абыем аерылышуы кебек аерылышулар булмасын!

Бетсен!

Мәңгегә онытылсын!

Хәзер инде абыйның олы кызы үзе әни кеше.

Аның улы да бик матур итеп көлә.

Минем балаларым да бик матур итеп көләләр.

Әнә бульвар тулы бала-чага шау килеп көлә.

Көлегез, шаулатып, яңгыратып, дөньясын ямьләндереп көлегез сез, балалар!

Без инде бу көлүне туктатырга, шат көлү көтми торган аерылышуларга юл куймабыз!

Юк, юл куймабыз!

Сораулар һәм биремнәр.

1. Р. Төхфәтуллинның тормыш юлы һәм иҗаты турында сөйләгез.
2. Нәсерне эчтәлеге буенча нинди өлешләргә бүләргә була? Алар арасындагы охшашлык һәм аерманы ачыклагыз.
3. Ата-ана һәм бала хисләре әсәрдә ничек чагыла? Тексттан шул урыннарны табып укыгыз.
4. Язучының әсәрдә әйтергә теләгән фикерен үз сүзләрегез белән сөйләп бирегез. Шул хакта әңгәмә корыгыз.
5. *Саф-саф, бала-чага, чем-кара, түп-түгәрәк, дөп-дөп, чын-чын, чырык-чырык, тирбәтә-тирбәтә, келт-келт* сүзләре ясалышлары буенча нинди төркемгә керәләр? Аларның язылышларына игътибар итегез, мәгънәләре буенча аңлатма бирегез.

Гөлшат Зәйнашева
(1928—2005)

Гөлшат Зәйнашева 1928 елның 13 гыйнварында Татарстанның Сарман районы Иске Теләнче авылында туган. Балачагы Минзәлә районының Югары Тәкермән авылында уза. Шунда башлангыч, Хуҗамәт авылында җидееллык мәктәпне, аннары Минзәлә педагогия училищесын тәмамлый. 1945—1949 елларда Казан дәүләт педагогия институтының татар теле һәм әдәбияты бүлегендә укый. Аны тәмамлагач, Татарстан китап нәшриятының матур әдәбият редакциясендә редактор булып эшли. Беренче шигырьләре, җырлары, эстрада өчен пьесалары илленче елларда ук көндәлек матбугатта һәм «Күңелле сәхнә», «Мәктәп сәхнәсе», «Эстрада», «Клуб сәхнәсе» кебек күмәк җыентыкларда басыла. 1958 елда «Тыңларсыңмы җырларымны» исеме белән лирик шигырьләре тупланган беренче китабы дөнья күрә. Аның «Рамай» исемле пьесасы буенча куелган спектакльләр халык театрлары сәхнәсендә зур уңыш белән бара.

Г. Зәйнашева — әдәбиятның төрле жанрларына караган ике дистәдән артык китап авторы. Аның шигырьләренә иҗат ителгән «Туган җирем — Татарстан» (А. Ключарев музыкасы), «Китмә, сандугач» (Р. Яхин музыкасы), «Минәргә иде Урал тауларына» (М. Мозаффаров музыкасы), «Үз илемдә» (С. Садыйкова музыкасы), «Кояш гомере» (Ф. Әхмәдиев музыкасы) кебек җырлар татар җыр сәнгатенең үзенчәлекле бер сәхифәсен тәшкил итәләр. Иң популяр җырлары тупланган «Илле җыр» (1988) исемле китабы өчен Г. Зәйнашева 1991 елда Татарстан Республикасының Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләгенә лаек булды.

ТУГАН ҖИРЕМ — ТАТАРСТАН

Г. Зәйнашева шигыре *А. Ключарев* музыкасы

Идел ярларына нурлар сибеп,
Матур булып ата бездә таң.
Таң шикелле якты Туган илем,
Бәхет биргән җирем — Татарстан.

Кушымта:

Кая гына китеп,
Кайларга бармадым,
Сагынып кайттым Иделем таңнарын.

Биш диңгезгә карап елмайгандай,
Балкый безнең Казан ерактан.
Коры җирне шаулы диңгез итә
Хезмәт сөйгән халкың, Татарстан.

Кушымта.

Күпме җырлар җырлый халкым бүген,
Туган җирем, синең турында.
Мин бәхетле, сине сөюемне
Әйтә алсам шушы җырымда.

Кушымта:

Кая гына китеп,
Кайларга бармадым,
Сагынып кайттым Иделем таңнарын.

Сораулар һәм биремнәр.

1. Шигырьдән туган якны ярату турында язылган юлларны табып укыгыз.
2. Шигырьдәге чагыштыруларны табып, дәфтәрегезгә язып куегыз.
3. Шигырьне яттан өйрәнегез.
4. Гөлшат Зәйнашева сүзләренә язылган нинди җырларны беләсез? Шул турыда фикер алышыгыз һәм аның җырларын туплап, әдәбият дәфтәрегезгә язып куегыз.
5. «Г. Зәйнашева шигырьләренә иҗат ителгән җырлар» дигән темага әдәби кичә уздырыгыз.

6. **Түбәндәге өзекләрне сәнгатьле итеп укыгыз, үзара фикер алышыгыз һәм русчага тәрҗемә итегез. Әлеге сүзләр татарча һәм русча ничек яңгырыйлар, аерма бармы?**

Кошлар сайрый тирәктә,
Сыгылып үсә таллары.
Кайда йөрсәм дә йөрәктә
Татарстан таңнары.

(Г. Афзал)

Азат та син,
Гүзәл дә син,
Әй туган җирем.
Күкрәп яшә, Татарстан,
Җөмһүриятем минем!

(Н. Арсланов)

Бу дөньяда мин бер ятим түгел,
Горурлыкта тулы хакым бар:
Тигезләргә мине тигез иткән
Республикам, туган халкым бар.

(Н. Хисамов)

Фәрит Иделле

(1943 елда туган)

Җир шарында татарлар яшәмәгән төбәкне табуы кыен. Татарлар — дөньядагы иң күп таралып яшәгән халыкларның берсе. Әмма язмыш кая гына илтеп ташласа да, татар халкы, хезмәт сөюе һәм тырышлыгы аркасында, беркайда да югалып калмаган, һәр җирдә төрле һөнәрләр үзләштереп, тернәкләнеп китә алган.

Без, татарның тарихи Ватанында яшәүчеләр, озак вакытлар әлеге мөһаҗир милләттәшләребез турында бик аз белдек яки бөтенләй хәбәрдар түгел идек. Бары узган гасырның сиксәненче еллары ахырында гына читтәге татарлар белән аралашу мөмкинлеге туды. Яңа шартларда алар белән бәйләнешләр булдыруда һәм ныгытуда Бөтендөнья татар конгрессы зур роль уйнады. Конгресс уздырган корылтайлар Җир шарына сибелеп яшәгән татарларны очраштыру һәм берләштерү, дуслаштыру чарасына әверелде. Шушындый очрашулар вакытында без дә читтәге милләттәшләребез белән якыннанрак таныштык, аларның гыйбрәтле язмышлары турында белдек.

Шуларның берсе — танылган журналист Фәрит Иделле (Аги Фәрит Әмруллаһ улы). Ул 1943 елда Кытайда татар гаиләсендә (бирегә язмыш аларны Пенза якларыннан китереп ташлаган) дөньяга килә. Алга таба бу гаиләнең язмышы драматик төс ала. Фәритнең берничә кыз туганы бик яшьли вафат булалар. Әтисе Әмруллаһны милләтчелектә гаепләп кулга алалар һәм ул 20 ел гомерен Себердә сөргендә үткәрә. Озакламый Фәрит, әнисе Шәмсинурдан аерылып, Төркиягә күчеп китәргә мәҗбүр була. 1968 елдан ул «Азатлык» радиостанциясенең татар-башкорт редакциясендә эшли башлый, журналистикадан тыш фәнни эшчәнлек белән дә шөгыльләнә. 1972 елда Истанбулда аның «Казакъ һәм татарлар» дигән китабы дөнья күрә.

ӨЗЕЛГӘН ҮЗӘКЛӘР, САРКЫЛГАН ЙӨРӘКЛӘР...

(Өзекләр)

Күз алдымда ап-ак кәгазь. Нәрсәдән башларга микән соң? Уй-фикерләр, талдан талга очып йөргән кошлар кебек, бер темадан икенчесенә күчә. Нәрсә турында язарга, нәрсә әйтергә; нәрсә, нәрсә, нәрсә..?

Дулкынланам, йөрәк ешрак тибә. Катлаулы тормыш. Әтиемне кулга алган көн... Мәктәп еллары... Мөһаҗир юллары... Казанны беренче тапкыр күрү...

Боларның һәммәсе үзе бер повесть, үзе бер роман.

Тукта әле, ни өчен башымда кайнаган фикерләрне тасвирламаска, йөрәгемне сызлаткан хисләр турында язмаска?! Бәлки, шул төрле-төрле мозаикалардан ниндидер бер рәсем барлыкка килер. Бәлки, ул укучыга болын чәчәкләреннән җыелган бер букет сыман күренеп, аның да тойгыларын уятыр?!

Шул ук вакытта бу язма роман да, документаль автобиографик әсәр дә түгел. Болар бары тик төрле уйланулар гына...

Кеше язмышы Хак Тәгалә кулында. Һәм шул язмыштан узмыш юк.

Без кем соң? Һәм кайдан?

Әтине сабый бала чагында, революциядән соң берничә ел үткәч, әнисе һәм үзеннән кечерәк өч сеңлесе белән Пензаның Нопар авылыннан ерак Кытайга алып китәләр. Авыр һәм михнәтле юллар, катлаулы сәяхәт. Хәзерге кебек, очкычка яисә поездга утырдың да киттең түгел бит. Мәрхүмә әбиемнең батырлыгын, тәвәккәллеген ничек аңлатырсың? Туган телдән гайре тел белмәгән авыл хатын-кызы, «ирем чакыра» дип, дүрт сабый баласын ала да меңнәрчә чакрымлык юлга чыга. Бар байлыгы: бер чемодан да самавыр. Ни өчен бабам әбиемне Кытайга чакырган соң? Сәүдә белән Ерак Көнчыгышка барып-кайтып йөргән бабам, чикләр ябылгач, хатынын үз янына чакырта. Юлга чыгалар, әйтеп бетергесез михнәтләрдән соң Благовещенск каласына барып җитәләр. Аннан Кытайга үтәләр. Яңа тормыш кору кайда да җиңел түгел бит. Әмма татарга хас тырышлык ярдәм итә. Кул сызганып эшкә керешәләр, җиңелме-авырмы дип тормыйлар. Төрле хезмәттә эшлиләр. Татарлар берләшә башлый. Үзләренә җәмгыять төзергә, мәчет салырга, мәктәп ачарга ниятлиләр. Һәркем кулыннан килгән хәтле ярдәм итә. Шулай итеп, чит илдә татар мәдәниятенең һәм ислам учагының нигезләре салына.

Әнием дә шул ук Пенза якларыннан, Юнә авылыннан шактый хәлле бер гаиләдән. Революция дәһшәте, гражданнар сугышы дигәндәй, һәрнәрсә югала. Инде нишләргә? Әле сабыйлыктан яңа гына чыккан яшь туташны абыйсы Харбин якларына озата. Еллар үтә... Еллар аера. Еллар кавыштыра. Пенза егете Әмруллах белән Пенза кызы Шәмсинурны язмыш ерак Кытайда очраштыра. Романнардагы кебек беренче күреп гашыйк булганнардырмы-юкмы, белмим. Ләкин татар җәмгыятендә очрашып, татар әсәрләрен сәхнәдә уйнап йөргән, милләт өчен җанын җәлләмәгән ике яшь йөрәк озакламый кавышалар, никахлашалар.

Тату гына яшәп, биш бала тудыралар. Әмма беренче ике кыз бала бик яшьли вафат булалар. Газиз балаларын кинәт югалткан ата-ананың кайгы-кичерешләрен кемгә аңлатып, сөйләп торырга! Әле дә хәтерлим: шул авыр көннәрдә әнием Кадер кичендә өзелеп-өзелеп «Сак-Сок» бәетен җырлаган иде. Аларның сөйләгән бер хикәяләре дә онытылмый. «Бер әнинең бердәнбер улы була. Кыз да мәхәббәтен яшерми, тик сынар өчен: «Мин сиңа кияүгә чыгарга риза. Ләкин син мине бөтен кешегә караганда да күбрәк яратырга һәм моны исбат итәргә тиеш. Шуның өчен иртәгә әниеңнең йөрәген алып кил»,— диде. Хәсрәтләнеп, аптырап калган егет, башын иеп, өенә кайта. Инде нишләргә? Бер якта үзен иркәләп, күкрәк сөтен имезеп үстергән газиз әнисе, икенче якта дөньяда бер генә чишмә дә сүндерә алмаслык ялкын белән яраткан кыз. Улының хәсрәтен ана йөрәге сизмиме соң?

«Улым, нәрсәң бар, ни өчен ашаудан-эчүдән тукталдың?» — дип сорый ул, кайгыда улын күргәч. Шунда егет сөйгән ярының коточкыч таләбе турында әйтә. Әнисе, баласын кочып, күз яшьләрен коя-коя: «Ярый, җан кисәгем, сине бәхетле күрү — минем иң изге теләгем. Ал йөрәгемне, илтеп бир сөйгән ярыңа»,— дип ризалыгын бирә. Егет әнисенең йөрәген кисеп ала да кыз янына йөгерә. Вөҗдан газабыннан, әллә ашыкканга күрәме, егет кинәт сөрлегеп китә һәм егыла... Шунда йөрәк телгә килә: «Улым, берәр җиреңне авырттырмадыңмы?..»

Без, балалар, бер-беребезгә күз яшьләребезне күрсәтмәскә тырышып, бу хикәятне үзебезчә аңлый идек кебек. Әмма бу гыйбрәтле хикәянең чын мәгънәсен мин, күрәсең, үсеп җиткәч кенә аңлаганмын. Җырларда, шигырьләрдә, хикәяләрдә меңнәрчә мәртәбә төрлечә тасвирланган мәрхәмәтле, шәфкатьле,

изге әниләр! Сезгә булган бурычыбызны без бервакытта да түли алмабыз, ахрысы. Беләм, әниләр моны көтми дә.

Әйе, язмыш катлаулы. Без — язмыш балалары. Меңнәрчә чакрым ераклыкта туып, Кытайның бер шәһәрендә очрашып өйләнүне Тәңре хикмәтеннән һәм язмыштан гайре нәрсә белән аңлатып була?

* * *

1945 ел. Мин әниемнең кулында, өебезнең икенче катында, тәрәзәдән урамга карыйм. Өй каршында өсте ачык йөк машинасы тора. Анда берничә кеше утырган. Шул чакта өебездән ике кеше әтине алып чыгалар. Ул башын күтәреп өскә карый. Безгә кул болгый. Аны йөк машинасына утырталар һәм алып китәләр. Шушы вакыйга ике яшьлек баланың хәтерендә бик тирән эз калдыра. Мондый фаҗигале хәлләрне безнең гаилә генә түгел, Кытайда яшәүче бик күп татарлар үз башларыннан кичерделәр.

Әтине ни өчен алып киттеләр соң? «Идел-Урал» җәмгыятенең Чан-Чун шәһәре бүлегенең сәркатибе булган, Ерак Көнчыгышта «Яңа милли юл» дигән газета чыгару эшенә катнашканы өчен, дип аңлатканнар. Үз милләтенә хезмәт иткән, аны сөйгән өчен генә дә кеше җинаятьче итеп табыла иде ул дәһшәтле елларда.

1965 ел. Истанбулның очкычлар мәйданы. Әхмәт Вәли Мәнгәр әфәнде, мин һәм абыйларым. Әтине көтәбез. Очкычтан чыккан кешеләргә карап торабыз. Менә тәбәнәк кенә зәгыйфь бер кеше. Тукта, әти бит бу!!! Кочаклашабыз, елашабыз. Күп еллардан соң мин аңа беренче мәртәбә «әти» дип эндәшәм. Бер чемодан, бер аккордеон, кечкенә бер фотоаппарат. 8 ел төрмә, 12 ел Себердә урман кисү — 20 еллык хезмәтнең җимешләре!!!

Һәр көн саен яңа бер бурыч, һәр көн саен бер үк уй-фикер. Тыңлаучы милләттәшләремә нинди информация кирәк? Аларның һәммәсе түгел, әлбәттә, күпчелеге канәгатьме? Милли аңны ничек уятырга? 70 елдан артык сеңдерелеп килгән «татарлар кыргый халык, алар мәдәни яктан артта калган, русча белсәң, шул җитә» дигән карашларның ялгыш булуын ничек аңлатырга? Татарларның олы милләт икәнен, Киев Русеннан да элегрәк үз дәүләтчелеге, борынгы язма әдәбияты булуы белән горурланырга тиеш икәнен ачыктан-ачык бөтен дөньяга җиткерергә иде теләгем.

Ниһаять, зыялылар, халык арасында уяну нык сизелә. Чит илләргә килеп-кайтып йөрүләр ешая... Ватанны күрү өмете үсә. Озак та үтми, чакыру кәгазе дә килә.

Татарстанны, аның башкаласы Казанны күрү мөмкинлеген ычкындырмаска кирәк. Аллага тапшырып, юлга чыгабыз.

Мәскәүдә очкычлар мәйданына килеп төшәбез. Анда мәхшәр. Ике очкыч бер үк вакытта килеп төшкәнлектән, паспорт контроленнән үтү өчен чиратның азагы күренми. Чиратта көтәбез. Рәсми эшләрне тәмамлап, таможнядан үткәннән соң, безне көтеп торган бер төркем кешеләр кочагына эләгәбез. Ниһаять, беренче автомобильгә утырып, Казан вокзалына барып җитәбез. Мәскәүдән поездның кузгалырга берничә минуты калганда гына тагы берничә кеше йөгереп килә, куллары ашамлык-эчемлек белән тулы. Инде баш буталып беткән, исемнәр хәтердә калмый.

Тагын бер онытылмаслык көн — 22 июньдә «Ватан» җәмгыяте тарафыннан оештырылган «Туган тел» бәйрәме. Яңгыр ява, һава да салкынча. Әйтерсең лә табигать татарларны сынамакчы. Анда җыелган милләттәшләребезне яңгыр да, суык та куркыта алмады. Бер-бер артлы чыгыш ясаган зыялыларыбызны, сәнгатькәрләребезне халык көчле алкышлар белән каршы алып озатты. Шулчак йөрәктә зур өмет туды. Димәк, дүрт ярым гасыр иреклектән мәхрүм булып яшәгән, үзенең милли дәүләтчелеге булмаган татар милләте әле югалмаган. Әле мин татар булуым белән горурлана алам икән. Дәреслекләрдә, романнарда, кинофильмнарда тарихны бозып, татарларны кыргыйлар, мәдәниятсез халык дип күрсәтеп, анда түбәнчелек комплексы тәрбияләү нияте әле тормышка ашмаган. Милләтебез яши!!! Аның киләчәге бар. Ләкин бер нәрсә күңелне тырнап куйды: шул урамнарда шуның белән кызыксынмаган кешеләр дә күзгә чалынды. Алар кем? Башка милләт вәкилләреме әллә маңкортлармы? Җавапсыз калган сораулар...

Август азаклары... Испания... Ял вакыты булуга карамастан, нindидер бер тынгысызлык бар. 27 август. Йөгереп берничә герман газетасы алып кайтам. Сәхифәләрне җентекләп актарам. Эзләнгән хәбәр юк. Бу һәр көн саен 1 сентябрьгә чаклы дәвам итә. Менә, ниһаять, 25 битлек газетаның бер почмагында кыска гына хәбәр. «Татарстан үзенең суверенлыгын игълан итте». Аллага шөкер!!! Үзаңлы хыялларыбызның, сәясәтчеләребезнең, милләттәшләребезнең армый-

талмый алып барган көрәше бушка булмады. Милли дәүләтчелегебезне тергезүгә таба беренче адым ясалды...

Халкыбыз, милләтебез чын күңелдән, ихлас рәвештә мөстәкыйль булырга теләгән хәлдә, ул суверенлык юлында барлык киртәләрне җимерә алачак. Моңа һәм милләтемнең якты киләчәгенә минем иманым камил!

михнәтле — авыр, кыен, газаплы, җәфалы
мәрхәмәт — шәфкать, яхшылык, игелек
офык — күкнең җир яки су өсте яссылыгы белән тоташкан сыман булып күренгән сызыгы; горизонт
гайре — башка, бүтән
икътисади — экономик

Сораулар һәм биремнәр.

1. Автор нинди вакыйгалар турында сөйли?
2. Ул ни өчен Татарстан белән горурлана һәм аның киләчәген ничек күз алдына китерә?
3. Әсәр ни өчен «Өзелгән үзәкләр, саркылган йөрәкләр...» дип исемләнгән? Шул юлларны тексттан табып укыгыз.
4. Түбәндәге мәкальләрне укыгыз һәм фикер алышыгыз.

* * *

Дусыннан аерылган җиде ел елар,
Иленнән аерылган гомер буе елар.

* * *

Илнең яме иле белән,
Ватан яме җире белән.

* * *

Халыкка хыянәт — Ватанга хыянәт.

* * *

Илен белмәгән — игелексез,
Халкын белмәгән — холыксыз,
Нәселен белмәгән — нәсәпсез.

* * *

Сыерчык, диңгез артына китсә дә,
Үз туган оясына кайта.

* * *

Болгар йорты — Идел йорт,
Идел эче — имин йорт.
Туган җирдәй җир булмас,
Туган илдәй ил булмас.

ВАТАН КАЙДАН БАШЛАНА?

Ватан турында сөйләшүне шагыйрә Саҗидә Сөләйманованың «Туган җирем, эчкән суым» шигыреннән өзек китерүдән башлыйк:

Туган җир ул кеше күңеленә
Ана сөте белән салына...
Тәпи баскан җирем, эчкән суым
Кара, акмы, ачы, татлымы —
Бөтен гомерем белән түли алмам
Шушы җирдә яшәү хакымны.

Сөйләшү-әңгәмәгә алдан әзерләнегез. Бирелгән сорауларга җавап табарга тырышыгыз.

1. «Ватан» төшенчәсен ничек аңлыйсыз?
2. Ватан кайдан башлана дип уйлыйсыз?
3. Ватанның туган йорттан, туган җирдән, туган яктан башлануын ничек дәлилли аласыз?
4. Безнең уртак Ватаныбыз — Татарстан җөмһүриятенең үткәне, бүгенгесе, киләчәге хакынданиләр беләсез?
5. Ни өчен башка төбәкләрдә яшәүче милләттәшләребез дә Татарстанны үз Ватаннары дип саныйлар? Шул хакта укыганыгыз яки ишеткәнегез бармы?
6. Туган йорт, туган җир, туган як, туган ил турында нинди хикәяләр, шигырьләр укыганыгыз, нинди җырлар тыңлаганыгыз бар? Шул турыда сөйләгез, сөйләмегездә мәкальләр һәм әйтемнәр кулланыгыз.

КАЗАН — БАШКАЛАБЫЗ

Казан — бик борынгы шәһәр. Ул — Татарстан Республикасының башкаласы.

Казанда Ибраһим Хәлфин, Шиһабетдин Мәрҗани, Каюм Насыйри, Хөсәен Фәезханов, Фатих Халиди, Габдрахман Ильяси, Хөсәен Ямашев, Габдулла Тукай, Галимҗан Ибраһимов, Мәҗит Гафури, Мулланур Вахитов, Җамал Вәлиди, Хуҗа Бәдигый, Гыйбад Алпаров, Мирсәет Солтангалиев, Гаяз Исхакый, Шәриф Камал, Галиәсгар Камал, Гыйлем Камай, Салих Сәйдәшев, Заһидулла Яруллин, Фәрит Яруллин, Һади Такташ, Гадел Кутуй, Муса Җәлил, Абдулла Алиш, Фатих Кәрим, Хәсән Туфан, Карл Фукс, Николай Лобачевский, Лев Толстой, Максим Горький кебек күренекле шәхесләр яшәгән һәм иҗат иткән. Без менә шуның өчен дә үзебезнең Казаныбыз белән чиксез горурланабыз.

Сораулар.

1. Сезнең Казан шәһәре турында китаплар укыганыгыз, шәһәр буенча экскурсиядә булганыгыз бармы?
2. Башкаланың урнашкан урыны, табигате хакынданиләр әйтә аласыз?
3. Шәһәрдә сан ягыннан күпме халык һәм кайсы милләт кешеләре яши?
4. Борынгы тарихи шәһәр буларак, Казанның нинди истәлекле урыннарын беләсез? Театр, музей һәм мәчетләргә барганыгыз бармы?
5. Казанда нинди югары уку йортлары бар? Казан университеты турында ниләр беләсез? Анда нинди күренекле кешеләр укыган?

НӘҮРҮЗ

(Язны каршылау бәйрәме)

«Нәүрүз» сүзенең мәгънәсе фарсыча «яңа көн» дигәнне аңлата. Урта һәм Кече Азия илләрендә борынгыдан килгән Яңа елны каршылау бәйрәме ул. Иран, Әфганстан һәм башка кайбер илләрдә ул — дәүләт бәйрәме, көн белән төн озынлыгы тигезләшкән чорга — 21—22 мартка туры килә. Биредә ул язны каршылап, язгы кыр эшләре алдыннан үткәрелә торган халык бәйрәменә әйләнгән.

Бездә исә Нәүрүз көннәрендә (ул атна-ун көнгә сузылган) йорттан йортка кереп, «нәүрүз әйтеп» йөрү гадәте булган. Моны укучы балалар — шәкертләр башкарган. Нәүрүз такмагын укып яки яттан әйтеп (аны еш кына көйләп тә әйткәннәр), хуҗаларга бәхет, уңыш теләп йөргәннәр.

Нәүрүз шәкертләрнең үзара күңел ачу чарасы гына булып калмаган, алар авылдашларының да күңелен күтәргәннәр, асылда салкын кышлар бетеп килүенә бергәләшеп шатланганнар, язны каршылаганнар. Бераз сыйланып алулар да күзәтелгән, чөнки нәүрүз әйтүләр беркайчан да бушка булмаган.

Ач ишегең, керәбез.
Нәүрүз әйтә киләбез,
Аш-сый көтеп торабыз,
Нәүрүз мөбарәкбад.

Абзый, эшең уң булсын,
Теләгәнең юш булсын,
Күңелләрең хуш булсын,
Нәүрүз мөбарәкбад.

Казанга бармак кирәк,
Балыкка кармак кирәк,
Шәкерткә акча кирәк,
Нәүрүз мөбарәкбад... —

дип, йорттан йортка йөреп такмак әйткән алар.

Әйтергә кирәк, нәүрүз такмагы төрлелеге белән аерылып торган. Еш кына шәкертләр, үз авыл халкына җайлаштырып, аларны үзләре үк уйлап чыгарганнар. Мәсәлән:

Нәүрүз килә яшереп,
Яшереп тә теш ярып.
Сөләйман абзый, кетәмсең,
Табак-савыт бирәмсең!

Нәүрүзгә табак кирәк,
Табакка кабак кирәк,
Май, күкәй, калак кирәк,
Сиңа яшь кортка кирәк.

Тамагыңны туйдырыр,
Игеп-икмәк уңдырыр.
Көмәчен дә кызганма —
Озак яшә, сызланма,
Нәүрүз, Нәүрүз!

Кыскасы, монда яшьләрнең тапкырлыгы, җор сүзлелеге күренгән.

Мондый теләкләрдән соң ничек инде нәүрүз әйтүчеләрне буш кул белән чыгарасың? Күчтәнәчләрен, тәмле ашларын бирәү дә кызганмаган, һәркем хәленә күрә сыйларга тырышкан. Мондый йола бәйрәмнәрендә кешеләрнең бер-берсенә ихтирамы, хөрмәте чагылган.

НӘҮРҮЗ БӘЙРӘМЕ

Алып баручы. Исәнмесез, саумысез,
Бүген бездә бәйрәм көн.
Уйнап күңел ачам дип,
Бакчага килде һәркем.

Бүген бездә Нәүрүз бәйрәме. Элгәре заманнарда безнең бабаларыбыз, бабаларыбызның бабалары Яңа ел бәйрәмен 22 мартта уздырганнар. Аны «Нәүрүз» дип атаганнар. Ошбу көнне малайлар вә кызлар, һәр өйгә кереп, хуҗаларга такмак-такмазалар әйткәннәр, аларны бәйрәм белән котлаганнар.

Татар халык җыры «Шома бас» яңгырый.

Алып баручы. Чү, әнә үзләре дә киләләр бугай!

Куч безнең күңелгә
Җыр яме, җир яме!
Рәхим ит, түрдән уз,
Нәүрүз» бәйрәме!

«Шома бас» көенә җырлап, бүлмәгә малайлар һәм кызлар керәләр. Бер малай гармун тотып алдан бара. Барысы да җырлыйлар.

Барысы бергә. Уйнат, уйнат гармуныңны
Авазлары чыңласын.
Нәүрүз бәйрәменең җырын
Иптәшләрем тыңласын.
Их, шома басабыз,
Биеп күңел ачабыз.

1 нче бала. Кыш китте, яз килде,
Үрдәк белән каз килде,
Былбылдан аваз килде —
Нәүрүз мөбарәк булсын!

2 нче бала. Абзый, эшең уң булсын,
Теләгәнең юш булсын,
Күңелләрең хуш булсын,—
Нәүрүз мөбарәк булсын!

3 нче бала. Нәүрүз хакы биш алтын,
Бирсәң ярар ике алтын,
Карама ялтын-йолтын —
Нәүрүз мөбарәк булсын!

4 нче бала. Казанга бармак кирәк,
Балыкка кармак кирәк.
Ә безгә бәйрәм кирәк,
Нәүрүз мөбарәкбад!

5 нче бала. Нәүрүз әйттек без сезгә
Хакын бирегез безгә,
Яшегез җитсен йөзгә,
Малыгыз артсын көзгә,
Нәүрүз мөбарәкбад!

Барысы бергә. Нәүрүз мөбарәкбад!

Алып баручы. Нәүрүз бәйрәме мөбарәк булсын,
Яз саен кабатланып торсын!

Барысы бергә. Хәер-дога кылабыз,
Аш-сый күтеп торабыз.
Нәүрүз мөбарәкбад!
Нәүрүз мөбарәкбад!

Алып баручы *(сый өләшеп).*

Котлап сәлам бирдегез,
Әйдәгез сыйланыгыз!

Барысы бергә. Әйдә, әйдә, катырак бас,
Биегәнне күрсеннәр.
Баскан җирдән ут чыгара
Безнең Гүзәл дисеннәр.
Их, шома басабыз,
Биеп күңел ачабыз.

«Шома бас» җырының икенче өлешен җырлагач, балалар урыннарына барып утыралар.

Алып баручы. Әйтегез әле, балалар, Нәүрүз нәрсә дигән сүз соң ул?

Балалар. Ул Яңа ел, яңа көн дигәнне аңлата. Ул көнне көн белән төн тигезләшә. Менә шуннан соң көн озыная башлый.

Алып баручы. Ә Нәүрүз бәйрәме нинди бәйрәм?

Котлаучы. Яңа ел бәйрәме!

Балалар. Яз бәйрәме. Кышны озату, язны каршылау бәйрәме. Дуслык бәйрәме.

«Яз җитә» җыры көенә бүлмәгә карга костюмыннан балалар керә.

Алып баручы. Балалар, карагыз әле, кара каргалар килгән, алар бит яз хәбәрчеләре.

Кара каргалар. Исәнмесез, балалар!

Алып баручы. Кая таба очасыз?

1 нче кара карга. Ачылды ак калын юрган,
Исә язгы җилләр дә.
Без кайтабыз сагындырган
Туган-үскән җирләргә.

2 нче кара карга. Көннәрне юлда үткәреп,
Куанышып сезгә очтык.
Канатларга күтәреп,
Сезгә язны алып кайттык.

3 нче кара карга. Яз кызы — Нәүрүзбикә тиздән сезгә килеп җитә!

Кара каргалар бүлмәдән очып чыгып китәләр.

6 нчы бала. Көннәр аяз, күктән алсу
Нур сибеп кояш көлә.
Җиргә тама көмеш тамчы,
Сагынып көткән яз килә!

7 нче бала. Әйтегезче, кайсы вакыт
Яздагыдан ямьлерәк?
Кыш айларын да яратам,
Әмма яз күңеллерәк!

Кошлар сайраган тавыш ишетелә, балалар «Яз җитә» җырын башкаралар. Җыр ахырында сәхнәгә каргалар, сыерчыклар һәм башка кошлар белән Яз — Нәүрүзбикә керә.

Нәүрүз. Исәнмесез, балалар!

Балалар. Исәнме, Нәүрүзбикә!

Нәүрүз. Гайбәт бетсен телегездә,
Орыш бетсен илегездә,
Ачу китсен йөзегездән —
Шулай икән, киләм сезгә!

Балалар. Нәүрүз мөбарәкбад!

Нәүрүз. Бурычлыны кичерегез,
Дошманнарга кул сузыгыз,
Шуның белән мәрхәмәткә,
Йөрәгемә юл сызыгыз!
Шулай икән, киләм сезгә!

Балалар. Нәүрүз мөбарәкбад!

Нәүрүз. Котлап сәлам бирдегез,
Мине көтеп алдыгыз,
Имин йортта торыгыз,
Кәеф-сафа корыгыз.

Инде мине тыңлагыз,
Моңаеп утырмагыз —
Уйнагыз да көлегез,
Биегез дә җырлагыз.
Нәүрүз мөбарәкбад!

Алып баручы. Әй дуслар, килегез,
Күңел ачу көнебез.
Татарча матур итеп
Без биибез, күрегез!

«Зәлидә» көенә парлы бию башкарыла.

Алып баручы. Яз иртәсен котлагандай матур булып,
Зәңгәр күкне каплап алды зәңгәр болыт.
Бизәкләнгән төсле булды бөтен һава,
Кар өстенә шыбыр-шыбыр ләйсән ява!

«Яңгыр» җыры башкарыла.

Алып баручы. Әй дуслар, килегез,
Күңел ачу көнебез.
Әйдәгез, күмәкләшеп,
«Бишле» уенын уйныйбыз!

«Бишле» уены җырлар, биюләр, шигырьләр белән алып барыла. Беренче пар «Ай җаный, вай җаный» җырын, икенче пар үзбәк биюен, өченче пар «Сыерчык» җырын башкара, дүртенче пар «Кәнфит» шигырен укый, бишенче пар әтәч булып кычкыра.

Алып баручы. Балалар, Нәүрүз бәйрәменең тагын бер үзенчәлекле ягы бар әле. Бу бәйрәмдә әби-бабайларга ярдәм оештырыла. Мәсәлән, аларга су, утын кертеп бирергә, кар көрәргә мөмкин. Менә мин дә... әбигә сезнең исемнән котлау открыткасы яздым, аңа сәламәтлек теләдем һәм аны безнең бәйрәмгә чакырдым.

Әби керә. Сәламләү сүзләреннән соң «Сак-Сок» бәетен башкара, теләкләр теләп, хушлашып чыгып китә.
Татар халык җыры «Әнисә» яңгырый. Бүлмәгә, атын ияртеп, Хуҗа Насретдин керә. Аның базарга товар сатарга барышы, култык астында әтәче.

Хуҗа Насретдин. Хуҗа Насретдин товары
Һәркемгә дә җитәрлек:
Тары-бары, растабары

Һәркөн сатыла товары.
Әтәче җырлап тора ла,
Эте һау-һаулап тора.
Аты иһа-һай итә дә,
Ә үзе биеп китә.
Шәһәрнеке булмасам да,
Әйбер хакын беләмен.
Теләгәнчә матур итеп,
Читек чигеп бирәмен.
Яшьләр өчен шатлык мин лә,
Картларга да тансык мин.
Халык үлмәс — мин үлмәсәм,
Мәңге яшә, Насретдин! Амин!

Алып баручы. Әссәламегаләйкем, Хуҗа Насретдин!

Хуҗа Насретдин. Вәгаләйкемәссәлам! Исәнмесез! *(Балалар белән исәнләшә, аннан бер бала янына килеп.)* Әйт әле, абзый, бу Кукмара базары буламы?

Бала. Юк!

Хуҗа Насретдин. Бик зур күренә-ә-ә, Казан базарыдыр, ахрысы. Сөбханалла!

Алып баручы. Хуҗа Насретдин, бу базар түгел, бу бит мәктәп.

Хуҗа Насретдин. Яхшы, яхшы, миңа мәктәп тә ярый, бакча да ярый, товарым гына сатылып бетсен. Агач күләгәсендә ял итеп тә алырмын.

Алып баручы. Син мине дөрес аңламадың, Хуҗа Насретдин, бу ял итү урыны түгел, бу — балалар белем ала торган мәктәп.

Хуҗа Насретдин. Анысын ишеттем *(Хуҗа, капчыгыннан китап алып, паласын җәеп утыра).*

Алып баручы. Хуҗа Насретдин! Ә бүген бездә «Нәүрүз» бәйрәме. Ә син безнең олы кунагыбыз булырсың. Сине бик күп мәзәкләр, мәкальләр, табышмаклар, такмаклар белә дип ишеткән идек. Безгә дә сөйләмәссең микән?

Хуҗа Насретдин. Була ул, тыңлагыз! Мин мәкальне башлармын, сез тәмамларсыз. Тырышкан табар...

Балалар. Ташка кадак кагар.

Хуҗа Насретдин. Кем эшләми...

Балалар. Шул ашамый.

Хуҗа Насретдин. Ялкау утырып йоклый...

Балалар. Ятып ашый.

Алып баручы. Яшьләр өчен шатлык син,
Картларга да тансык син.
Халык үлмәс — син үлмәсәң,
Мәңге яшә, Насретдин!
Биеп алчы, Насретдин,
Ялындырма, Насретдин.

Хуҗа Насретдин «Әнисә» җырын башкара, шул ук вакытта үз товарларын күрсәтә.

Хуҗа Насретдин. Тыпыр-тыпыр биергә,
Тимер идәннәр кирәк,
Тимер идәннәр өстенә
Хәтфә паласлар кирәк.
Хәтфә паласлар өстенә
Имән өстәлләр кирәк,
Имән өстәлләр өстенә
Көмеш табаклар кирәк.
Көмеш табаклар өстенә
Хөрмә-җимешләр кирәк,
Хөрмә-җимешләр ашарга
Алтын кашыклар кирәк.
Алтын кашыклар тотарга
Кара кашлы кыз кирәк,
Кара кашлы кыз каршына
Хуҗа Насретдин кирәк.

Алып баручы. Ә хәзер әйдәгез уйнап алыйк. *(«Миңлебай» уены. Хуҗа Насретдин җитәкчелегендә уйнала.)*

Хуҗа Насретдин. Җәмәгать, мин исән чакта бу уенны бик яратып уйныйлар иде.

Алып баручы. Шәп шаяртасың, Насретдин!

Хуҗа Насретдин. Бүген Нәүрүз бәйрәме,
Күңел ачу көнебез.
Тәмле прәннекләр алырга
Минем янга килегез.
Товарымны сатмыйм әле,
Сезне сыйлыйсым килә.
Нәүрүз бәйрәмен котлап,
Бүләк бирәсем килә.
Сый-хөрмәтләр сезгә булсын,
Нәүрүз мөбарәк булсын!

Балалар. Рәхмәт сиңа, Насретдин!

Хуҗа Насретдин. Миңа китәргә кирәк.
Ишәгем, кузгал юлга,
Кичке намазым кала.

Балалар. Рәхмәт сиңа, Насретдин,
Мәңге яшә, Насретдин!

Алып баручы. Әйдәгез әле, балалар, бергәләп җырлап-биеп алыйк. *(«Әйлән-бәйлән» җыры башкарыла.)*

10 нчы бала. Җырларыбыз юлдаш булсын,
Юлдаш булсын, яңгырап торсын,
Эшләрегез уңнан булсын,
Илебезне бизәп торсын!

«Минем җырлыйсым килә» җыры башкарыла.

Нәүрүз. Кояш, чык, чык, чык,
Тәти кашык базарда,
Ботка пешәр казанда.
Батыр карны елак ит,
Җылың белән кунак ит.

Кояш керә.

11 нче бала. Кояш, кояш, син биектә,
Бар дөньяны күрәсең.
Әйтче, иң матур җир кайда?
Син бит инде беләсең?!

Кояш. Әйе, беләм, мин әйтәм, тыңлап кара:
Иң матур җир — Туган җир ул,
Онытма моны, бала!

«Кояшлы ил» җыры башкарыла.

Алып баручы. Алдагы көннәрегездә
Телибез зур уңышлар.
Муллыкта, тыныч тормышта
Хезмәт итегез, дуслар!

Сорау һәм биремнәр.

1. Текстны рольләргә бүлеп укыгыз.
2. Сезнең Нәүрүз бәйрәме турында ишеткәнегез бар идеме? Шул турыда сөйләгез.
3. Мәктәптә Нәүрүз бәйрәме үткәрегез.

ЭЧТӘЛЕК

Халык авыз иҗаты 3

Габдулла Тукай 7
Исемдә калганнар 8
Шүрәле 19
Туган авыл 23
Кичке азан 24
Татар яшьләре 26

Байназар Әлменов 27

Заһидулла Яруллин 28

Фәрит Яруллин 30

«Шүрәле» балеты 31

Фатих Әмирхан 36
Март каһарманы 37

Мәҗит Гафури 47
Татар байрагы 48
Сарыкны кем ашаган? 49

Галимҗан Ибраһимов 52
Алмачуар 53

Гадел Кутуй 70
Сагыну 72
Рөстәм маҗаралары 74

Хәсән Туфан 80
Киек казлар 81
Талантлы син, Кеше туганым 82

Газиз Кашапов 84
Киек каз юлы 85

Зифа Басыйрова 104

Роза Хафизова 106
Кашкарыйлар озын гомерле 107

Ибраһим Салахов 116
Колыма хикәяләре 117

Зыя Мансур 125
Таңсылу әкияте 126

Әмирхан Еники 131
Кем җырлады? 132
Матурлык 138

Рафаил Төхфәтуллин 148
Балам көлүе 149

Гөлшат Зәйнашева 152
Туган җирем — Татарстан 153

Фәрит Иделле 155
Өзелгән үзәкләр, саркылган йөрәкләр. 156
Ватан кайдан башлана? 161
Казан — башкалабыз 162

Нәүрүз 163
Нәүрүз бәйрәме 164

Учебное издание

Мусин Флюн Муслахович
Гилязов Ильдус Гилязович
Шавалиева Роза Сиразетдиновна

ТАТАРСКАЯ ЛИТЕРАТУРА

Учебник для 7 класса
средней общеобразовательной школы
с русским языком обучения
(для учащихся-татар)

Казань. Издательство «Магариф». 2005
На татарском языке

Уку-укыту басмасы

Мусин Флүн Мөслахович
Гыйләҗев Илдус Гыйләҗевич
Шәвәлиева Роза Сираҗетдиновна

ТАТАР ӘДӘБИЯТЫ

Рус телендә урта гомуми белем бирүче мәктәпнең
7 нче сыйныфы өчен дәреслек
(татар балалары өчен)

Редакторы *В. Г. Гомәрова*
Бизәлеш редакторы *Л. С. Золондинова*
Техник редакторы *Ә. С. Трофимова*
Компьютерда биткә салучысы *Н. А. Казакова*
Корректорлары *Р. Ә. Фәйзуллина, Л. Р. Гатауллина*
Рәсемнәрне компьютерда эшкәртүчесе *Э. Ф. Нурмөхәммәтова*

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 05.08.2005. Форматы $60x90^{1}/_{16}$.
Офсет кәгазе. «Школьная» гарнитурасы. Офсет басма.
Басма табагы 11,0+рәс.0,25+форз.0,38.
Нәшер-хисап табагы 8,63+рәс.0,25+ форз.0,38.
Тиражы 14 300 д. Заказ А-601.

«Мәгариф» нәшрияты. 420111. Казан, Бауман урамы, 19.
Тел. /факс (8432) 92-57-48.
http: // magarif. kazan. ru
E-mail: magarif@mail. ru

ААҖ «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы.
420066. Казан, Декабристлар урамы, 2.

ДӘРЕСЛЕКНЕҢ САКЛАНУ ДӘРӘҖӘСЕ

№	Укучының исеме һәм фамилиясе	Уку елы	Дәреслекнең торышы	
			ел башында	ел азагында
1				
2				
3				
4				



А. Абзгильдин. Тукайның төштә күргәннәре